**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ**
**ТҮБӘН КАМА ХИМИЯ-ТЕХНОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫ (ФИЛИАЛ)**
**ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЮДЖЕТ ЮГАРЫ**
**ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**
**“КАЗАН МИЛЛИ-ТИКШЕРЕНҮ ТЕХНОЛОГИЯ УНИВЕРСИТЕТЫ”**
**РУС ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЛӘРЕ ЦИКЛЫ**

# ТУКАЙ ИҖАТЫНЫҢ КАДЕРЕ

***Г. ТУКАЙНЫҢ 125-ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН ШӘҺӘРКҮЛӘМ ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ МАТЕРИАЛЛАРЫ***

**16 ДЕКАБРЬ 2011 ЕЛ**
**ТҮБӘН КАМА**

**УДК 82**
**Т 88**

**Тукай иҗатының кадере:** Г. Тукайның 125 еллыгына багышланган шәһәркүләм түгәрәк өстәл материаллары (16 декабрь 2011 ел). - Түбән Кама : Түбән Кама химия-технология институты (филиал) КНИТУ, 2012. – 145б.

Җыентыкка Г. Тукайның 125 еллыгына багышлап үткәрелгән шәһәркүләм түгәрәк өстәл чыгышлары тупланган. Аларда Г. Тукайның тормышы, иҗаты, аның белән бәйле истәлекләр яктыртыла, шулай ук Тукай исемен мәңгеләштерү буенча да материаллар урын алган.

**Редакцион коллегия:**
***Габдурахимова Татьяна Михаил кызы –*** редакцияләү – китаплар бастыру бүлеге мөдире, педагогика фәннәре кандидаты.
***Зарипова Гузалия Гали кызы*** – рус һәм татар телләре циклының өлкән укытучысы.
***Мирдиянова Бибинур Мөкәтдис кызы*** – рус һәм татар телләре циклының өлкән укытучысы.
***Саримова Резеда Рашшат кызы*** – рус һәм татар телләре циклы җитәкчесе, педагогика фәннәре кандидаты, доцент.

**УДК 82**

© Түбән Кама химия-технология
институты (филиал) КНИТУ, 2012

## ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛНЕҢ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ

Председатель:
***Саримова Резеда Рашат кызы*** – рус һәм татар телләре циклы җитәкчесе, педагогика фәннәре кандидаты, доцент.
Оештыру комитетының әгъзалары:
***Галеев Эльдар Рафаил улы*** – Түбән Кама химия-технология институтының фәнни эшләр буенча директор урынбасары, техника фәннәре кандидаты.
***Дырдонова Алена Николай кызы*** – Түбән Кама химия-технология институтының НИРС җитәкчесе, икътисад фәннәре кандидаты, доцент.
***Зарипова Гузалия Гали кызы*** – рус һәм татар телләре циклының өлкән укытучысы.
***Мирдиянова Бибинур Мөкәтдис кызы*** – рус һәм татар телләре циклының өлкән укытучысы.
***Балашова Марина Виктор кызы*** – рус һәм татар телләре циклының өлкән укытучысы.

**I НЧЕ ЮНӘЛЕШ.**

**ШАГЫЙРЬ ТОРМЫШЫННАН ЭПИЗОДЛАР**

***Шарифуллина А.И. 16 нчы мәктәп укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Фәрхетдинова Ф.Г.,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**ШАГЫЙРЬ ТОРМЫШЫННАН ЭПИЗОДЛАР**

1911 ел. 23-24 апрель. Г.Тукай Казаннан “Самолет” ширкәте “Тургенев” исемендәге пароходының өченче классына утырып, Әстерханга сәфәргә чыга.

Ул өстенә озын пальто, аягына ботинка, башына фуражка кигән, чәчен озын итеп үстергән була.

Әстерханга килеп төшкәч, ул “Люкс” кунакханәсенә урнаша. Бу шәһәрдә торганда (апрель азагы - 6 июнь) ул дуслары, танышлары һәм биредәге интеллигенция белән аралашып яши.

Ерак булмаган Балык Базары авылына барып, кымыз эчеп берникадәр сәламәтлеген рәтли, иҗат эше белән шөгыльләнә. Азәрбайҗанның күренекле җәмәгать эшлеклесе доктор һәм язучы Нариман Нариманов белән очраша. “Идел” газетасы редакциясендә хәреф җыючы булып эшләүче Габдерәхим Утабалиев истәлекләре буенча шундый күренешләр бар, Тукай Әстерханга килеп төшкәч тә иң элек дусты Сәгыйть Рәмиев янына – “Идел” газетасы редакциясенә килә.– Сәгыйть әфәнде, безгә бер авыру рус малае килә,-дидем.

Рәмиев миңа җавап кайтарырга өлгермәде, әлеге “малай” ишектән килеп тә керде. Сәгыйть, аны күргә урынынннан торып, каршы барып:

- Әй, Тукай-җан! - дип, ишектән керүчене кочаклады. Габдулла Тукай белән мин шулай таныштым. Әстерханда чакта Тукай редакциягә көн дә диярлек килә иде. Озакламый аның белән дуслаштык. Сәгыйтьнең эше тыгыз вакытта Тукай минем белән сөйләшеп утыра, үзенең Уральскида матбагада эшләгәнен хәтерли иде. Ә кайчакларда кәгазь келәтенә кереп,кәгазьләр өстенә ятып ял итә, хәттә йоклыйиде. Башта моңа безнең исебез китте, без аңардан, икенче катка менеп,

безнең торактагы йомшак урынга ятуын үтендек. Ләкин Тукай баш тартып:

- Рәхим, миңа монда да “Люкс”номерларыннан ким түгел, чебен дә тешләми,-дип җавап бирде.

Тагын шул истә: “Борһане тәрәккъкый” газетасында Сәгыйть Рәмиев белән Тукайга карата карикатура урнаштырылды. Берничә көннән Сәгыйть, җыярга дип, миңа “Мостафа” шигырен бирде. Аны Габдулла Тукай язган иде. Шигырь миңа ошады, аның беренче куплетын шунда ук ятлап алдым...

Ләкин икенче көнне Тукай яныма килеп:

- Рәхим, “Мостафа” шигыре кая? – дип сорап, аны кире алды.

Мин, җырлый-җырлый, шигырьнең оригиналын кайтырдым. Габдулла көлә-көлә:

- Инде яттан да беләсең, наборын тарат, кирәге юк, - диде.

Соңынна мин бу шигырьне Тукай җыентыкларында “Һазиһи касидәтеп фи мәдхи “Мостафа” исеме астында укыдым. Ләкин ул инде күп үзгәртелгән: “Борһане тәрәккъкый” редакторы Мостафа Лотфый кебек, халыкны революция юлыннан читкә өстерәүче, икейөзле милләтчеләрне көйдерә торган политик әһәмиятле шигырь иде.

Тукай Әстерханга килгәндә, Сәгыйть Рәмиев минем абыем Даут Мөхәммәдиевләрдә тора иде.

Даут абый көймәләр күтәрүче һәм конопатчы эшчеләр бригадиры булса да, бик прогрессив кеше иде. Ул Нариман Нариманов белән дә дус, аның белән йөрешә иде. Аның хатыны Әстерхан хатын-кызларыннан беренче булып сәхнәгә чыкты. Даут абый үзе дә спектакльләр, төрле җәмәгать чаралары оештыруда катнаша иде. Шуңа ул, Тукай килү хәбәрен ишетү белән, Сәгыйть Рәмиевкә Тукайны “Люкс” номерыннан үз өйләренә алырга тәкъдим итте. Соңыннан ул бөтен буш вакытын кунагы Тукайның Әстерханда булуын күреп, Даут абый, Сәгыйть Рәмиев белән бергәләп, аны доктор Наримановка алып бардылар.

Нариман Нариманов Тукайның авыруын карагач:

- Бер-ике сәнә мөкатдәм килү кирәк иде, - дигән.

Шулай да аңа көч җыярга, кымыз эчеп карарга киңәш биргән.

Шул киңәш буенча Тукай Калмык базарында, укытучы Шәһит Гайфидә торып, кымыз эчте.

Доктор Нариманов һәр ел ромашка чәчәк ата башлаган көннәрдә, “Ак чәчәк бәйрәме” оештырып, туберкулезга каршы көрәш кампаниясе үткәрә иде. Шуңа хәзерлек барган көннәрдә, Тукай белән танышкач, ул аңа бу чарага катнашырга тәкъдим итә һәм Тукай аны кабул итә.

Тагын Тукайның Яңа Гаскәр авылына барганын хәтерлим. Анда баруны Даут Мөхәммәдиев оештырды. Ул моторлы көймә сорап алды. Бу юлы мине “кушчы бала” - йомыш үтәүче итеп алдылар.

Язгы ташу вакыты иде. Көймә Аударма елгасыннан барды. Яңа Гаскәрдә “Ирагаҗи” зияратында булдык. Сәгыйть Рәмиев турыдан-туры каберлеккә барып керде, аннан аңа каршы мөҗәвир килеп чыкты. Сәгыйть аптырап калмады:

-Галимҗан хәзрәт шәкертләрен изге аталарга Коръән укырга алып килдем,-диде.

Галимҗан хәзрәт дигәч, тагын бер кызыклы хәл хәтеремдә. Тукай минем абый – Мәзһәр Моради-Алиев белән бергә укыган булган. Мәзһәр абый Казанда Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә үлеп кала. Тукайны Әстерхандә Мәзһәрләргә Габдерәхим Сәмәки алып барды. Киткәндә Мәзһәрнең анасы,аларны озата чыгып, Тукайга:

- Мә, балам Габдулла, Мәзһәр рухына укырсың,- дип, ун сум акча тоттырды.

- Әнкәй, мин сәдака алмыйм,- дип, Тукай акчаны кире кайтарды диелә Вәлит Алиев истәлекләрендә.

Ә шулай да, Әхмәт Урманчеев истәлегендә Тукайның 1911 елның 5 нче маенда Әстерханнан Казанга язган хаты бар.

Мелла Әхмәт әкә!

Мин, малай, Әстерханда. Бу хат сиңа барганчыга кадәр булган вакытны исәпләмичә, тагын бер ай кадәре торырга карар

бирдем. Киләсе хатымда рәсемнәр өчен темалар вә, булдырып булса, мәкалә вә шигырьләр дә җибәрсәм кирәк. Әле хәзер кунакка йөрүдән бушаганым юк.

Бу мәкаләләрне дөрест басарга иҗтиһад итеңез. Әлбәттә, бик шәп чыкмадылар. Моны “Шүрәле” имзай шәрифен куймавымнан да аңларга мөмкин. Кымыз эчәм. Ит ашыйм, һава яхшы. Хәзердән үк үземдә җисмән вә рухан бер көч хис итә башладым.

Квартирамда ничава. Сәгыйт белән бергә торабыз. Баерак вакытыңыз булса, миңа бер 5 тәңкә акча җибәрсәңез, яхшы булыр иде. Ят җирдә кирәк бит...

Һәрхәлдә, адресым:

Астрахань, ред.газ. “Идель”, Сагиду Рамееву.

Үз исемемә (хосусән акча булса) җибәрергә ярамый. Г.Т.

6 июнь. Г.Тукай Әстерханнан “Василий Лапшин” исемле пароходка утырып, Казанга кайтырга чыга. Бер төркем дуслары аны озатып калалар. Истәлекләрдә аның килгәндәгедән күп үзгәргәнлеге, кымыздан соң тазарганлыгы әйтелә.

**Әдәбият:**

1.Тукай Г.Сайланма әсәрләр. Ике томда. 2 т. Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар./ Г.Тукай. – Казан: Татар.кит.нәшр.,2006. - 335 б.

2.Тукай Г.Сайланма әсәрләр.Ике томда.2т.Шагыйрь турында истәлекләр./Г.Тукай.-Казан:Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты ( ТаРИХ), 2002.446-452 б.

3.Тукай Г. Тормыш һәм иҗат елъязмасы.Казан: Татарстан китап нәшрияты,2003.179-182 б.

*Тимербаева Л. 10 нчы мәктәп укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Гараева Г.Р.,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## ТУКАЙНЫҢ ҖАЕКТАГЫ ТОРМЫШЫ

Сөекле шагыйребезнең исемен телгә алуга, үзеннән-үзе аның "Исемдә калганнар" дигән язмаларында бәян ителгәннәр хәтергә килә. Шуларга менә бу мәгълүм юллар өстәлә:

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?

Азрак үстерде сыйпап тик маңгаемнан милләтем.

Әйе, 1886 елдан алып 1895 елга кадәр, ягьни Жаекка килгәнче, кечкенә Габдулла бик күпләр озын гомер кичереп күрмәгәннәрне дә башыннан уткәрә.

Г.Тукайның "Исемдә калганнар" хикәясе аньң Җаекка китүе белән тәмамлана. 1895 елда Җаекка аны этисенең бертуган сеңлесе Газизә апасы белән җизнәсе Галиәсгар эзләтеп алдыра. Сәүдәгәр Галиәсгар Госманов Габдулланы яхшы тәрбияли, килгән елда ук заманында алдынгы саналган "Мотыйгия" мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Ул сабакны күңел биреп, тырышып укый, кайчакларда, дәрескә соңга калам дип, иртәнге ашны да ашамыйча китеп бара. Тукай мәдрәсәдә иң галим, иң үткен, зирәк шәкертләрдән санала. Ул гарәп, фарсы, төрек телләрен үзләштерә.

Бер үк вакытта Тукайны җизнәсе мәдрәсәгә бирү белән бергә рус мәктәбенә дә йөрткән. 1896 елның сентябрь аенда Габдулланы җизнәсе Галиәсгар Госманов еч еллык рус классына бирә. Булачак шагыйрь мәдрәсәдә дә, рус классында да бер үк вакытта укый. Рус классында беренче учителе Оренбургта Учительская школаны тәмамлаган Әхмәтша Сиражетдинов (1850—1919). Учительнең бай китапханәсе булган. Габдуллага рус язучыларының әсәрләрен биреп укыткан. Пушкин, Лермонтов ижаты белән ул беренче мәртәбә шушында танышкандыр, дип уйланыла. Әхмәтша учитель Тукайның сәләтле бала булуы турында сокланып сөйли торган булган, рус классына кергәндә, Габдулла ун яшендә була. Сабакташы Ярулла Морадыйга үзе: «Мин школага кергәндә сигез яшьтә генә идем»,— дип сөйләгән.

Г.Тукайның талантлы шагыйрь булып җитешүендә Госмановлар гаиләсенең роле аз булмаган. Шәһәр мохитендә яшәү, «Мотыйгыя» кебек алдынгы мәдрәсәдә, шуның белән бергә рус классында уку Габдулланың дөньяга карашы, шагыйрьлек таланты формалашуга уңай йогынты ясамый калмаган.

Тукай Пушкин, Лермонтов, Крылов, һәм башка әдипләрнең иҗаты белән таныш була, аларны ирекле тәрҗемә итә. Рус теле аша ул инглиз, француз һәм башка халыкларның әдәбияты белән таныша. Шекспир, Байрон, Гетеның да берничә шигырен тәрҗемә итә ул. Тукай Җаекта "Пушкин йортына" йөри, анда Пушкин, Гоголь, Кольцов, һәм башка рус әдипләренә багышланган кичәләрдә катнаша.

Пушкин белән Тукай икесе дә гаилә бәхете татымаганнар. Бу да аларның охшашлыгы. Ләкин аларның уртаклыгы тирәндәрәк ята. Пушкин гади халыкның тормышы турында уйлана торган әсәрләр иҗат иткән, Тукай да гади кешеләрнең язмышын, халык тормышын кайгыртып яза.

Пушкин 1824 елда рус теленә Веревкин тәрҗемә иткән Коръәнне укый һәм тулысынча өйрәнеп чыга. Аның изге Коръән тәэсире белән язылган "Подражание Корану" дип исемләнгән шигъри җыентыгы чыга. Пушкин иҗат иткән "Алтын әтәч" әкияте гарәп халык әкиятләреннән алынган була. Тукай аны татарчага тәрҗемә итә.

Тукай Пушкинны хөрмәт итеп, "Хәзрәти Пушкин" дип атый. Тукай рус шагыйрьләренә ияреп, күп әсәрләр яза. "Көзге җилләр", "Милләтемә", "Үз-үземә" шигырьләре шундыйлар.

Ул үзен кеше һәм шагыйрь буларак, Пушкин һәм Лермонтов белән янәшә куя.

*"Шигъре Лермонтов вә Пушкин саф диңгез ул,*

*Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай -өч йолдыз ул", - дип яза "Җавап" шигырендә.*

Берничә елдан, җизнәсе үлгәч, "Мотыйгия" мәдрәсәсенә күчә, ягъни ундүрт яшьлек малай үз көнен үзе күрә башлый. Мәдрәсәдә җаның рәхәт! Беркемнең дә күзенә карап тормыйча, беркемгә дә баш имичә, хөр яшисең, үзеңчә яшисең.. Җитмәсә, иптәшләр арасында күңелле. Мендәр сугышы дисеңме, сукыр

тәкә уйнаумы, әкият сөйләшүме-хозурның хозуры. Болар белән инде Габдулла яхшы таныш. Ул җизнәсе исән чакта ук мәдрәсәдә кунгалап йөргән.

Мәдрәсәдә Габдулланың тагын бер сыйфаты ачылып китә: җырга оста икән ич ул. Дөрес, замандашларының әйтүенә караганда, аның тавышы артык матур да, көчле дә түгел икән. Әмма ниндидер үтә бер моң белән, көйнең һәр борылышындагы күчешләрне бөтен нечкәлеге белән биреп җиткерүе, аның җырлавы матур тавышлы җырчыларныкыннан ким тәэсир итмәгән. Тормышының бу вакытында Тукайга Мотыйгулла хәзрәт ярдәм итә. Ул Уральскийда бу вакытта имам һәм ахун булып тора. Мотыйгулла хәзрәт бик галим, зыялы кеше була, борынгы Көнчыгыш фәлсәфәсен, шигъриятен яхшы белгән, астрономия буенча да белемле кеше була.

Габдуллага шигырь иҗат итү серләрен беренче булып өйрәтүче дә - Мотыйгулла хәзрәт. Ул узенең улы Камиль Мотыйгыйга типография сатып ала. Тукайның журналистлык эшчәнлеге Камиль Мотыйгый белән бергә башлана. Билгеле инде Камилнең төс-кыяфәте, үзен тотышы, күп җирләрдә булып, күп нәрсә күргәнлеге, күп белүе 16 яшьлек Габдуллага шактый көчле тәэсир иткән. Ул аңа якынаерга, аңардан өйрәнергә тырышкан. Габдулланы тагын К.Мотыйгыйның яңалыкка омтылуы, кайнап торган энергиясе үзенә тарткан.

Габдулла типографиядә корректор, редактор булып эшли, үзенең әсәрләрен дә чыгара. «Фикер» газетасының беренче санында ук Г.Тукайның "Ник йоклыйсың, мужик" дигән шигыре басылып чыга. Габдулла Тукай Камиль Мотыйгый белән «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» сатирик журналларын да чыгара.

Булачак шагыйрь 1902-1904 елларда җинел һәм күп язган. Чөнки Габдулла инде шигырь техникасын үзләштерде, рифма үзеннән-үзе килә. Үрнәкләр дә җитәрлек. Аннан да бигрәк, ул тормыштан алып язарга кирәклеген төшенде. Тукайның 1906 ел урталарыннан алып 1907 елньң көзенә кадәр язганнарын да аз дип булмый. Иллеләп шигъри әсәр, шулар эчендә бер поэма, иллегә якын мәкалә һәм фельетон. Әмма хикмәт санда түгел-хикмәт Тукайның шагыйрь һәм публицист буларак гаять тиз үсәендә.

Хикмәт-сыйфатта. Тукайның бу чорда ук нинди югарылыкка күтәрелүен күз алдына китерү өчен ataклы "Шүрәле" әкият-поэмасының шушы чорда язылуын искә алу да җитә. Тукай, Уральскидан тыш, татарлар яши торган төбәкләрдә нәкъ менә 1906 елның икенче яртысыннан башлап язылган шигырьләре белән танылa. Дөрес, киң халык массасы тарафыннан танылу түгел әле бу. Чөнки аның "Су анасы", "Кәҗә белән сарык" кебек экиятләре, "Печән базары яхут яңа Кисекбаш" исемле поэмасы, балаларга багышланган шигырьләре әле язылмаган, бер генә китабы да укучы кулына барып кермәгән.

Безнең Габдулла моңарчы да талантына һәм шагыйрьлегенә нык ышана иде. Хәзер исә китабы күренекле һәм зәвыклы Гыйльметдин Шәрәф кебек китап нәшрияты җитәкчесе тарафыннан кабул ителгәч, болай да кечкенә Җаек Габдуллага тагын да таррак булып тоела башлый. Канатлар ныгыган бөркет баласының, тар оядан чыгып, киң дөньяга очасы килә. Кая? Билгеле инде, Казанга. Кечкенә Апуш хәзер зуп-зур Тукай булды. Ул-шагыйрь. Аның халкына, милләтенә биргән олы вәгъдәсе бар. Бу вәгъдәне ул татар мәдәниятенең үзәге-Казанда гына үти алачак.

Моңа тагын Уральскига килеп төшүеннән үк башланган һәм унбер-унике ел дәвамында бер дә ташлап тормаган сагынуын да өстик. Балачагы никадәр генә ямьсез үтмәсен, туган туфрак - газиз. Кимсетелүләр һәм ачлык-ялангачлык инде онытылган, сирәк кенә була торган кечкенә шатлык һәм куанычлар исә, вакытның зәңгәр томанына өртелеп, матур булып зураеп күренәләр, дулкынландыралар. Кырлай урманы, чәчәкле болыннар, тар инеш һәм чишмә буйлары Габдулланың йөрәген , туктаусыз чакырып торалар. Казанның үзен инде әйтәсе дә юк. Бала чагында гаять мәһабәт булып куренгән таш кала унике елдан соң аның хыялында, һичшиксез, нур эчендә йөзә торган әкият шәһәре булып калыккан. Аннан да бигрәк, ул татар милләтенең, татар халкыньң мәдәният үзәге. Анда Гаяз Исхакый бар, Галиәсгар Камал бар.

Бу чыгышны тәмамлап мин шуны әйтәсем килә: Тукай тормышында ″Җаек шәһәре зур һәм әһәмиятле урын алып

торган. Ул инде Казанга үткен телле, дөреслек өчен көрәшүче кыю яшь шагыйрь буларак китеп бара.

**Әдәбият:**

И.Нуруллин "Монды саз чьщнары" Казан: Татарстан китап нэшрияты, 2000.-Ә.Фәйзи "Кечкенә Апуш" Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1993.-Ә.Фәйзи. Әсәрләр биш томда. Казан: Татарстан китап нәшрияты ,1985.

***Якупова М.Р. 10 нчы мәктәп укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Хәбирова Л.Ә.,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## ТУКАЙ ЯНӘШӘСЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗЛАР

“Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь Габдулладай
Ул - караңгы төндә яктырткан матур, ак тулган ай”. (Шәехзадә Бабич)

“Килер заман: һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар”, - дип язган иде бөек шагыйребез Габдулла Тукай. Ул заман килде. Еллар узган саен Тукай иҗатының мәгънәсе тирәнрәк ачыла бара. Ә 2011 ел Татарстан Республикасында Тукай елы итеп игълан ителгәч, аның җиһанга ямь, яктылык биргән, яшәү көче бөркеп торган бай һәм күп тармаклы иҗатына,  тормышына игътибар тагын артты.

Фәнни эшебезнең **темасы**: “Тукай янәшәсендә хатын-кызлар”.

Сайлаган **темабызның актуальлеге**. Халкыбызның күренекле улы, бөек шагыйре Габдулла Тукайның тормышы һәм кабатланмас иҗаты турында күп язылды, күп укылды. Әдәбият белгечләребез һаман да аның биографиясенең ачыкланып бетмәгән кайбер фактларын тикшерәләр, истәлекләрен барлыйлар. Алар арасында бүгенгә кадәр “Тукай хатын-кыздан качкан” дигән фикер яши. Бу чыннан да шулай микән соң? Дөрес булса, ни өчен Тукай

алар белән аралашудан баш тарткан? Моның сәбәпләре нидә булган? Без дә үзебезчә шул сорауларга җавап эзләү эшенә алындык.

Төп **максатыбыз**-Тукай янәшәсендә булган, аның белән аралашкан хатын-кызларны ачыклау. Хезмәтебезнең **тикшерү объекты** – Габдулла Тукайның шәхси тормышы, ә **тикшерү предметы** – Тукай янәшәсендә хатын-кызлар.

**Кулланылган чыганаклар.**

Эш барышында төрле чыганакларга мөрәҗәгать итәргә туры килде. Фәнни эшне башкарып чыгу өчен 15 чыганакка анализ ясалды.

Эшнең **структурасы.**

Фәнни эшебез кереш, төп өлештән, йомгаклаудан, әдәбият исемлегеннән һәм кушымтадан (презентация) тора.

Максатыбызны тормышка ашыру өчен эшебезнең **бурычларын** да билгеләдек:

**1**. Габдулла Тукай турында истәлекләрне барлау, чыганаклар туплау.

**2**. Тукай белән бәйле хатын-кызлар исемлеген төзү.

**Беренчедән,** бу-Тукаебызның әнисе Мәмдүдә.

**Икенчедән,** Тукайның тормышында эз калдырган, аңа күңел җылысын кызганмаган Зиннәтулла бабасының кызы Саҗидә һәм Газизә - әтисенең сеңлесе.

**Өченчедән,** Нәни Габдулланы башлап гыйлем дөньясына алып кергән, гомере буе Тукайны хөрмәт итеп яшәп, шагыйрьнең соңгы сәгатьләренә кадәр янына барып йөргән, хәлен белеп торган шәфкатьле ханым-атаклы мөгаллимә, шагыйрә Маһруй Габделвәли кызы Мозаффария (Маһруй абыстай).

**Дүртенчедән,** аның тирәсендә булган мәгърифәтче хатын-кызлар Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Гөлсем Болгарская, Хөсәен Ямашев белән Хәдичә апа, китап нашире Шиһаб Әхмәрев белән хатыны Әминә Әхмәрева, Закирә апа белән ире журналист Борһан Шәрәф, гимназия тәмамлаган апалы-сеңелле Әминә, Мәдинә Терегулова һәм Зәйнәп, Рабига

Габитовалар, Зәйнәп Хәсәни, Фатиха Аитова, Суфия Коләхмәтова.

**Бишенчедән,** Тукай иҗатында мәхәббәт шигырьләренең тууына сәбәпче хатын-кызлар: Җаекта укыган чакта күз атып йөргән кызы һәм Тукайның бердәнбер сөйгәне- Зәйтүнә Мәүлидова.

**3.**Тукайны "татар Пушкины" дип йөртсәләр дә, дәртле рус әдибеннән аермалы буларак, 27 елга якын гомерендә Тукай бәхетле сөю хисләрен кичереп өлгермәгән. Тукайның иҗатына гашыйк туташлар күп булган. Тукайны хатын-кызлар бик яраткан. Туташлар аның кайларда йөрүен белү өчен нәрсәләр генә эшләмәгәннәр, очраклы очрашу ясарга хәйләләр корганнар. Тик шагыйрь алардан качу юлларын бик тиз эзләп тапкан. Ялгызак, үз эченә бикләнеп яшәүче Тукай үз кайгыларын беркайчан да берәүгә дә сөйләмәгән. Ә Тукай үзе сөйгәнме? Ул хатын-кызлар булган мәҗлесләрдә күренмәгән, алар очрарга мөмкин җирләрдән читтә йөргән. Бу бит әле аның хатын-кызларны яратмаган дигән сүз түгел. Әгәр Тукай хатын-кыздан кача, аларны яратмый торган булса, аның мәхәббәт шигырьләре туар идеме икән? Аның "Мәхәббәт", "...гә", "Гашыйк", "Соңра", "Кулың", "Кызык гыйшык" һ.б. шигырьләре моңа дәлил.

Ләкин туң йөрәкне эретерлек бер туташ була, ул- Зәйтүнә Мәүлидова. Тукай аны нибары биш мәртәбә генә күргән. Әмма шагыйрьнең күңелендә мәхәббәт турында берничә гүзәл әсәре туу өчен шунысы да җиткән. Зәйтүнә дә бит үләр алдыннан: "Мөмкин булса, мине Тукай янынарак күмсәгез иде,"- дип, үтенечен белдергән. Кабер ташына Тукайның Зәйтүнәгә багышланган беренче шигыреннән:

"Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген;

Ул шуңар да шатлана бит",- дигән сүзләр язылган.

Менә шулай ике яшь йөрәк тойгылары турында түгел, болай гына да ялгыз калып бер сүз дә сөйләшмәгән килеш мәңгегә аерылышалар.

Тукай - яшь, өйләнмәгән кеше булган бит, шуңа күрә кызлардан оялу- әхлаклы, иманлы яшьләр өчен бик табигый хәл. Тукай хатын-кызларның игътибарыннан качып, оялып йөрсә дә,

аның тормыш юлында, янында һәрвакыт укымышлы, зыялы, тәртипле һәм тәрбияле, хөрмәткә лаек хатын-кызлар булган. Үз чиратында, бөек шагыйребез шигырьләре аша аларга хөрмәтен, мәхәббәтен, күңеленең иң тирән серләрен ачып биргән.

Габдулла Тукайның шәхесе һәм ул тудырган үлемсез әсәрләр һәрвакыт халык күңелендә калалар. Без бүген дә чиксез горурлык хисләре белән сөекле шагыйребезнең шигырьләрен кабатлыйбыз. Һәр йөрәктә- Тукай моңы, Тукай рухы!

Татар халкы милләт булып яшәгәндә Тукай да яшәр, һәр туар яз безне Тукай белән очраштырыр.

**Әдәбият:**


1. “Атна вакыйгалары” гәзите. 25 март, 2011./Венера Беляева: Тукайның бердәнбер сөйгәне/.
2. Әмирхан Ф. Әсәрләр. 4 томда. Т. 4.-Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.- Б. 161- 162.
3. Биктимерова Т. Тукай даирәсендә-хатын-кызлар.- Мәгариф журналы.- №4.- апрель, 2011.- Б.68-71.
4. Ильина С. Кайдан алсын шигъре шагыйрь.- Мәгариф” журналы.- №4.- апрель, 2006.- Б.25-26.
5. Рәсүлева З. Тукай эзләреннән.- Казан: Татар, кит. нәшр., 1985. - Б. 63.
6. “Салават күпере” журналы, 2004 ел, апрель.
7. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр.- Казан: Тат.Респ. “Хәтер”нәшр., 2002.- 511 бит.
8. Тукай Г. Тормыш һәм иҗат елъязмасы/ Ә.Х.Алиева, З.З.Рәмиев ред./- Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.- 271 бит.
9. “Чулман энҗеләре” гәзите, 2010 ел, апрель.
10. “Ялкын” журналы, 2006 ел, апрель.

*Никитина А.Е. 10 нчы мәктәп укчысы*

# Г. ТУКАЙНЫҢ НӘСЕЛ ШӘҖӘРӘСЕ

## Кереш өлеш.

Кешелекнең иң югары кыйммәткә ия булган сыйфатларыннан берсе, мөгаен, Туган иленә, төбәгенә, йортына булган тирән мәхәббәттер. Социаль тормышка аяк баскан бала бик кечкенәдән үзенең кем икәнлеген, ә иң мөһиме, аның үзенә генә хас тормыш юлы булганлыгын һәм иртәме-соңмы үз тормышы өчен җавап бирергә кирәклекне аңлый башлый. Чөнки кеше тормышы яшәү һәм үлем белән генә чикләнми. Чын яшәү ул - үз исемең аша нәселеңне, аның матур сыйфатларын дәвам итә белү. Ә моның өчен үз барлыгыңны, аның тарихи килеп чыгышын аңлау зарури.

Элек-электән төрки дөнья кешесе әти-әнисе ягыннан җиде буынга кадәр нәселен белеп, алар рухына дога укырга тиеш булган. Укымышлыларга тугыз буын бабаларын белү таләп ителгән.

Һәрбер кеше бик кечкенәдән үзенең нинди нәселдән килеп чыгып, нинди юлдан барырга тиешлеген тоеп яшәргә тиеш. Шул мәгълүм: тамырлары нык булмаган кеше тормыш зилзиләләренә каршы тора алмый. Юкка гына шәҗәрә “агач” мәгънәсен аңлатмыйдыр. Тамырлары нык булган агач көчле җилләргә дә бирешмәгән кебек, үз асылын аңлаучылар, үз тамырларын тоючылар тормышта да югалып калмыйлар. Тамырлар ул – безнең бабаларыбыз, бабаларыбызның бабалары, гаилә традицияләре, бабаларыбызның данлыклы эш-гамәлләре, ниһаять, ул синең фамилияң, кушаматың, нигезең, халкың, Ватаның. Кайбер гаиләләрдә иске альбомнар, гаилә ядкярләре, чүп-чарга саналып, аяусыз рәвештә юкка чыгарыла. Менә шулай тамырлар чабыла: кайтарып булмаслык зур ялгышлар ясала. Соңгы елларда генеалогия фәненә - нәсел тарихын өйрәнүгә - шәҗәрәләр төзүгә игътибар артты. Күпләр чын-чынлап үзләренең барлыгын аңларга: белеп булган барлык бабаларын эзләп табарга тырышалар. Бу – бик күп вакыт сорый торган,

катлаулы, четерекле, шул ук вакытта кызыклы һәм бик саваплы эш.

Быел Татарстанда Тукай елы булгач, минем аның турында күбрәк беләсем килде һәм мин аның турында материаллар туплый башладым.Тукай турында күбрәк белү теләге белән мин фәнни-тикшеренү эше язарга булдым. Мине кызыксындырганы- аның нәсел шәҗәрәсе. Үз алдыма шундый максат куйдым:1. Тукайның нәселе каян килеп чыккан.2. Ничә буын барлыгы билгеле.3. Нәселендә нинди күренекле кешеләр булган. 4.Кемнәр аның тормышы һәм иҗатын туплау эше белән шөгыльләнгән- шуны ачыклау.

Татар халык шагыйре Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлы күптәннән өйрәнелеп килә. Әдәбият галимнәре бу проблеманы игътибар үзәгенә куеп, күп кенә китаплар, монографик хезмәтләр яздылар.

Тукайга багышланган мемуар әдәбият шактый бай. Үлгән көннән алып 50-60нчы елларга кадәрге чорда аның турында йөзгә якын истәлек язылды. Шулардан кайберләре архивта саклана, күбесе матбугатта да дөнья күргән.

Ләкин Тукайның тәрҗемәи хәле әле тарихи эзлеклелектә өйрәнелгән дип булмый. Минем уйлавымча, һәр кеше бөек Тукай турында белергә тиеш. Аның өчен төрле өстәмә китаплар укырга, интернетка да мөрәҗәгать итәргә кирәк. Быел Тукай турында бигрәк тә күп телгә алына, чөнки аның тууына 125 ел һәм быел Татарстанда Тукай елы дип игълан иттеләр. Шуңа күрә бу тема быел бик актуаль.

**Төп өлеш.**

Нәрсә ул шәҗәрә?

Шәҗәрә ул – чал тарихка батыр тәрәзә, Күз яздырсаң, шул тәрәзәдән атар ядрә. Ал бер үрнәк – бал кортлары төзи кәрәз, Син дә ятма, кор ояңны, үр шәҗәрә. Шәҗәрәдә - чал тарихы бабаларның,
Бүгенгең дә, киләчәгең, балаларың. Корымасын шәҗәрәңнең тамырлары, Урын алсын оныкларның оныклары.

Шәҗәрә ул – ыру-кабилә тарихына бәйле вакыйгалар, нәсел-нәсепнең таралуы, ата-бабалар исемлеге теркәлгән кулъязма

истәлек. Борынгы заманда шәҗәрә тармакланып үскән агач формасында төзелгән. Бу бик дөрес, чөнки агач җир эченә киткән тамырлары аша кемлегеңне белү өчен, иң беренче чиратта, туган җир, туган авыл тарихына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Шәҗәрә - ул нәсел – ыругыңның кемнән башлап, ничек тармакланып китүен күрсәткән, нәсел агачы.

Нәсел – ыру тарихлары белән кызыксыну дөньядагы күп халыкларга таныш. Мөселман – ислам дөньясы үзенең мәдәни – рухи системасына шәҗәрәләр белүне керткән. Һәр мөселман үзенең әтисе һәм әнисе ягыннан җиде буын бабасын белергә тиеш була. Ә галим кешеләрдән тугызар буын бабаларын белү таләп ителгән.

Татар телендә шәҗәрә сүзенең күп төрле синонимнары сакланган : шәҗәрә - тарих, нәсел шәҗәрәсе, шәҗәрә китабы, нәсел агачы, тарих һ.б.

18 нче гасырдан калган татар кулъязма китаплары битләрендә шактый гына шәҗәрә текстлары булган.

19 нчы гасырга кергәч, татар шәҗәрә текстлары белән И.Хәлфин, К. Фукс, Ш. Мәрҗани, Х. Әмирхан, Р. Фәхретдинов. С. Шпилевский кебек галимнәр кызыксынып, аларны туплап, үзләренең хезмәтләрендә тарихи чыганаклар итеп файдаланганнар.

20 нче гасыр башында (бигрәк тә 1905 нче елдан соң) газета - журнал битләрендә татар шәҗәрәләре басылып тарала башлый. Халык кулларында йөргән аерым каллиграфлар тарафыннан язылган пәйгамбәрләр, солтаннар шәҗәрәләре ташбасма ысулы белән нәшер ителеп, татар шәҗәрәләре белән халыкның кызыксынуын үстерәләр. Шушы чорда татар басмалары тәэсире белән казаклардан да шәҗәрәләр төзеп чыгаручылар күренә башлый. Бу дәвердә татар галимнәре Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Һ. Атласи, С. Вәлиди, Г. Рәхим кулларында татар шәҗәрәләре текстларының бай коллекцияләре туплана. Ризаэтдин бине Фахретдин тарафыннан татар һәм башкорт шәҗәрәләреннән беренче җыентык төзелә. Кызганычка каршы, ул җыентык эшләнеп бетми һәм аны басарга мөмкинлек тә калмый. Тамырлар никадәр тирәнрәк китсә, агачлар шулкадәр тотрыклырак, җил давылларга бирешмәүчәнрәк булалар. Шуның кебек үк

хылыкларның тарихи тамырлары да никадәр тирәнрәк катламнардан үсеш алсалар һәм ул катламнардан бүгенгә килеп җиткән хәбәр - өн никадәр тулырак булса, халыкның язмыш - тәкъдире, үткән юлы да вакыт көзгесендә шулкадәр үк тулырак гәүдәләнә. Бу бик тә мөһим, чөнки үткәннәр белән киләчәк арасында җанлы бәйләнеш булганда гына нәсел агачы тере булачак һәм гасырлар дәвамында бирешмичә шаулап үсеп утырачак. Шәҗәрәләр исә (бүген сүз шул хакта барачак) тамырдан кәүсәләргә, ягъни ерак үткәннәрдән бүгенгә “Тереклек суы” ташып торучы җепселләр ул.

Дөньяда күп халыклар элек - электән үзләренең, күренекле кешеләрнең нәсел - нәсебе белән кызыксынганнар, шәҗәрәләрен төзегәннәр, аларны гасырлар буе саклаганнар һәм саклыйлар.

Халкыбызның бөек шагыйре Г.Тукайның турыдан - туры туганы һәм шулай ук никах буенча булган туганнарыннан ике йөз егерме өче күрсәтелгән беренче шәҗәрә 'Казан утлары' журналының 1986нчы ел дүртенче санында басылып чыкты. Ул шәҗәрәне Тукайның әнисе ягыннан бабасы Зиннәтулла балалары турында архив документлары нигезендә, ә балалары турында шагыйрьнең әле исән булган олы һәм урта яшьтәге туганнарының үз нәселләре хакында сөйләгән, язган һәм имзалары расланган истәлекләре нигезендә ясалган. Бу истәлекләр аерым китап булып Тукайның 100 еллыгына басылып чыкты ("”Тукай эзләреннән” дигән баш астында Татарстан китап нәшрияты 1985нче елда чыгарды). Монда шагыйрьнең шәҗәрәдә күрсәтелгән туганнарыннан йөздән артык кешенең фоторәсемнәре, кайбер документлары һәм карта – схемалар тупланган.

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның нәсел-нәсәбен, кардәш-ыруларын өйрәнүгә Зәкия Рәсулова бик күп көч куйды. Ул бөек Тукай эзләреннән йөреп күп җирләрдә булды. Арча—Әтнә якларын аркылыга-буйга айкап чыкты. Мәскәү, Ленинград, Казахстан, Ерак Көнчыгыш якларына барды. Шуларның нәтиҗәсе буларак, ул 1985 елда «Тукай эзләреннән» дип аталган китап чыгарды һәм анда шагыйрьнең әтисе һәм әнисе ягыннан булган нәсел җәдвәлләрен бастырып чыгарды. Аннан соң да Зәкия апа Тукай турында мәгълүматлар туплавын дәвам итте, яңа

табышларын газета-журналлар аша халкыбызга җиткерә килде. Әйе, милләтебезгә бик тә игелекле эш эшләп калдырды Зәкия Әхмәт кызы Рәсулова. Ул 1999 елның октябрь аенда үзе туган Казан шәһәрендә 83 яшенә җитеп вафат булды. Авыр туфрагы ана йомшак мендәр дә, җылы юрган да булсын.

Габдулла Тукай 1886 елның 14 (26) апрелендә элекке Казан губернасының Казан өязе Мәңгәр волостенә караган Кушлавыч авылында мулла Мөхәммәтгариф бине мулла Мөхәммәтгалим гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Мөхәммәтгариф 1864 елның 30 апрелендә Кышкар мәдрәсәсендә муллалыкка указ алып Кушлавыч авылының икенче мәхәлләсенә мулла итеп билгеләнгән була. Ул, истәлекләргә караганда, «уртача буйлы, коңгырт чәчле, зәңгәрсу күзле, матур борынлы кеше булган. Үзе телгә-сүзгә бик оста, мәзәкчел булып, кием-салымны да купшы кияргә яраткан. Башына кырпулы каракүл бүрек киеп, аны аз гына кыңгыр салып җибәрә торган булган». Мөхәммәтгарифның хатыны Бибигафифә Сираҗетдин кызы 1885 елның 28 апрелендә (яңа стиль белән 10 майда) бала тапканда кан китеп 42 нче яшендә вафат була. Шуннан соң Мөхәммәтгариф хәзрәт 8 яшьлек кызы Газизә, 13 яшьлек улы Мөхәммәтшәриф белән тол кала. Ул Зиннәтулла Зәйнелбәшир улы Әмиров дигән Өчиле авылы имамының Камилә исемле беренче хатыныннан туган Бибимәмдүдәгә өйләнә. Менә шушы никахтан Габдулла Тукай туа. Әтисе аны метрикә кенәгәсенә «Габдуллаҗан» дип теркәгән. Кызганыч ки, баланың әти-әнисе бик иртә үлеп китә. Әтисе Мөхәммәтгариф 1886 елның 29 августында (яна стиль белән 10 сентябрьдә), Бибимәмдүдә исә 1890 елның 18(30) гыйнварында бакый дөньяга күчәләр. Беренчесе — 44, икенчесе 25 яшендә була. Әтисеннән Габдулла 4 ай ярымлык, әнисеннән 3 яшь тә 7 айлык булып ятим кала. «Мәмдүдә озынчарак йөзле, сызылып киткән кара кыйгач кашлы, матур кылыч борынлы, төскә-биткә чибәр, матур буй-сынлы, кирәк чакта шигырь белән җавап бирә торган оста телле, үзе тегү-чигүгә маһир бер мөлаем сылу булган». Әйе, Габдулла Тукай әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да муллалар нәселеннән. Габдуллада зыялы затлар каны аккан. Әмма хәзергә кадәр «Тукаев» фамилиясенең кемнән килүе, ана Габдулла Тукай нинди мөнәсәбәттә булуы

ачыкланмаган. Шагыйрь нәселендә Тукаев — Тукаева фамилияләрен йөртүче бер кеше дә юк. Барысы да диярлек үзләренә фамилия итеп әтиләренең исемен алганнар. «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә «Габдулла Тукай» китабын чыгарып Ибраһим ага Нуруллин да моның ахырына чыкмады. Ул да элекке картлардан ишеткән риваятьләр белән генә чикләнүен белдерде. Берәүләре шагыйрьнең ерак бабалары арасында Туктаргали исемле кеше булуын һәм аны кыскартып Тукай дип йөртүләрен әйтәләр, икенчеләре Кушлавыч авылындагы Тукый тавын Тукайның борынгы бабасына бәйләп сөйлиләр.

Габдулланың мәктәп елларында Гарипов (Гарифов — әтисе Мөхәммәтгарифтан) фамилиясе белән йөрүе хакында истәлекләр бар (Ярулла Моради). Ни генә булмасын, кемнәрдер шагыйрь нәселендә Тукай исемле кеше булуын белгәннәр һәм тора-бара шуны Габдуллага да җиткергәннәр. Тукаев фамилиясе юктан бар булмаган, әлбәттә. Мәрхүмә Зәкия апа Рәсулова хезмәтләрендә шагыйрьнең нәселен күрсәткән менә мондый исемлек ярылып ята. Габдулла Тукай — аның атасы Мөхәммәтгариф, аның атасы Мөхәммәтгалим, аның атасы Шәмсетдин, аның атасы Мортаза, аның атасы Туктулы бабай. Кем белә, бәлкем әнә шул Туктулы бабайны Тукай дип йөргәннәрдер. Шагыйрьнең әтисе Мөхәммәтгариф бу хакта тәгаен гына белгәндер, билгеле. Бәлкем шул Туктулы бабайның атасы Габдуллаҗан булып, булачак шагыйрьгә исем дә шуның хөрмәтенә — җиденче буын бабасы хөрмәтенә бирелгәндер. Алдагы эзләнүләр моңа ачыклык кертер әле дип өметләник.

Габдуллаҗанны (Габдулланы) кыскартып Габдекәй дип атау гадәте булган. Габдекәйдән Габдукаев, Абдукаев, Тукаев фамилияләре ясалган очраклар бар.

Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдә ягыннан шәҗәрәдәге төп исемлек: Бибимәмдүдә, аның атасы Зиннәтулла, аның атасы Зәйнелбәшир, аның атасы Әмир (Әмирхан) була. Бу исемлектәге Зиннәтулла хакында замандашларының җылы сүзләре байтак. Ул китап яратучы, язу-сызу белән дә шөгыльләнүче кеше булган. Кайбер шигырьләре дә сакланып калган. Ул Пермь ягыннан, Гайнә иленнән Кышкар мәдрәсәсенә укырга килгән.

Соңыннан мөэзин булып Кушлавычта эшләгән. Ә инде Өчиле авылы мөселманнарының соравы буенча аларга имам буларак хезмәт итә. Менә шул хәзрәтнең Камилә исемле беренче хатыны аңа Бибимәмдүдә исемле бердәнбер кызын бүләк итә һәм озак та тормый вафат була. Бибимәмдүдә булачак бөек шагыйребезнең газиз анасы. Ул да дөньяга фәкать бер генә бала — Габдулланы гына таба. Шулай да ата-баба ягыннан Габдулла Тукай нәселенең шәҗәрәсе һаман тармаклануын дәвам итә. Әйтик, Тукайның апасы (ата бер, ана башка) Газизә Зәбирова, я булмаса әтисе белән бертуган Газизә Госманова, Фаизә Шәмсетдиноваларнын балалары, оныклары, туруннары хакында озын һәм күп итеп язарга мөмкин булыр иде. Мәсәлән, Зәкия апа Рәсулова язганча, Газизә Зәбированың алты баласы була. Шуларның берсе яшьтән үк үлә. Олы кызы Гайшә исә студент чакта вафат була. Вәли исемле улы СССР Фәннәр академиясенең тарих фәннәре ассоциациясе гыйльми секретаре. Аның Раҗия — медицина хезмәткәре, Сәлим — су асты көймәсе командиры, Рөстәм — инженер-механик, исемле балалары була. Газизә Забированың Гали исемле улы мехчы булган, гражданнар сугышында Чапаев дивизиясе составында сугыша. Аның Суфия, Рәшит, Рәисә, Рафаэль исемле балалары туып үскәннәр. Газизә апаның Фаизә исемле кызы Ленинградта «Эрмитаж»да фәнни хезмәткәр булып эшләгән. Ә инде кече улы Хөсәен югары белем алып төзүче-инженер һөнәрен үзләштерә. Ул Бөек Ватан сугышында башыннан ахырына кадәр катнаша, күп кенә орден-медальләр белән бүләкләнә. Аның өч кызы була. Әлфия белән Наил архитектор булалар. Төпчек кызлары Диләрә дә Мәскәү архитекторлар институтын тәмамлый, аннан соң Казан төзүче-инженерлар институтында хезмәт куя. Тукай — халык шагыйре, татар халкының мәшһүр улы. Ул үзенең иҗаты белән бөтен төрки дөньяга хезмәт итә. Без Тукайны бишектән үк ишетеп беләбез, аның шигырьләре, җырлары, экиятләре белән әсирләнеп үсәбез, һәр җанда шагыйрьгә булган җылылык арта бара. Шагыйрь һәм Кеше буларак, Тукай - мәңге кабатланмас, мәңге уникаль шәхес. Күкләрне яктыртып, һава сафландырып узган яшендәй гомере белән ул халкыбызның әдәби, мәдәни, рухи күгендә җуелмас эз калдырды.

**Йомгаклау өлеше.**

“Илен белмәгән – игелексез, халкын белмәгән – холыксыз, нәселен белмәгән – нәсәпсез” дип юкка гына әйтмәгән халкыбыз.Адәм баласына җиде бабасын белү фарыс, дигәннәр борынгылар. Шул вакытта гына кеше туган иленең, туган төбәгенең, туган йортының үткәнен, үз халкының чыгышын белә. Шуның өчен дә безгә бүген үз шәҗәрәләребезнең тарихын, туган авылның үткәнен белү, өйрәнү, туган төбәкнең тарихи урыннарын хөрмәт белән саклау кирәк.

Шәҗәрәләр безгә халкыбызның үткән юлын, чал тарихын сөйли. Шәҗәрәләр арта барган саен, без үз җиребездә яшәгән халыкның кәсебен, аралашу культурасын, гореф – гадәтләрен беләбез.Йомгак ясап шуны әйтәсе килә: һәр кеше Тукайны өйрәнергә, аның турында күбрәк белергә тиеш.Тукайның тормышын һәм иҗатын тикшереп язган хезмәтләр байтак санда. Аны укып сөйләргә бик күп вакыт таләп ителә. Шулай да алга куйган максатыма ирештем дип уйлыйм. Мин бу фәнни эшемдә үземә бик күп яңа мәгълүмат алдым, белемемне тагын да тулыландырдым.

**Әдәбият:**


1. Гарифуллин Дамир. Шәҗәрәләр: 1 китап. - Яр Чаллы, 2002.-160 б.
2. Г.Тукай. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. VII том. ТаРИХ- 2002.
3. Г.Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы. Н.Г.Юзиев.Казан Татарстан китап нәшрияты 2003.
4. «Казан утлары» 1986 ел, апрель
5. «Мәйдан» журналы 2006,апрель.
6. Рәсулова З.Ә. Тукай эзләреннән. Казан:Тат.кит. нәшр., 1985.- 141 б.
7. «Салават күпере» журналы 2004 ел, апрель
8. «Ялкын» журналы 2006 ел, апрель

## II НЧЕ ЮНӘЛЕШ.

## Г. ТУКАЙНЫҢ КҮПКЫРЛЫ ИҖАТЫ

***Гыйбадуллина Г.Ш.,***
***Кол Гали исемендәге милли китапханә мөдире***

# ТУКАЙ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮДӘ КОЛ ГАЛИ ИСЕМЕНДӘГЕ МИЛЛИ КИТАПХАНӘНЕҢ ЭШ АЛЫМНАРЫ

"Тукай моңа кадәр тарих белгән
Татарларның иң бөеге..."
*М.Кәрим*

Тукайны зурлау, аның бөеклеген буыннардан-буыннарга җиткереп бару – безнең изге бурычыбыз.

Әдипнең күпкырлы иҗатын өйрәнү, пропагандалау – ул Татарны, аның борынгы тарихлы, бай эчтәлекле әдәбиятын, газиз ана телебезне һәм рухи мирасыбызны өйрәнү, олылау дигән сүз.

Шәһәребез быел бик зурлап 45 еллык юбилеен бәйрәм итәргә әзерләнә. Кол Гали исемен йөртүче милли китапханәбезнең дә ачылуына 30 нчы августта 5 ел тула. Кечкенә генә юбилей...

Бераз гына аның тарихын исегезгә төшереп узыйк. Ул 30 нчы августта, шәһәрнең 40 еллык юбилеена тәгаенләп, Г.Тукай исемендәге үзәк китапханәнең татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеген һәм Кол Гали исемен йөртүче 30 нчы санлы татар китапханәсен берләштереп оештырылып тулы куәтенә эшләп китте.

Алдыбызга куелган максатка ирештек: әдәби әсәрләр аша халкыбыз күңеленә матурлык һәм сафлык иңдерү, шәһәрдәшләребезне рухи яктан баетырга, милли үзаң уятырга тырышу - үз нәтиҗәләрен бирә дип әйтергә тулы җирлек бар.

Китапханәбезнең шәһәрдә үз йөзе бар: бирегә олылар да, кече яшьтәгеләр дә бик теләп йөриләр, без үткәргән мәдәни чараларда актив катнашалар.

Китапханәнең төп байлыгы – аның китап фонды һәм белешмә – библиографик аппараты. Хәзерге көндә китап

фондында 19473 данә басма исәпләнә, шуның 9379 татар телендә, бу сан барлык фондның 49 %ын тәшкил итә.

Фондны баетып, китап укучыларыбызның ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү өчен 78 исемдә вакытлы матбугат алдырабыз, шуның 33е татар телендә.

Китапханәбездә 6 китапханәче, 1 библиограф эшли. Барыбыз да – 2 дәүләт телендә бик рәхәтләнеп сөйләшә, эш-гамәл кылуыбыз белән горурланып эшлибез.

Шәһәребездә бердәнбер милли китапханә буларак, эшчәнлегебезнең беренче көннәреннән үк анда һәрчак Тукай рухын саклау, китап укучыларыбызны аның иҗаты белән якыннан таныштыру максаты белән янып яшибез. Бөек шәхес турында күбрәк укыган, күбрәк белгән саен ул күңелгә һаман якыная, иҗаты яңа яктан ачыла бара. Бөек Тукаебызның искиткеч бай, күпкырлы иҗаты бүген дә үсештә, кулланылышта.

Иң мөһиме, китапханәбезнең Тукай иҗатын пропагандалауда инде сыналган, уңай нәтиҗәләре дә күренгән үз традицияләре бар, аны сүрелдерми дәвам иттерә алырлык сәләтле хезмәткәрләребез – китапханәчеләребез бар.

Китапханәбездә бөек әдипнең китаплары һәрвакыт кулланылышта йөри. Бүгенге көндә китапханә фондында аның төрле елларда дөнья күргән сайланма әсәрләре (4 томлык; 5 томлыгы), тормыш юлын һәм иҗатын яктырткан энциклопедия-дисклар коллекциясе, мультимедия җыентыклары, DVD китаплар, шагыйрьнең рус телендә дөнья күргән әсәрләре, балалар өчен нәшер ителгән әкият-поэмалары, төрле телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләре, иҗатына күзәтү ясалган фәнни монографияләр, әдип турында хатирәләр һәм истәлекләр тупланган җыентыклар, фотоальбомнар, күренекле шәхесләр һәм шагыйрьләребезнең Г.Тукайга багышланган шигырьләре, юбилейлары уңаеннан дөнья күргән газета-журнал материаллары укучыларыбызның күпсанлы сорауларына тулы җавап табарга ярдәм итәләр.

Укучыларның кызыксынуларын, сорауларын тулырак канәгатьләндерү өчен “Габдулла Тукай” исемле электрон мәгълүмат базасы ярдәмгә килә һәм бүгенге көндә анда 964 язма

теркәлгән.

Татар һәм рус телләрендә традицион карточкалы картотека да алып барыла. Анда Тукай турында тулы материал тупланган. Мәгълүматлар тематик рубрикаларда, ә рубрикалар эчендә кире (обратная) хронологик тәртиптә бирелгән һәм алар актуаль темалар белән даими тулыландырылып торалар. Менә яңа гына кертелгән рубрикаларның кайберләре:

“Тукайның 125 еллыгына”

“Тукай һәм дин: бүгенге көн күзлегеннән...”

“Тукай премиясе лауреатлары – безнең якташларыбыз”

“Тукайның мәхәббәте”

“Түбән Камада Тукайга багышланган урыннар” һ.б.

Боларга өстәп, китапханәбездә “2011 ел – Бөек Тукай елы” исемле тематик папка эшләнеп, анда ксерокс аша чыгарып, газета-журнал битләрендә дөнья күргән, бик кызыклы язмалар тупланды. Папка укучыларыбыз өчен зур ярдәмлек булып тора.

Һәркем шагыйрьне үзенчә кабул итә, һәркемнең үз Тукае бар: дөньяны аңлый башлаган бала өчен ул – әкиятче, мәктәп укучысы өчен – намуслы һәм тырыш бала, каләм тибрәтүче өчен – остаз, ә күпчелек өчен – яраткан шагыйрь. Көндәлек эшебездә менә шушы хакыйкатьне истә тотып эшлибез.

Ел саен, Тукай көннәре уңаеннан, төрле мәдәни чаралар уздырыла. Һәръелны шагыйрьнең тормышы һәм иҗатына багышланган мәгълүматле бик бай китап күргәзмәләре оештырыла. Аларның исем-атамалары гына да бу эшкә бик зур җаваплылык тоеп, иҗади якын килүебезне күрсәтә.

“Тукай – безнең шигъри кыябыз,
Ә тормышта – рухи кыйблабыз...”

“Без – бәхетле, без шагыйрьле халык
Без – Тукайлы халык мәңгегә.”

“Тукай җырларында яши халык җаны
Тел бетмәсә, көй үлмәсә – мәңге даны...” кебек күренекле шагыйрьләребезнең шигъри юлларыннан алынган өзекләр китап укучыларыбызның игътибарын үзенә тартып торалар.

Әйтергә кирәк, бу күргәзмәләр һәрвакытта да әңгәмәләр, китапларга күзәтүләр, шигърият сәгатьләре, викториналар кебек

сөйләм формалары белән тулыландырылып укучыларга Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты хакында бик күп яңа мәгълүмат ирештерәләр.

Ел саен бу кургәзмәләрне ***Экспресс-күргәзмәләр*** тулыландыра. Һәръелны, Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатларының исемнәре билгеле булу белән, китап укучыларга бу мәгълүматны тиз арада ирештерү ниятеннән чыгып эшләнә. "***Алхәбәр! Ел лауреатлары"*** дип исемләнгән бу күргәзмәләр укучыларыбыз арасында зур популярлык казандылар.

Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә башлануга 50 ел тулу уңаеннан, ***"Габдуллаҗан, миңа да бит кичә***

***Бирелгән синең исем...***" (күренекле шагыйрь Мөдәррис Әгъләм шигыреннән алынган юллар) дип аталган зур ***мәгълүмати-иллюстратив күргәзмә*** оештырылды һәм анда әдәбият өлкәсендә бу бүләккә лаек шәхесләр хакында язмалар, фотоматериаллар, аларның әсәрләре куелды. Күргәзмә библиографыбыз тарафыннан төзелгән "Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә – 50" дип исемләнгән библиографик күрсәткеч белән тулыландырылды.

Шагыйрьнең 120 еллык һәм 125 еллык юбилейлары арасында Г.Тукайның һәрберебез бик яратып укучы, бик популяр әсәрләре язылуга да 100 ел тулды. Шул әсәрләргә багышлап аерым күргәзмәләр оештырылып, алар янында төрле формадагы күп кенә мәдәни чаралар үткәрелде.

...Һәркемгә бишектән үк таныш булган, хакыбызның теленә, тарихына, гореф-гадәтләренә гимн булып яңгыраучы ***"Туган тел" шигыренең язылуына 100 ел тулуга багышлап***

***"Үлемсез дастаннар кебек***

***Моңлы син, туган телем"*** исемле күргәзмә оештырылып, аның янында китапханәбезнең иң яшь китап укучылары арасында ***шигырь уку*** бәйгесе оештырылды.

Тукайның тормыш юлын чагылдырылган автобиографик ***"Исемдә калганнар"*** әсәренә багышлап оештырылган ***бер китап күргәзмәсе "Йөз ел бүе исебездә"*** дип исемләнде һәм аның янында китапханәбезнең "Кол Гали варислары" клубы

әгъзалары: 8нче мәктәп нең 8 сыйныф укучылары өчен ***әңгәмә*** һәм укучылар көче белән оештырылган ***театральләштерелгән тамаша*** күрсәтелде, шагыйрьнең ***шигырьләре яттан*** укылды.

***"Шүрәлегә – 100 яшь"*** ***күчмә күргәзмәсе*** белән 1нче һәм 7нче санлы балалар бакчаларына барып, сабыйларны Тукай иҗаты белән таныштырдык. Күрәсез, чаралар төрле яшьтәге китап укучыларыбызга адресланган.

Шушы эшләребезне милли сәясәтнең зур бер өлеше итеп саныйбыз. Бала кечкенәдән Тукайны белә һәм аның күңелендә шагыйрь иҗатына мәхәббәт уяна икән, димәк ул киләчәктә дә милләтен хөрмәтләп яшәячәк, дип уйлыйбыз.

Түбән Кама китапханәләр берләшмәсендә уздырылучы Тукай бәйрәменең үзенчәлеге – аның бер-ике көн белән генә чикләнмичә, ай буе дәвам иттерелүе.

2008 елда Тукай айлыгы кысаларында галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе, мин аны Тукай белгече дип тә атар идем, Татарстан Фәннәр академиясе вице президенты Азат Шәймулла улы Зыятдиновка багышланган ***"Милләт зыялылары белән көчле"*** исемле ***очрашу кичәсе*** үтте.

Күп санлы китап укучыларының теләген искә алып, бу комплекслы чара Тукай исемендәге үзәк китапханә залында ***яшьләр белән очрашу*** итеп, кабатлап оештырылды. Азат абый бик рәхәтләнеп Тукаебыз турында сөйләде, илһамланып шигырьләрен яттан укыды һәм Тукай шигырьләрен сәнгатьле уку конкурсында җиңгән катнашучыларны бүләкләү, кызыксындыру өчен үзенең шәхси премиясен тапшырды.

2010 елда Тукай атналыгы кысаларында узган чара Түбән Кама шагыйрьләре иҗатына багышланып ***"Шагыйрьләр язга елмая"*** дип исемләнде һәм шәһәребездә яшәп, "Кама таңнары" әдәби берләшмәсендә иҗат белән шөгыльләнүче ***13 шагыйрә иҗатын колачлады***. Бу ***әдәби-музыкаль кичәгә*** тәгаенләп оештырылган

"***Мин - шагыйрә ,***
***Мин шигырьләр язам,***
***Минем бакчам – шигъри түтәлләр***" исемле ***күргәзмә*** үзенең зәвыклылыгы, мәгълүмати яктан бай булуы белән китап

укучыларыбызның игътибарын үзенә җәлеп итте.

Соңыннан шагыйрьләргә багышланган бу язмалар һәркайсына аерым папка итеп ясалып, мәгълүмати-белешмә фондын тулыландырды.

Сөекле шагыйребез иҗаты бүгенге заман укучылары күзлегеннән ничек бәяләнә? Укучыларыбыз бөек Тукаебызның тормыш һәм иҗат юлын әйбәт беләләрме? Шушы сорауларга җавап эзләү һәм шагыйрь иҗатын пропагандалау йөзеннән, Түбән Кама китапханәләр берләшмәсе җирле телерадиокомпания белән берлектә ел саен, “***Тукай иҗатын иң яхшы белүче”гә конкурс-викторина*** үткәрә. Һәм бу бәйгегә әзерлек йөзеннән, ***“Тукай турында иң кызыклы сорау”*** конкурсы оештырыла, җыңгән сораулар НТР каналы аша игълан ителә, сорауга җавап бирүче чыганак күргәзмәдә урын ала.

Безнең китапхәнә хезмәткәрләре бу ике бәйгедә дә катнашып, викторина сорауларына дөрес җаваплар биреп, мактаулы урыннар алып бер отсалар, Тукайга багышланган күп санлы әдәбият белән танышып, мәгълүмат туплап, интелектуаль белем багажларын да ныгыталар.

Безнең үзәкләштерелгән китапханәләр берләшмәсе “Туган тел” дигән махсус программа белән эшли.

Туган телебез – Тукай теле – милләт язмышы икәнлеген аңлап эшлибез. Телне музейларга куеп саклап булмый, аның яшәеше бүгенге көндә һәр кешенең үзеннән тора.

Безнең бурыч – саф һәм матур туган телебезне ата-аналарыбыздан кабул итеп алу, аны бөтен нечкәлекләре белән өйрәнү, бөтен байлыгын саклау, үстерү һәм балаларыбызга, оныкларыбызга, киләчәк буынга җиткерү.

Татар теленең ролен күтәрү, кулланылышын киңәйтү максатыннан татар телендәге китапларны пропагандалауга, укучыларны татар язучылары һәм аларның әсәрләре белән даими таныштырып баруга аеруча игътибар итәбез.

Туган телне үстерүне без Тукай телен үстерү итеп кабул итәбез һәм бу юнәлештә массакүләм информацион чараларны киң кулланып эш итәбез.

Китапханәбезнең эш алымнары, уздырылган һәр чара

җирле матбугат битләрендә дөнья күрә. Китап пропагандалауда булышканнары, үткән һәр чараны тәфсилле, үтемле итеп халыкка ирештергәннәре өчен без җирле “Туган як” газетасы хезмәткәрләренә рәхмәтлебез. Юкка гына бу басманың да беренче саны Тукай туган көндә чыкмаган бит! Без бергәләшеп милләтебезгә хезмәт итәбез.

Җирле телевидиенең НТР каналы белән дә иҗади бергәлектә эшлибез. “Яңалыклар “ тапшыруы китапханәбез эшчәнлеген даими яктырып, эчтәлекле сюжет - программалар күрсәтә. Бу безнең китапханәгә яхшы реклама ролен үти һәм укучыларыбыз санын ишәйтүгә ярдәм итә.

Һәръелны  Тукай һәйкәле каршында шигърият бәйрәме гөрләп үтә. Шагыйрь туган көнне зурлап бәйрәм итү – матур бер традициягә әйләнде. Инде 5 нче ел бу чараның сценарийсын әзерлибез һәм алып баручы сыйфатында да чыгыш ясыйбыз. Бу без, китапханәчеләрдән, җаваплылык, тырышлык, эзләнүләр һәм профессиональ осталык таләп итә.

Башкарылган эшләребез күп кебек тоелса да, бу әле диңгездәге тамчы гына, безгә Тукайны чын-чынлап өйрәнү заманы җитте. Совет чорындагы мәктәпләрдә таралган, юылган-рафинацияләнгән Тукайдан баш тартып, чын бөек Тукайны өйрәнү заманы җитте.

Бүген Тукай иҗатын белмәү – элекке заманнардагы кебек җаһиллек булып саналырга тиеш, дип уйлыйбыз. Тукай иҗаты белән  яхшы таныш булган, аның шигырь-поэмаларын, ул тудырган сурәт-манзараларны күңеленә сендергән татар кешесе беркайчан да: “Я учился в русской школе, и, к сожалению, не знаю родного языка и Тукая”, я булмаса “Кому он нужен ваш татарский – кухонный язык”,- дип әйтә алмас. Дөресрәге ул дәрәҗәдә надан булмас.

Татар өчен авыр заманда Тукаебызга таянып исән калыйк һәм аның дәрәҗәсен тагын да арттыру юлы белән үзебезнекен дә үстерик. Әдәбиятыбызны Тукаебыз күтәргән югарылыкта саклыйк!

Бергә булыйк, бердәм булыйк!

Игътибарыбыз өчен зур рәхмәт!

***Кунаев А.Ю. Түбән Кама нефтехимия көллияте студенты,***
***Фәнни җитәкче: Ризванова Ф.М.,***
***телләр кафедрасы укытучысы***

## МНОГОГРАННОСТЬ ТВОРЧЕСТВА Г. ТУКАЯ

Имя Габдуллы Тукая известно не только в Татарстане, но и далеко за её пределами. Его знают все, кто ценит искусство, кто любит поэзию. Творчество Тукая многогранно: он поэт и публицист, литературный критик и общественный деятель.

Тукай - молния, на миг и на все времена озарившая жизнь татар начала XX столетия. Габдулла Тукай прожил не полных 27 лет, но оставил богатое творческое наследие, которое навсегда вошло в сокровищницу литературы народов нашей страны. Благотворное влияние Тукая на духовную жизнь татар так глубоко и всесторонне, что с годами интерес к творчеству и личности поэта лишь возрастает.

Тукай жил и творил в очень сложный период общественного развития, в период ожесточенной борьбы за демократизацию литературного языка. Несмотря на это, он сумел заложить твердый фундамент для развития национального литературного языка и дать ему правильное общее направление.

Наследие Тукая очень велико: более 400 стихотворений и 9 поэм; 350 рассказов, очерков и воспоминаний.

Поэзия Тукая привлекает читателя прежде всего прекрасным языком и стилем. До Тукая у татар не было поэта, стихи которого звучали бы так легко и непринужденно, к тому же они очень просты и доступны. Его жизнь и среда давали множество тем: неприятие окружающего, жалобы, горести и печали народа, ощущение его трагедии, смех сквозь слезы - всего не охватить. Поэтому хочется остановиться лишь на тех особенностях его поэзии, мимо которых пройти просто невозможно.

Воинствующая сатира. В то время, когда поэт находился в стенах религиозного медресе и знал лишь турецкую литературу, читал религиозные, пронизанные суфизмом книги, и ему грозила опасность попасть под их влияние, уже тогда в первых

своих стихах он открыто выступал против религиозной поэзии. Молодой поэт тогда жил в городе Уральске, он открыто издевался над ишанами и муллами. В стихотворении этого периода « Голос с кладбища мюридов» он пишет:

Ишаны губят наш народ, а я не знал об этом. Они не любят наш народ, а я не знал об этом.

Время шло, менялось, события развивались все быстрее, и борьба поэта с вредным наследием прошлого принимала все более острые формы. В то время никто из современников Тукая не осмелился бы написать такие строки:

Закрыл глаза, согнул свой стан, намотан на башку тюрбан, Как сена стог на голове, - хоть и скотина, а ишан. («Ишан»)

В другом стихотворении он срывает маску с личины муллы:

Было время! Жил я праздно средь обжорства и обмана, Но чистейшими считали всех служителей Корана («Жалоба муллы»).

У Тукая необычно сильно сатирическое начало. И пользовался он им мастерски. Каждое событие вызывало ответную реакцию. У него много стихов, бичующих образованных шарлатанов, национальных кровопийц и ложных друзей народа.

Тема любви. Любовь не есть главное в его поэзии, но несмотря на это той любви, которая отражена в его стихах, вполне хватило бы тому, кто этому чувству посвятил все свое творчество. Поэт специально не занимался этой темой, о любви писал как бы мимоходом. Однако во многих стихах он говорит об этом чувстве. Примером может служить стихотворение «Хвала творцу, субханалла!», где поэт свои чувства к возлюбленной сравнивает с незапятнанными чувствами ребенка. Стихотворение написано просто. Однако изображенная в нем полная луна, детское восприятие окружающего мира так сливаются с ощущениями поэта, что создается гармоническое единство.

А стихотворение «Любовь» в этом отношении является образцовым. В нем поэт говорит:

Всех татарских стихотворцев обогнать могу легко. *Я,* бичом любви гонимый, я, страдавший столько лет.

Кто, как я, знаком с томленьем, с вечной жаждою души? Мук бессонных скрытый пламень каждой строчкою воспеть.

В стихотворении «К портрету» поэт свою любимую ставит даже выше солнца, обращаясь к которому восклицает:

Солнце, солнце! Ты стыдиться станешь бледности своей, Посмотрев на эти щеки спелых яблоков алей.

Любовь в стихах Тукая редко поднимается в заоблачные высоты, но и не является игрушкой. Она для поэта реальное земное чувство, присущее человеку.

Природа. Разнообразные картины природы, ее различные состояния и краски играют в жизни человека немалую роль, влияют на его настроение. Точно так же Тукай обладал чувствительным сердцем, умел выражать тончайшие движения души, однако в изображении картин природы он все же испытывал определенные трудности. И это вполне понятно.

Если мы обратимся к жизни Тукая, то почти не найдем там разнообразия: сиротство, обездоленность, ничтожество окружающей среды, холод одиночества, - вот что сопровождало его в жизни — все, что он увидел, а дальнейшая его жизнь прошла в номерах гостиницы, расположенной в одном из уголков старой Казани.

Целительный воздух башкирских степей он вдохнул только в конце жизни, когда уже безнадежно болел чахоткой. Так что Тукаю не удавалось долго общаться с природой, но даже в этом случае он вполне может соперничать с поэтами, которые этой темой занимаются сознательно. Вспомним хотя бы зимнюю картину в стихотворении «Нищий» или в том же «Буране». Мало того, что эти вещи прекрасны по стилю, глубоки по мысли и чувству, изображением хлопьев снега, ветра, бурана, круговерти, борьбы стихии создается ощущение грозной музыки.

*Было тихо, но внезапно небеса застлал туман.*
*Снег взметнулся, как безумный, снег пошел, подул буран.*
*Снег слепит глаза нещадно, бьет в лицо с ветвей слетая;*
*Ветви кажутся ворами, черным волком - тьма ночная.*

*Целый день змеею мертвой в тишине спала дорога.*
*Вдруг - буран! Скажи, откуда это буря и тревога?*
*Джинны, что ль, с цепи сорвались и бесчинствуют впотьмах?*
*Или порвалась перина, на которой спит аллах?*

В цикле о природе музыка и ритм ощущаются особенно сильно. Возьмем хотя бы поэму «Шурале», то место, где изображается деревня Кырлай:

*Есть аул вблизи Казани, по названию Кырлай.*
*Даже куры в том Кырлае петь умеют... Дивный край!..*

Отрывок этот является лучшим доказательством того, что Тукай, когда это требовалось, мог мастерски описать и картины родной природы. Изображение леса в том же «Шурале» просто поражает. Не пустой лес изображает поэт, а наполняет его зверьем, травами, различными персонажами народной фантазии, мифическими существами.

Много здесь тропинок тайных и сокровищ, говорят. Много здесь зверей ужасных и чудовищ, говорят. Правда ль это? Бесконечен, словно небо, древний лес, И не меньше, чем на небе, может быть в лесу чудес.

Г. Тукая чаще всего воспринимают лишь как поэта, между тем и прозаическое наследие его представляет собой художественную ценность. И если Тукай писал о себе, что он «молнией сверкал» и «гремел грозой», то это касается его прозы ничуть не меньше, чем его поэзии.

В знаменитой статье-лекции «Народная литература» Тукай утверждает народные истоки новой татарской литературы. Жизнь народа - вот неисчерпаемый источник тем и сюжетов; язык народа, его песен, сказок, пословиц, поговорок - тот язык, на котором следуют писать - такова главная идея статьи.

В числе первых своих публицистических работ, как некое счастливое откровение, Габдулла Тукай представил читателям свой татарский перевод знаменитой брошюры «Царь-голод» известного революционера А.Н.Баха.

Тукай при необходимости легко меняет оружие метких строк на не менее острое оружие публицистических и критиче-

ских статей, фельетонов. И еще неизвестно, поэзией или прозой сильнее он разил своих идейных врагов.

Поэзию и прозу Тукая невозможно рассматривать порознь — они представляют единое целое. И все его стихи, поэмы, статьи, фельетоны, автобиографические очерки, заметки и письма отмечены могучим духом поэта - человека с высоким чувством собственного достоинства, независимого и волевого, бесстрашного и самоотверженного.

**Литература:**


1. Габдулла Тукай. Стихотворения и поэмы: пер. с татар. Издательство «Советский писатель», 1988г.
2. Лирика Тукая, авт: Наипь Лаисов, Татарское книжное издательство, 1976г.
3. Слово о Тукае. Писатели и учёные о татарском народном поэте/ Таткнигиздат, 1986г.
4. Книги и люди. Иследование/предисл. докт. ист. наук М.А. Усманова. - Казань: Татарское кн. Изд-во, 1985г.



***Сәйфуллина Л.З. 14 нче лицей укучысы***


## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ КҮПКЫРЛЫ ИҖАТЫ

Татарстан Республикасы президенты Рөстәм Миңнеханов татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның истәлеген һәм иҗади мирасын мәңгеләштерү максатыннан 2011 елны Татарстан Республикасында Габдулла Тукай елы буларак игълан итте. Габдулла Тукай исеме Татарстанда гына түгел, аннан бик ерак төбәкләрдә дә билгеле. Аны сәнгать, шигърият сөюче һәркем белә. Тукай иҗаты күпкырлы: ул шагыйрь һәм публицист, әдәби тәнкыйтьче һәм җәмгыять эшлеклесе. Габдулла Тукай 1886 елның 26 нчы апрелендә Кушлавыч авылында дөньяга килә. Тормышының 1892-1895 елларын кечкенә Апуш Кырлай авылында уздыра. Нәкъ Кырлай чорында ул халкына һәм туган җиренә карата булган мәхәббәтен

тулысынча аңлый. “Кырлай авылы тормышка минем күзләремне ачты”, - дип яза соңыннан шагыйрь үзенең истәлекләрендә. Кырлай чорындагы балачак тәэсирләре аның иҗатында онытылмас эз калдыра.Тугыз яшьлек Габдулла 1895 елда апасы янына Җаек (Уральск) шәһәренә килә. Анда ул мәдрәсәгә укырга керә, шушы шәһәрдә беренче шигырьләрен яза. Тукай ныклы ихтияр көченә, тумыштан килгән сәләткә ия шәхес булган. Кечкенә Урал шәһәрендә яшь Тукай бөек рус шагыйрьләре - Пушкин һәм Лермонтов иҗаты белән таныша. Аларның шигырьләре шагыйрьнең йөрәген яулап ала. Ә инде 1905 елда ул үзенә генә хас “Хөррияткә”, “Дусларга бер сүз” исемле шигырьләрен яза. Бу шигырьләрендә алга китешне, халык азатлыгын яклаучы Тукай ачыла.1907 елның көзендә Тукай милли мәдәният һәм тарих бишеге булган Казан шәһәренә килә. Анда үзенең эшчәнлеген иҗтимагый һәм иҗади мәсьәләләр чишүгә багышларга исәпли. “Нурлы Казан” шагыйрьне үзенең бай, аның өчен бик мөһим мәдәни мөхите белән җәлеп итә. Тукайның сәләте чәчәк аткан, шәхес буларак формалашкан, шөһрәт казанган чоры Казан еллары була.Тукайның беренче иҗат тәҗрибәләре үк XX гасыр башының фикерләүче яшьләренә хас булган омтылышлар һәм эзләнүләр белән сугарылганнар. Милләтнең авыр хәлен күрү һәм аны төзәтү юлларын табу теләге – бу омтылышларны хәрәкәткә китерүче төп көч шул була. Мәгърифәтчелек идеяләре белән яна башлаган яшь шагыйрь, әлбәттә инде, туган халкының түбәнлеккә төшүенең, артталыгының асыл сәбәпләрен бөтен тулылыгында күрә һәм аңлый алмый. Яшь Тукай мәгариф системасының артталыгы, мәдрәсәләрдә техник белемнәр бирелмәү, төгәл фәннәр укытылмау татар тормышының төп проблемалары дип санаучылар сафында була. Милли матбугат, европача типтагы уку йортлары ачу, әдәбият һәм сәнгатьне үстерү ярдәмендә туган халкының алгарышына ирешү – яшь шагыйрьнең ихлас теләкләреннән. Иң беренче басма шигыре булган «***Голүмнең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран… (1905) (Гыйлемнең бакчасында күңел ачып йөрик) дип башланып киткән әсәрендә Тукай нәкъ менә шул идеяләрне

байрак итеп күтәрә, «голүмлә дөньяи дотды япон, нәмсә, французлар»дан, ягъни «гыйлем белән дөнья тоткан япон, немец, французлардан» үрнәк алырга чакыра. Матбугатның һәм әдәбиятның халыкны алга җибәрүдәге ролен идеаллаштыру, патша хакимиятенең Беренче рус буржуаз-демократик революциясе шартларында биргән матбугат ирегенә зур өметләр багълау яшь Тукайның беркатлы иллюзияләреннән. «Шималь яктан чыгып бәркъ, орды бер нур…», «Хәзерге халемезә даир», «Хөррият хакында…» кебек шигырьләрендә бу идеяләр аеруча ачык чагыла. Бишенче-алтынчы еллардагы шагыйрь иҗатының публицистик аһәң белән өртелгән, сәяси темалар белән сугарылган, авторитетларны санга сукмаучы ачы сатирик юнәлешле булуы күзгә ташлана. Тукайның журналистлык эшчәнлеге белән дә тыгыз бәйләнгән әлеге юнәлеш (бу елларда ул Камил Мотигый тарафыннан оештырылган матбугатта актив хезмәттәшлек итә) аның иҗатында соңгы елларга кадәр дәвам итте һәм үстерелде. Гомеренең азагына кадәр публицистик мәкаләләр белән татар вакытлы матбугатында катнашып килгән әдип җәмгыятьтә яшәп килгән кимчелекләрне камчылау аша үз милләтенең уянуын, бәхетле булуын тели иде. Бөтен күңеле белән туган якка омтылган, милләтенең иң матур сыйфатларын күңелендә якты истәлек итеп саклаган әдипнең лирик герое Казанга кайткач та «җанга ягымлы» шул хисләрне җырлый. 1907 елдан башлап шагыйрь иҗатында мондый йомшак җылылык, лирик хисләрне чагылдыру, моң һәм сагыш хисе арта, беренче чор иҗатыннан аермалы буларак декларатив риторика урынына, кеше күңеленең тирәнлеген, андагы уй-тойгылар хәрәкәтен тасвирлау көчәя, лирик герой үтә бер якынлык белән балачагына, туган ягына әйләнеп карый. «Пар ат» һәм «Шүрәле»дән соң мондый хисләрнең сурәтләнеше аеруча калку булып «Туган җиремә» шигырендә күренә. Бу әсәрдә дә без «кайту» мотивлары белән очрашабыз, бу яктан караганда ул «Пар ат»ның дәвамчысы, аның лирик «игезәге» булып тора. Тукай шигъриятендә лирик агым көчәю белән аның каләме мәхәббәт темасына торган саен активрак мөрәҗәгать итә, бу

тема аңарда романтик, юмористик һәм реалистик аспектларда ачыла.

1909-10 елларда Тукай балалар әдәбияты өлкәсендә актив эшли башлый. Бу елларда ул балалар өчен язылган үз әсәрләреннән төзелгән «Балалар күңеле» (1909) һәм «Күңелле сәхифәләр» (1910) исемле ике китап бастыра. Болардан тыш әле аның тезмә һәм чәчмә әсәрләрен туплаган «Яңа кыйраәт» (1909) исемле уку китабы һәм «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле дәреслеге дә басыла. Соңгысында башка язучыларның балалар өчен язган талантлы әсәрләрен дә туплый. Тукайның балалар өчен язган шигырьләре һәм әкиятләре, чәчмә әсәрләре яшь буында кешелеклелек, тырышлык, максатка омтылыш кебек сыйфатлар тәрбияләүне максат итеп куйдылар. «Эш» (1909), «Япон хикәясе» (1909), «Бәхетле бала» (1909), «Эш беткәч уйнарга ярый» (1909), «Имтияз алган бала» (1910), «Кызыклы шәкерт» (1910), «Эшкә өндәү» (1911), «Сабитнең укырга өйрәнүе» (1912), «Сабыйлар җыруы» (1912) кебек шигырьләрендә әдип белемгә омтылышны, мәгърифәтне зурлый, тырышлыкның уңышка илтүе турында сөйли. Хайваннарга, үсемлекләргә, гомумән табигать дөньясына кешелекле мөнәсәбәт, гуманистик караш тәрбияләү Тукайның балалар өчен язган әсәрләрендә шулай ук мөһим урын алып тора. «Кошларга» (1909), «Кошчык» (1909), «Бала белән күбәләк» (1909), «Фатима белән сандугач» (1910), «Бичара куян» (1910), «Күгәрчен» (1910) шигырьләре шундыйлардан. Балалар өчен язылган шигырьдә төп фикернең ачык булуы, аңлаешлылыгы принцибы Тукай шигърияте өчен төп принциплардан. Башкаларга золым кылу, көчсезләрне рәнҗетү шагыйрьнең дидактик эчтәлекле балалар өчен иҗат ителгән әсәрләрендә дә тәнкыйть ителгән сыйфатлардан. Әдип хәтта зәгыйфьлек кебек бик үк уңай булмаган сыйфатны да залимлектән өстен куя («Күгәрчен»), көчсезләрнең тапкырлыгына һәм зирәклегенә дан җырлый («Кәҗә белән сарык»). Тукай әкиятләренә халык иҗатыннан килә торган көчсезнең көчлене җиңүе, финалда гаделлек тантана итүе хас. «Кәҗә белән сарык», «Шүрәле» кебек әкиятләрендә автор конфликтның юмористик планда чишелешен тасвирлый, бала күңеленә

сак карый, аны мондый очракларда ихтимал булган психологик травмалардан саклый. Шагыйрьнең ниндидер аерым дидактик максат куймаган әсәрләре дә хайваннар дөньясына җылы караш, игелекле мөнәсәбәт тәрбияләрлек итеп корылганнар. «Шаян песи», «Ялкау маэмай», «Гали белән кәҗә» шигырьләре шундыйлардан. Шагыйрь иҗатында табигать тасвирлары, пейзаж лирикасы, ел фасыллары турында мәгълүмат бирүче әсәрләр дә байтак. Аларда Тукайның балалар психологиясен нечкә белүе чагыла, балалар теле белән сөйли белү осталыгы күренә.

Тукай җиде-сигез еллык иҗат гомерендә зур биеклекләргә иреште, татар шигърияте яңа эчтәлек белән баетты, шигъри теленең камиллеге, фәлсәфи фикерләвенең оригинальлеге, хисләренең ихласлылыгы таң калдырырлык югарылыкта иде. Әлбәттә, ул яулаган үрләрнең нигезендә иң беренче чиратта тумыштан килгән табигый талант ята иде. Тукай таланты татар әдәбиятында моңарчы күрелмәгән вакыйга, дөнья әдәбиятларында да сирәк очрый торган күренеш булып чыкты. Ләкин чын асылташ яктылыгы белән балкысын өчен талантның чарлануы, шомаруы да таләп ителә иде. Гомер юлын армый-талмый туган халкыңа хезмәт итү дип санаган әдип үзеннән элгәре булган көнчыгыш әдәбиятын да, рус әдәбиятын да җентекләп өйрәнде, шагыйрьнең поэтик теле, камил шигъри формасы төрле әдәби йогынтылар нәтиҗәсендә формалашты, эчтәлек һәм хис белән баеды, үзенә генә хас әдәби бизәкләр белән тулыланды, Тукай шигъриятенең оригинальлеге төрле катламдагы йогынтылар аша үсте. Иҗатының башлангыч чорында ул, әлбәттә, үзеннән алда булган әдипләргә ияреп, Көнчыгыш әдәбиятының традицияләрен дәвам иттерде. Бу традицияләр яшь Тукайның шигъри телендә дә, форма һәм эчтәлек юнәлешендә дә ачык чагылалар иде. Әйе, башка халыкларның әдәбиятларына сокланырга, алардагы үз күңеләңә аваздаш якларга кызыгып карарга мөмкин, әмма синең әдәбиятыңны да башкалар үз итсеннәр, яратсыннар дисәң, аны туган милләтеңнең сәнгатьчә фикерләү чаралары ярдәмендә үстерү зарур. Моны гамәлгә ашыруы – Г.Тукайның әдәбиятыбыз алдында күрсәткән тагын бер зур игелеге. Халык шагыйрьнең тәнкыйть өлкәсендә дә туры сүзле, гадел, аяусыз,

таләпчән булуы, бигрәк тә үз-үзенә ташламалар ясамавы, аның шәхесенә карата ихтирамны тагында үстерә.Күренекле шагыйрь С.Хәкимнең мондый сүзләрен искә төшерәсе килә: “Тукайдан өйрән дә өйрән...”. Шагыйрьнең бөтен тормышы, үзе әйткәнчә, соңгы көннәренә кадәр хезмәт белән үтте. Г.Тукайны татар халкы гына түгел, башка төрки халыклар да үзләренең остазлары итеп санныйлар. Габдулла Тукай- шагыйрь, тәнкыйтьче, остаз, дәүләт эшлеклесе, публицист, журналист, җәмәгать эшлеклесе.

Бүген олы әдип образы, иҗаты кешеләрне яңа иҗат биеклекләренә рухландыра.Г.Тукай әсәрләренә язылган музыкаль әсәрләр: “Шүрәле” - Ф.Яруллин балеты, “Су анасы” - Әнвәр Бакиров, “Кисекбаш” – Р.Гобәйдуллин. Р.Батулла “Сират күпере” (драма) Т.Миңнуллин “Без китәбез, сез каласыз”(драма). Ә.Гаффар - “Соңгы сәгать” (драма). И.Юзеев- “Очты дөнья читлегеннән”. Тукай образы музыкада: Әнвәр Бакиров - “Тукай” операсы, М.Мозаффаров - “Тукай истәлеге”, Р.Кәлимуллин - “Тукай истәлеге”. Тукай онытылмас шәхес һәм бөек шагыйрь булып кала бирә. Аның мирасы, заманга аваздаш булып, бүген дә яши, бүген дә уйландыра, сөендерә. Кеше балачактан Тукайны укып үсә, олыгайгач та аннан аерылмый. Шагыйрьнең катлаулы һәм авыр тормышы белән таныш булучылар аның шигырьләрен укып соклана: алар аерым моң белән тулы һәм матурлар. Аның иҗаты үлемсез һәм иксез-чиксез, ул татар мәдәниятенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән аерылгысыз!

**Әдәбият:**

1. Әмирхан Р. Төзәтмикче Тукайны/ Р.Әмирхан Иманга тугрылык-Казан. Тат.кит.нәшр., 1997.

2. Тукай Г. Шүрәле/ Г.Тукай. Әсәрләр: биш томда Т.1.-Казан: Тат. кит. нәшр., 1985.

3. Тукай Г. Пар ат./ Г.Тукай. Әсәрләр: биш томда Т.1.-Казан: Тат. кит. нәшр., 1985.

4. Нуруллин И. Габдулла Тукай.-Казан: Тат. кит. нәшр., 1979.

5. Тукай Г. Туган җиремә./Г. Тукай. Әсәрләр: биш томда Т.1.-Казан: Тат кит.нәшр., 1985.

6. Тукай Г. Бәйрәм вә сабыйлык вакыты/Г.Тукай Әсәрләр: биш томда Т.1.-Казан: Тат.кит.нәшр., 1985.
7. Бикмөхәммәтов Р. Милли әдәби тел./ Р.Бикмөхәммәтов. Поэзиябезнең сулмас чәчәкләре-Тат. кит.нәшр., 1960.
8. Тукай Г. Шигырьләребез./Г.Тукай Сайланма әсәрләр.-Казан: Тарих, 2002.
9. Мәгариф, 11/2011.

***Портнова Э.В. 35 нче лицей укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Хуҗанбердиева Ч.Т.,***
***КФУ аспиранты, татар теле укытучысы***

## Г. ТУКАЙ ИҖАТЫНДА МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

Даһилар гомере гасырлар белән генә исәпләнә. Татар шагыйре Габдулла Тукайның да тууыны да 2011 нче елда 125 ел тулды. Гади кешеләр өчен бу еллар чиксез күп булып тоелырга мөмкин. Әмма Тукай өчен түгел...

Бурычым итеп, Габдулла Тукай иҗатын өйрәнеп, аның милләт хакындагы уй-хыялларын, фикерләрен белүне, Тукайның бу мәсьәләгә карата карашларын билгеләүне, әдәби тәнкыйть мәкаләләрен өйрәнүне саныйм. Тикшерүдә төп чыганак итеп Габдулла Тукай әсәрләренең биш томлыгын алдым.

Егерменче йөз башындагы татар әдәбияты тарихын, гомумән татар халкы тарихын Габдулла Тукай исеменнән башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

Тукай әдәбият мәйданына милләт җырчысы булып аяк басты һәм гомеренең ахырына хәтле шушы кыйбласыннан читкә тайпылмады.

Габдулла Тукайның матбугатта басылып чыккан иң беренче шигыре үк милләткә багышланган була. “Гыйлемнең бакчасында күңел ачып йөрик...” дигән юл белән башлана бу шигырь.

Иҗатының беренче елларыннан ук Тукай татар халкы өчен әһәмиятле булган проблемаларны күтәрә алган. Шагыйрь аңлап эш итә: әгәр халыкны тормыш баткаклыгыннан чыгарырга, аны башка цивилизацияләр югарылыгына күтәрергә телисең икән, аңла, иң беренче эшең синең – мәгърифәт, аң, белем булырга тиеш. Бу проблема шагыйрьнең иҗатында бер җеп рәвешендә сузылып бара. Ул шигырьләрендә укучыларны бәхеткә ирешү юлында аң-белемне үстерү кирәклегенә өйрәтә. Аның фикеренчә, белем юлында тырышлык кую кешене матурлый, аны алга илтә. Комсызлыкка каршы Тукай белемлелекне куя.

Эш барышында 2 дистәдән артык теоретик әдәбият өйрәнелеп, шагыйрьнең шигырьләре тикшерелде һәм түбәндәге нәтиҗәләр ясалды:

- Габдулла Тукай иҗатында төп урынны милләт проблемасы алып тора. Шагыйрьнең нинди генә әсәрен алып карама, һәрберсендә диярлек милләт язмышы чагыла. Аның “Туган тел”, “Китмибез” кебек шигырьләре татар халкы гимны булып яңгырарлык әсәрләр.
- 1905 нче елгы революция Тукайның иҗатына уңай тәэсир ясый. Тукай иҗаты бу чорда күтәрелеш вакытын кичерә. Шагыйрьнең каләме бигрәк тә ялкынланып милләт язмышын чагылдыра. “Чөнанча bездә Камил әл Мотыйгый”, “Мөхәрриргә”, “Милләткә” кебек бик күп әсәрләр шушы чорга карый.
- Габдулла Тукай әсәрләрендә халыкның бүгенгесен генә түгел, ә үткәнен дә бик дөрес сурәтли. Аның “Милли моңнар”, “Сайфия”, “Олуг юбилей мөнәсәбәтләре белән халык өмидләре” кебек шигырьләрендә татар халкының үткән тормышы, газап-михнәтләре – барысы да чагылыш тапкан.
- Габдулла Тукай милләтенә чын күңеленнән ышана. Ул әле татар халкының да “йолдыз сәгате” җитәчәгенә өметләнеп иҗат итә.
- Шагыйрь бәхетле булып, тигез, тату гомер итү өчен татар халкының берләшүе кирәк дигән идея үткәрә. Бу бигрәк тә аның

“Кичке азан”, “Иттифакъсыз бәдәвам” кебек шигырьләрендә ачык күренә.
- Тукайның матбугатка чыккан беренче шигырьләре гарәп, фарсы, борынгы төрки һәм госманлы төрекләре сүзләре белән тулы. Бигрәк тә 1908 нче елга хәтле язылган әсәрләре алынмалар белән чуарланган. Тукай күп кенә гарәп-фарсы сүзләреннән, урынына карап, шул заманның әдәби теле мөмкинлек биргән дәрәҗәдә файдалана, телнең чит сүзләргә бай булып тулы яңгырашлы рифмалар табуны да бик нык җиңеләйтә, рифмаларны төрләләндерергә ярдәм итә. Тукай иҗатында аерым гарәп-фарсы сүзләре генә түгел, кайбер очракларда хәтта гарәпчә һәм фарсыча берничә сүздән төзелгән бөтен гыйбарәләр дә урын ала. Тукай иҗатында мондый тел чуарлыгы, әлбәттә, тәнкыйтьчеләр, тел белгечләре, замандашлары тарафыннан төрле бәя алды. Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Җамал Вәлиди, Әхмәт Исхаклар бу мәсьәләгә карата үз фикерләрен вакытлы матбугатта бастыра килделәр. Хәзерге вакытта да Тукай шигъриятенең тел-стиль үзенчәлекләре галимнәребез тарафыннан тикшерелә килә;
- Шагыйрь үзенең башлангыч чор иҗатында урта гасыр суфичылык, дини-әхлакый, мәгърифәтчелек һәм госманлы төрек әдәбиятларының традицияләрен дәвам иттерде, шуңа күрә бу чорда иҗат ителгән әсәрләренең идея-эчтәлек, форма ягыннан Шәрык йогынтысында булуын күрергә мөмкин, шигырьләрендә гарәп-фарсы алынмаларының еш очравын (аеруча иҗатының беренче елларында) XX гасыр башында гадәти күренеш буларак карарга кирәк. Вакытлар үтү белән шагыйрь әсәрләренең теле үзгәрә, камилләшә, тагын да халыкның җанлы сөйләм теленә якыная, татарлашу процессын кичерә.

Җәмгыятьтә, әдәбиятыбызда үзгәрешләр барган дәвердә галимнәребез алдына Тукай мирасын яңадан барлау, иҗатының әлегә кадәр күрелмәгән яңа якларын өйрәнү мәсьәләсе килеп басты. Шуны күздә тотып, һәр елны шагыйрьне бүләк иткән матур яз көннәрендә Тукай җәмгыяте (Тәлгать Галиуллин), Татарстан язучылар берлеге (Илфак Ибраһимов) һәм Тукай музее (Р. Аймәт) белән берлектә, бер төркем галимнәрне,

әдипләрне, әдәбият сөючеләрне җыеп, фәнни – гамәли конференция оештыра. Биредә Тукай мирасының яңа катламнары ачыла, иҗатын өйрәнүнең үзенчәлекле юнәлешләр билгеләнә.

Тукай мирасы – беркайчан кыйммәте югалмаячак, киресенчә, еллар үткән саен кадере генә арта барачак милли хәзинәбез. Татар халкы данлы тарихын, фаҗигале, ачы язмышын да, киләчәген дә Тукай шигырьләреннән эзләгән, алардан җан тынычлыгы, рухи азык алган. Һәр яңа буын Тукайны үзенчә ача, үзенчә өйрәнә.

Мин Тукайны татар халкының кап-кара төнендәге йолдыз дип атар идем. Бу йолдыз аз гына вакыт яктырса да, аның яктылыгы хәтта безнең көннәргә дә килеп җиткән. Мин ышанам: әле бу йолдыз сүнмәячәк, ул һаман яначак, киләчәк буыннар да әле аны сагынып сөйләячәк.

Тукай иҗаты – татар халкының йөз аклыгы ул. Ә Тукае булган милләт – зур һәм талантлы милләт икәнлегенә ышанам мин. Һәм әлбәттә, бу милләтнең һичшиксез үткәне бар һәм киләчәге дә булачак.

**Әдәбият:**


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Вәлиди Җ. Тукаев хакында берничә сүз / Тукай турында замандашлары. – Казан, 1960 . – 259-263 б.
3. Галиуллин Т. Тукай һәм XX гасыр татар поэзиясе.–Казан, 1997.-28-32б.
4. Ганиева Р. Каршылыклы еллар авазы // Казан утлары. – 1983. -№ 6. -174-183 б.
5. Ганиева Р. Тукай иҗатында реализм мәсьәләләре. – Казан, 1987. -10 б.
6. Ганиева Р. Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. – Казань: изд-во КГУ, 1988.
7. Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2008. – 254 б.

8. Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1985-1986.
9. Заһидуллина Д. Әдәбият кануннары һәм заман.- Казан: Тат. кит. нәшр., 2000.- 271 б.

***Магданурова Л.И. Түбән Кама нефтехимия көллияте укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Булатова Ф.В.,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ТАТАР МУЗЫКАСЫ

Г. Тукай таланты, Тукай иҗатының әһәмиятен зур шигърият дөньясы белән генә чикләү аның XX гасыр татар яңарышында тоткан ролен тарайту булыр иде. Аның иҗаты күп төрле. Татар профессиональ музыка сәнгате барлыкка килүендә, балет жанры тууында Тукай иҗатының роле зур. Тукай булмаса, С.Сәйдәшев, Ф.Яруллинар булыр идеме икән? Мәшһүр композитор Ф.Яруллинның “Шүрәле” балеты Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург театрларында гына түгел, күп кенә Европа илләренең сәхнәләрендә шаулап бара, татар музыкасын дөнья аренасына алып чыга. Музыка Г. Тукайның авыр тормышында шатлык та, таяныч та була. Ул моң шагыйрьнең күңелендә һәрвакыт олы урын алып торган. Замандашларының хатирәләре буенча, кечкенә Габдулла алты яшьтән үк Яңа Кырлай авылында татар халык көйләрен җырлап йөри. Ә тугыз – ун яшьләрендә апасы Газизә Зәбировага: “Апа, минем белмәгән җырым юк”, - ди.

Шагыйрь җырга битараф булмаган. Ул күңеле хозурланган, кәефле көннәрендә дә җырларга яраткан. Аның укытучысы К. Мотыйгый яшь Тукай турында: “Җырлый җырлый үзе теләгәнчә торырга тотынган иде”, - дип әйтә. Тукай уйлы – моңлы чакларында да күңел сагышын түгеп җырлый торган була. Ә ятим Габдулланың тормышында мондый көннәр аз булмый.

Тукай мәдрәсәдә дә җыр яратучы, җырлый белүче шәкертләрне якын итә, алар белән дуслаша.

Җыр һәм шигърияткә мәхәббәт аны сәяси сәбәпләр нәтиҗәсендә Төркиядән качкан һәм Уральск шәһәрендә урнашкан Габделвәли Әмрулла белән бәйли. Замандашларының истәлекләре буенча, Тукай татар халкының борынгы озын көйләреннән “Кара урман”, “Зиләйлүк”, “Тәфтиләү”не җырларга яраткан.

Борынгы озын көйле татар җырларын аеруча яраткан Тукай соңыннан болай дип яза:

Валлаһи, җандай күрәм мин искеләрнең җырларын,
Күкрәгемдә саклыйм, әйтерсең, рәсүлнең тырнагын.

Тукай, күрәсең, татар халык җырларын күп белгән. 1910 елда басылган “Халык моңнары” дигән татар халык җырлары тупланмасы да һәм 29 җырдан торган “Җыр дәфтәре” дә шушы фикерне раслыйлар. Соңгысы 1946 елда гына табыла.

Тукай башка халыкларның музыкасы белән дә кызыксынган. Аның тарафыннан тупланган 29 халык җыры арасыннан башкорт язучысы Афзал Кудаш берничә башкорт җырын да танып ала. Бу – “Эстәрле”, “Сәрмәсән буе”, “Агыйдел” җырлары. Тукай Уфада башкорт җырчысы Әхмәтфәиз Даутовның җырлавын ишетеп таң кала. Бу уңайдан ул аны язып алырга кирәклеген әйтә.

Кайбер замандашлары Тукайның Моцартның “Төрек маршы”н бик яхшы җырлавын әйтәләр. 1907 елның 11 мартында Уральск шәһәренең “Казан” кунакханәсе залында концерт була. “Халык күп килгән иде. Татарлар күбрәк иде, руслар – азрак... Тукаев белән Сираҗетдин Билюков әфәнделәр, милли киемнәргә киенеп, тезләрен шәрекъчә бөгеп утырып, “Кичке азан” шигырен укыдылар”, - дип яза “Фикер” газетасы. Пәрдә дүртенче тапкыр күтәрелгәч, Г. Тукаев хәерче булып киенгән Хәкимҗан Йосыповка карап “Теләнче” шигырен укый. Алтынчы пәрдәдән соң Тукай, үзенә кушылырдай музыкантлар булмавын күреп һәм: “Мин үзем балалайка, үзем гитара”, - дип халыкка мөрәҗәгать итеп, “Төрек маршы”н җырлый.

Тукайның Уральскидагы тормышының күп өлеше мәдрәсәдә уза. Яшь шагыйрь 1905 – 1907 еллардагы Беренче Россия революциясен дә Уральскида каршылый.

Билгеле булганча, Беренче Россия революциясе чорында мәдрәсәдә укучы шәкертләр арасында мәктәп эшләре реформасы өчен хәрәкәт башлана. Шуңа күрә дә биредә “Беренче сада”, “Икенче сада” һәм “Өченче сада” кебек беренче революция гимнары таралган була. Менә шушы революция мохиты Тукайның ул еллардагы иҗатына йогынты ясый.

Шагыйрьнең шул еллардагы иҗатында рус революцион җырлары йогынтысы да күренә. “Мәдрәсәдән чыкккан шәкертләр ни диләр” дигән шигырьнең егерме икенче куплетында “Марсельеза” кушымтасының тәэсире сизелә:

Алга, алга, алга табан,
Алга, дуслар, басыйк табан.
Раздайся, клич, мести народной!
Вперед! Вперед! Вперед! Вперед! Вперед!
(“Рабочая марьсельеза”)

1907 елда Казан шәһәренә кайткач, Тукай әдәби даирәгә бик тиз кереп китә, татар шагыйрьләре һәм язучылары Ф. Әмирхан, Г.Камал, С. Рәмиев һ.б. белән дуслаша.Тукай үзе Казанда яшәгәндә, Уральск мәдрәсәсендәге кебек, халык алдында җырчы буларак чыгыш ясамый.

Ләкин Тукай Казанда композитор, дирижер һәм этнограф А. А. Эйхенвальд (1875 – 1952) белән таныша. Бу менә ничек була: “Без Казан янындагы урманда таныштык, - дип сөйләгән Эйхенвальд. – Җепшек, карлы көн иде. Без чыпчыкларга ипи валчыклары бирә идек. Яшебездәге аермага карамастан, дуслашып киттек. Мин өлкәнрәк идем. Еш кына икәүләп татар авылларында йөрдек. Ул миңа җырларны язып алырга булыша, крестьяннарга минем нигә болай эшләвемне аңлата иде”. Л. Рубинштейн мәкаләсеннән без Тукайны бөек рус җырчысы Ф. И. Шаляпинны белүен дә күрәбез.

Тукай музыка белән тәэсирләнеп яши, ул аның йогынтысы белән теге яки бу әсәрен иҗат итә. Аның иң яраткан

көйләреннән берсе сузып – сузып җырлана торган “Зиләйлүк” була.

“Милли моңнар” шигырен Тукай халык җыры “Әллүки”нең көчле тәэсирендә иҗат итә. Бу хакта М. Гали менә ничек яза: “Көннәрнең берсендә Тукай “Болгар” номерларында үз бүлмәсендә утырганда бик матур бер җыр тавышы ишетә. Ирексездән, ул шул тавыш килгән якка китә. Ишеге ярык кына калдырып ачылган бер бүлмәгә килеп туктый һәм аның ишек яңагына башын куеп, тирән уйларга калып бүлмә эченнән килә торган җыр тавышын тыңларга керешә. Ул бүлмә Сәгыйть Рәмиев бүлмәсе булып чыга һәм кроватьта моңлы калын тавыш белән “Әллүки” көенә җырлаучы кеше дә Тукайның иң яраткан җырчысы шагыйрь Сәгыйть Рәмиев була. Башка вакытта Сәгыйть белән күбрәк шаярып сөйләшергә яраткан Тукай, бик җитди кыяфәт белән аның бүлмәсенә керә дә:

- Әй, туган, нинди көй җырлыйсың син? Синең җырың минем аяк буыннарыма китте, - ди. Сәгыйть бер дә исе китмәгән кыяфәт белән: “Нигә, белмисеңмени,”Әллүки”ич, - ди. Шуннан соң Тукай үзенең “Милли моңнар” шигырен язып, Сәгыйтьтән “Әллүки” көенә җырлата һәм үзе дә аны шул көйгә яки “Зиләйлүк” көенә җырлап йөри”.

Тукайның музыкага мәхәббәте тирән һәм саекмас була. Бу хакта шагыйрь үзе менә ничек әйтә:

Җырлый – җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
“Без китәрбез, сез каласыз!” - дип җырлармын,
Җәсәдемнне туфрак берлә күмгәндә дә.

(“Шагыйрь")

Авыру шагыйрьнең көчләрен көннән-көн күбрәк кимерә. Тукай уйлы-моңлы көннәренең берсендә гаҗиз калып әйтеп куя:

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

(“Кыйтга”)

Һәм үзенең авыру хәлен элегрәк җырлап юанган көннәре белән чагыштырып болай ди:

Бар иде ялгыз калып, җырлап юанган чакларым,

Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм!
("Хәстә хәле")

Музыка шагыйрьне сабый чагыннан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр озата бара. Ул Тукайның күңел юанычы да, сагышы да, иҗатында киңәшче дә була.

Шагыйрьнең музыкаль булуы аның шигырьләрендә чагылыш таба, аларның табигый, көйле агышын, җырлап торуын китереп чыгара. Бу турыда беренче тапкыр Тукай вафатыннан соң 1913 елда басылган "Тукай – халык шагыйре" дигән мәкаләсендә Гали Рәхим әйтә: "Укучыларны шигырьләрнең тагын бер үзенчәлеге җәлеп итә – алар гадәттән тыш музыкаль".

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: Тукай үз әсәрләрен көйләп язган, бу аның шигырьләренә үзенчә бер музыкальлек биргән. Һәм шуңа аның шигырьләре үзләре үк көйгә ярашып тора. Халык Тукай шигырьләрен җырлый. Бу яктан караганда, Тукай, төрле заманнарда яшәсәләр дә, рухлары белән аңарга якын булган һәм француз Ренессанс чорында иҗат иткән Пьер де Ронсарга (1524 – 1585) һәм испан шагыйре Гарсиа Лоркага (1898 – 1936) бик якын тора.

**Әдәбият:**


1. Тукай турында истәлекләр. Төз. И. Нуруллин, Р. Якупов. – Казан.1986,24 б.
2. Тукай турында истәлекләр. 33 б.
3. Тукай . Әсәрләр. 4-том, 256 б.
4. Тукай . Әсәрләр. 1-том, 238 б.
5. Шунда ук. 4-том, 186 б.
6. Тукай Г. Әсәрләр. 5-том, 53 б.
7. Казан утлары, 1986, №4, 182 б.
8. Нафигов Р. И. Күрсәтелгән хезмәт. 47 б.
9. Урал, 1907, 12 гыйнвар, №3. Шигырь "Фикер"нең 1907, 21 гыйнвар санында күчереп басыла.
10. Тукай турында замандашлары. – Казан, 1960, 126, 127 бб.
11. Рубинштейн Л. Шаляпин и Тукай. – Дружба народов, 1969, №9, с. 285

12. Гали М. Тукай җырчы һәм җыр-музыка сөюче. – Совет әдәбияты, 1943, №4, 37 б.

***Кыяметдинова Д.Ф. 10 нчы мәктәп укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Гыйльметдинова Г.М.,***
***югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## ТУКАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР

Татар әдәбияты үсешенә Габдулла Тукай кебек зур өлеш керткән башка каләм иясен табу кыен. Габдулла Тукай шагыйрь генә түгел, бәлки халкыбызның теле дә, моңы да, рухы да, язмышы да.

Вакыт безне 1913 елның апреленнән ераклаштыра бара. Әмма гаҗәеп хәл: Тукай безгә көннән көн якыная. Аның шигырьләрен укыган саен укыйсы килә. Укыган саен үзеңә бер яңалык ачасың. Шуңа күрә Тукай шигырьләрен без инде белеп бетердек дип әйтеп булмый. Минем уйлавымча, бу тема бүгенге көндә дә бик актуаль.

Татар халык шагыйре Габдулла Тукайның яшәү һәм иҗат юлы күптәннән өйрәнелеп килә. Әдәбият галимнәре күп кенә китаплар, монологик хезмәтләр яздылар. Бу өлкәдә эшләүчеләрдән И. Нуруллин, Ф. Ибраһимова, Ә. Әлиева, Р. Гайнанов, Л. Гайнанова, Р. Башкуров, Р. Нәфыйгов һәм башкаларны күрсәтергә була. Ләкин Тукай иҗаты шулкадәр күп тармаклы, аны әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе.

Инде бөек шагыйребезне бездән аерган XX йөз дә “узган гасыр” булып тарихка кереп калды. Әмма Габдулла Тукайның шәхесе һәм ул тудырган үлемсез әсәрләр һәрвакыт халык күңелендә, “безнең гасырда” калалар.

Шагыйрьнең инде 1905 нче елда ук унлап әсәре дөнья күрә. Аларны укып чыккач, яшь авторны җәмгыятьтә бара торган хәл-әхвәлләр кызыксындыруын күрәсең. Бу яшьтәге егет сөю, мәхәббәт, чибәр кызлар турында язса да урынлы булыр иде. Ләкин Тукай каләмен башка нәрсәләр хәрәкәткә китерә.

Шигырьләрен укыган саен аның талантына, һәр сүзне урынлы куллануына гаҗәпләнәсең һәм яңа Тукайны ачасың.

Мин Тукай шигырьләрендә кулланылган урын, җир атамаларына, ягъни географик атамаларга игътибар иттем һәм аларны язучының ни өчен куллануын тикшерергә булдым.

Шагыйрьнең 40 шигырендә географик атамалар таптым. Тукай бер генә атаманы да урынсыз кулланмаган. Сәламәтлеккә туймау, матди яктан шактый кысынкылыкта яшәү күңеле белән әллә кайларга ашкынган Габдуллага сәяхәт кылырга да ирек бирмәгән. Ләкин шуңа да карамастан шагыйрь географияне, шул урыннарда булган тарихи вакыйгаларны яхшы белгән һәм шигырьләрендә күрсәтә алган.

Мин шигырьләрдә кулланылган географик атамаларны болай итеп тупладым:

| № п/п | Шигырь исеме | Язылган елы | Географик атамалар |
|---|---|---|---|
| 1 | Дусларга бер сүз | 1905 | Петербург |
| 2 | Сорыкортларга | 1906 | Кавказ таулары |
| 3 | Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр | 1907 | Яурупада (Европада) |
| 4 | ни диләр? | 1907 | Казан, Ханкирмән, |
| 5 | Теләнче | 1907 | Астырхан |
| 6 | Пар ат | 1907 | Казан |
| 7 | Туган җиремә | 1907 | Казан арты |
| 8 | Китмибез | 1907 | Русия |
| 9 | Гыйлавә | 1909 | Идел |
| 10 | Милли моңнар | 1907 | Болгар, Агыйдел |
| 11 | Шүрәле | 1908 | Казан арты, Кырлай |
| | Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш | | Казан, Печән базары, Хиҗаз, Җиддә, Мәккә, |
| 12 | Япун хикәясе (Буренинннан) | 1909 | Мәскәү, Кабан, Бохара |
| 13 | Мәҗрух указ | 1910 | Япунья |
| 14 | Зур бәшарәт | 1910 | Хиҗаз, Өфе |
| | | | Петербург, Нью-Йорк, |
| 15 | Ник? Нигә? | 1910 | Берлин, Лондон |
| 16 | Яз хәбәре (русчадан) | 1910 | Болак, Орынбур |
| 17 | Төркия янгын эчендә | 1911 | Ак диңгез |
| 18 | Авыл җырлары, өченче көлтә | 1909 | Төркия |
| 19 | Авыл җырлары, дүртенче көлтә | 1910 | Казан, Мәскәү, Токио, |
| 20 | Авыл җырлары, бишенче көлтә | 1911 | Идел |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 21 | Поезд барган көйгә | 1911 | Казан, Варшау |
| 22 | Һазиһи касидәтен фи мәдхи | 1912 | Казан, Мәккә |
| 23 | Мостафа | 1912 | Себер, Сембер |
| 24 | Казан мулласы һәм булачак | 1912 | Төркия, Истамбул |
| 25 | депутат | 1912 | Петербург |
| 26 | Авылда авырып яту | 1912 | Амрика |
| 27 | Бәрәңге вә гыйлем | 1912 | Амрика, Яурупа |
| | Казан вә Кабан арты | | Казан, Кабан |
| | Казан вә Казан арты | | Казан, Чистополь, |
| 28 | | 1912 | Спас, Тәтеш, Чабаксар, |
| 29 | | 1913 | Мамадыш, Малмыж, |
| 30 | Өч хакыйкать (Майковтан) | 1913 | Казан арты |
| 31 | Суык | 1911 | Мәскәү |
| 32 | Казан | 1908 | Кабан күле, Печән |
| 33 | Шигърият һәм нәсер | 1907 | базары |
| | Тотса мәскәүләр якаң | | Казан |
| 34 | Безне урынсыз яманлыйлар | 1912 | Хаҗитархан |
| 35 | | 1910 | Мәскәү |
| 36 | Күк сыер | 1913 | Бохара, Каргалы, |
| 37 | Мигъраҗ | 1907 | Мәдинә, Мәккә |
| | “Аргымак” көе | | Әтнә |
| 38 | Авыл хатынының бала | 1907 | Мәккә |
| 39 | тирбәткәндә өмидләре | 1906 | Казан, Мәскәү, |
| 40 | Бер гәзитә идарәсе хәленнән | 1912 | Петербург |
| | Япониянe мөселман идарә | | Бохара |
| | итәчәкме? | | Петербург |
| | Балкан көйләре | | Япония |
| | | | Балкан, Төркия, |
| | | | Әдернә, Истамбул |

Мин бу шигырьләрне тагын менә мондый өч төркемгә бүлдем:

1) Казан, татар дөньясы белән бәйле атамалар.
2) Русия белән бәйле атамалар.
3) Чит илләр белән бәйле атамалар.

Билгеле, бу атамаларның һәркайсы татар милләте язмышы белән бәйләнгән.

“Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре” (1907) исемле шигырь халыкның муллага мөнәсәбәтен ачык чагылдыра. Муллалар, иң элек, гыйлем ияләре. Ә Бохарада укып кайтканнары бигрәк тә гыйлемле булган.

*Әлли-бәлли итәр бу,*
*Бохарага китәр бу,*
*Бохарадан кайткачтын,*
*Мулла булып җитәр бу*, - дип язган Тукай да.

1907 нче елда язылган “Пар ат” шигыре Габдулла Тукайның Казанга килү хыялларын чагылдыра. Шигырь “Лермонтовның “Тройка” шигырен уку тәэсиреннән”, - дигән искәрмә белән басылган. Моны шигырьнең беренче юлыннан ук күрәбез:

*Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;*

Тукай Казанга зур өметләр баглый һәм хыялындагы хисләрен шигырь юлларына сала.

Менә бервакыт кучерның: “Тор, шәкерт, җиттек Казанга, алдыбызда бит Казан!” – дигән тавышы яңгырап китә.

*Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна:*
*“Әйдә чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на! на!”*
*Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан:*
*И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!*

Шигырь Тукайның Җаектан Казанга чыгып китәреннән 5 ай элек язылган.

Тик аның гомеренең соңгы көннәрендә язган шигырендә бөтенләй капма-каршы Казанны күрәбез.

*Ут, төтен, фабрика – завод берлә кайный Казан;*
*Имгәтеп ташлап савын, сау эшчеләр сайлый Казан.* (“Казан”, 1913)

Тукай бар нәрсәдән хәбәрдәр кеше булган һәм Казанга, туган җиргә багышланган шигырьләрдә урын, җир атамаларын урынлы кулланганын без ачык күрәбез.

“Туган җиремә” шигырендәге бу юлларга шагыйрьнең туган ягына булган ярату хисләре сыеп беткән бит.

*Айрылып китсәм дә синнән гомремнең таңында мин,*
*И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.*

“Казан вә Казан арты” шигырендәге географик атамаларга игътибар итик әле. Шигырь Казанга мәдхия җырлау белән башланып китә һәм аның бөтен як өчен үрнәк булып торучы булуына ишарә итә:

*Нур ала синнән бөтен як: Чистополь, Спас, Тәтеш,*
*Һәм Чабаксарга, Мамадышларга Чар, Малмыж катыш.*

Ләкин үз туган җиренең ярлылыгына, караңгылыгына йөрәге әрнегән шагыйрь менә бу юлларга нинди олы мәгънә сала:

*Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артын кара:*
*Нур чәчәсең бар өязгә, үз өязең кап-кара.*

Тукайның күңеленә Казан арты бик якын һәм ул атаманы "Шүрәле" әкиятендә дә куллана:

*Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр;*

*"Кырлай Тукайны үстергән. Тукай шуңа рәхмәт рәвешендә, шагыйрь булгач, Кырлайны үзенең әсәрләрендә мәңгеләштергән," - дип яза Сибгат Хәким.*

Казан шәһәре искә алынган шигырьләрендә шагыйрь Кабан күле атамасын да еш атый. Тукай Казанда "Болгар" номерының Кабан күленә таба карап торган 40 нчы бүлмәсендә бик озак яши һәм шагыйрь бу атаманы кулланмый кала алмый, билгеле.

*Кай заманда, кайсы телдә булса да мәшһүр Казан,*
*Искә керми калмый һич тә шундагы бер күл – Кабан.*
("Казан вә Кабан арты", 1912)

*Бер очын учлап, Кабанга чумды ул,*
*Туп-туры шуннан коега тотты юл.*
("Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш", 1908)

"Суык" (1913) шигырендә шагыйрь январь суыгы турында, Казанның төрле кәсеп кешеләренең суыкка мөнәсәбәтләре турында язса да, аларның шул суыкта үзләрен ничек тотуларына бәйле картиналар иҗтимагый тормышны күз алдына китерәләр. Һәм моңа инде географик атамалар да ярдәм итә.

*Байлар кигән тиен толып, төлке толып,*
*Үз фикеренчә, Печән базар күрке булып;*
*Суык инде; Кабан күле чынлап катты;*
*Юргаларга башлар инде байлар аты;*

"Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш", "Милли моңнар", "Мәҗрух указ", "Ник?Нигә?", "Шигъріять һәм нәсер"

шигырьләрендә дә без татар дөньясы белән бәйле урын, җир атамалары белән очрашабыз.

“Милли моңнар” шигырендә Болгар һәм Агыйдел буйларына таралган милли хисләр турында сүз барса, “Мәҗрух указ” (“Җәрәхәтләнгән указ”) шигырендә *“Дәваларга Өфе якка юнәлдем”* дигән юллар указын саклап калу өчен Уфага Духовное собраниегә баручыга ишарә булып тора.

Тукай туган милләтенә зур өметләр баглый. “Дусларга бер сүз” шигырендә дә, милләтнең хәлен җиңеләйтү өчен, кулга-кул тотынышып эшләргә, көрәшергә өнди. Алга киткән башка милләтләрнең хәленнән үрнәк алып, “егъла-тора” алга таба атлыйк дип өнди. Моның өчен безнең мәнфәгатьләрне кайгыртучы депутатлар сайлап Петербургка җибәрү, башкалада “кирәкләрне сорау” кирәк ди.

*Һәр милләтләр максудларын хасил итә,*
*Депутатлар ясап, Петербургка китә;* (“Дусларга бер сүз”, 1907)

Тукай курыкмыйча өстен катлауларны, кеше хакын ашаучы, изүче сыйныфларны тәнкыйтьли һәм чагыштыру өчен урын, җир атамаларын куллана.

*Боларның һәрбере Каф яки Кавказ таулары микъдар;*
*Болар ни йотмаган инде, беләмсең, Миңлебай бабай!*
(“Сорыкортларга”, 1906)

Тукай 1907нче елның май аенда “Китмибез” исемле шигырен яза. Дәүләт думасының 1907 ел май аенда булган унбишенче мәҗлесендә Уфа губернасыннан сайланып килгән депутат мөгаллим Кәлимулла Хәсәнов мөселман мәктәпләренең хәле начарлыгыннан, хөкүмәтнең моңа бер чара да күрмәвеннән зарланып сөйли. Суллар кул чабалар, ә уңнар урыннарыннан сикереп торып, йодрыкларын төйнәп, ораторга ташланалар һәм: “Төркиягә китегез” – дип кычкыралар. “Китмибез” шигыре шул уңай белән иҗат ителгән. Революцион-демократик позициягә юл тотучы Тукай патша Россиясендәге иҗтимагый строй белән килешеп яшәү яклы түгел:

*Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт – хөр Русия!*
*Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе русияһ!* (“Китмибез”, 1907).

Һәркем үз туган җирендә бәхетле тормыш төзергә тиеш. “Безнең бөек максатыбыз – ирекле мәмләкәт(дәүләт) булдыру”, - ди шагыйрь.

“Безне урынсыз яманлыйлар” шигырен Тукай башта “Бездә истигъдад бар” исеме белән язган. Бу шигырьдә татар милләтенең бик күп урыннарда белем алганы, күп илләр белән аралашып яшәве географик атамалар аша күрсәтелгән.

“Мигъраҗ” дини сюжетка корылган шигырь, шуңа күрә Мәккә атамасы- изге, нурлы җир атамасы кулланылган.

“Ник? Нигә?” шигырендә

*Ник, “Болакыл- хак”, сиңа юктыр мәхәббәт һәм мәрак?*
*Шул сәбәптер ки: Болак гөлдән вә рәйханнан ерак,* - дигән юлларда редакциясе Болак буена урнашкан “Бәянел-хал” (1906-1914) газетасының исемен шул пычранып беткән Болакка бәйли.

“Зур бәшарәт!” (сөенеч, шатлык) шигырендәге Петербург, Нью-Йорк, Берлин, Лондон атамалары Петербург мулласы язган “Алланың рәхмәте барлык кешегә дә” дигән китабы тудырган шау-шудан көлеп, бу шау-шуның зурлыгын күрсәтү өчен кулланылганнар.

*Бәшарәт сезгә,и әһле Петербург!*
*Шулай ук сезгә дә, әһле Нью-Йорк!*
*Бәшарәт сезгә, и Берлин әһле!*
*Шулай ук сезгә шатлык, Лондон әһле!* (“Зур бәшарәт!” 1910).

“Японияне мөселман идарә итәчәкме?” (1906) шигыре язылган елларда Японийдә мөселманлык тарала, япон патшасы (Микадо) ислам динен кабул итә. Шуның хөрмәтенә ул ислам галимнәрен Япониягә чакыра икән, дигән хәбәр тарала. Шигырь шул уңай белән языла.

Габдулла Тукай белемлелекнең Европаны күкләргә күтәрүен мактый, ә татар милләтенең җиде кат җир астына төшкән хәлдә яшәвенә бик борчыла.

*Күрде милләт*
*Арзан безне*
*Агачтан яки*
*Таштан да;*

*Яурупада*
*Газиз бит без*
*Күз өстендәге*
*Каштан да*.

дип яза ул "Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?" шигырендә.

"Бәрәңге вә гыйлем" шигырендә дә шушы ук фикер әйтелә.

*И бәрәңге! Безгә килдең син ерак Амрикадан;*
*Мәгърифәт! Син безгә килдең мондарак Яуропадан.*

"Авылда авырып яту" һәм "Бәрәңге вә гыйлем" шигырьләрендә Тукай һәр яңалыктан курыккан авыл халкының бәрәңгене ашамауларын аларның белемсез булуларыннан икәнен күрсәтә.

*Күп җәфа күрдең бу җиргә син килеп Амрикадан,*
*Нишлисең, тәкъдир шулайдыр, халкыбыз шул бик надан.*
("Авылда авырып яту", 1912)

## Нәтиҗә

Тукай шигырьләрендә халык өчен актуаль булган мәсьәләләр күтәрү белән бергә сурәтләү чараларын һәм географик атамаларны күп кулланган. Мин Тукай тормышына, иҗатына багышланган бик күп эшләрне укыдым. Тик ул эшләрдә географик атамаларның булуына, кулланылуына караган фикерләр тапмадым. Мине Тукайның Казанда, Россиядә, Европада булган, бара торган вакыйгаларны яхшы белүе һәм шуларга бәйле рәвештә географик атамаларны урынлы куллануы гаҗәпләндерде. Тикшерүләрдән чыгып, мин шундый нәтиҗә ясадым:

1. Тукай географик атамаларны туган җиренә, туган ягына булган ярату хисләрен атап күрсәтү өчен кулланган.
2. Татар тормышын Россия, Европа тормышы белән чагыштыру өчен кулланган.
3. Вакыйгаларның төгәл географик урынын күрсәтү өчен кулланган.
4. Изүче сыйныфларны чагыштырулар аша тәнкыйтьләү өчен кулланган.

5. Татар халкының тарихына, язмышына кагылышлы урын, җир атамалары аша милләтнең нинди булырга тиешлеген күрсәтү өчен кулланган.

Бөек шагыйребез халкыбыз рухында яши. Без аның шигырьләрен, әкиятләрен укыйбыз, өйрәнәбез. XXI гасырга да ул олуг шагыйрь, зур җәмәгать эшлеклесе, бөек фикер иясе буларак килеп керде.

**Әдәбият:**


1. Ә.Н. Алиева. Ф.И. Ибраһимова. «Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы». Татарстан китап нәшрияты. Казан. 2003.
2. Габдулла Тукай. Шигырьләр, поэмалар. II том. Таткнигиздат. 1976.
3. Габдулла Тукай. Шигырьләр, поэмалар. Татарстан китап нәшрияты. 1990.
4. Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр. VII том. ТаРИХ. Казан. 2002.
5. И. Нуруллин. «Габдулла Тукай». Татарстан китап нәшрияты. 1979.
6. И. Нуруллин. «Моңлы саз чыңнары». Татарстан китап нәшрияты. Казан. 2000.
7. Н. Хисамов. «Шигърияттә Тукай феномены». «Казан утлары» журналы. 2006. №4. 11-15 битләр.

***Галиева М.Р. Түбән Кама педагогия көллияте студенткасы,***
***Фәнни җитәкче: Галимова Ф.А.***

# ӨСТӘЛЕМДӘ ТУКАЙ КИТАБЫ

Мин – Түбән Кама педагогия колледжы студенты. Һәр яктан үсешкә ирешкән, югары сыйфатлы укытучы булу – минем төп хыялым. Педагогика, психология өлкәсендә белемнәр туплау һәм балаларны турыдан-туры өйрәнү барышында кызыклы һәм шул ук вакытта бик тә әһәмиятле мәсьәләләр белән әледән-әле очрашырга туры килә. Укучыга нинди эчтәлектәге белем бирергә, ничек бирергә, нинди телдә бирергә, ничек аларны тәрбия кылырга һәм башка сораулар безне борчый. Менә шушы сорауларның кайберләренә мин бөек Тукаебызның педагогик хезмәтләреннән җавап таптым. Сезне дә шул фикерләр белән таныштыру докладымның төп бурычы булып тора. Чыгышымның темасы "Өстәлемдә Тукай китабы" дип атала. Габдулла Тукай әсәрләре һәм хезмәтләре укытучыларның якын киңәшчесе була ала, дигән фикер – чыгышымның гипотезасы.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы, –

дип яза Габдулла Тукаебыз. 1909нчы елда "Туган тел" шигыренә салган төп идеяне – Ян Амос Коменский, Виссарион Григорьевич Белинский, Константин Дмитриевич Ушинский, Лев Николаевич Толстойлардан килгән балаларга укыту-тәрбияне туган телдә бирергә кирәк дигән фикерне – XX гасыр башында, беренчеләрдән булып, Г.Тукай үзенең 1906 елда "Фикер" газетасында дөнья күргән "Һәркемнең, һичшиксез, үзенчә фикере, төшенчәсе бар" мәкаләсендә яңгырата. Г.Тукай безнең алга яшь буынны туган илен ихлас күңелдән яратучы, белемгә омтылучы итеп тәрбияләргә, балаларга гомуми белемне ана телендә бирүне тәэмин итәргә омтылучы мәгърифәтче педагог буларак килеп баса.

Баланы тәрбия кылу, аны мәктәпкә әзерләү, анда укуга кызыксыну, дәрт уяту мәсьәләләре юнәлешендә эзләнүләр алып

бару безне Г. Тукайның “Ана мәктүпләре” хезмәтенә алып килде. Г.Тукайның “Ана мәктүпләре” язмасы эчтәлеге һәм формасы белән Л.Н.Толстойның “Педагогик хатларын” хәтерләтә. Педагог Тукаебыз язмасының “Сүз башы”нда бала тәрбия итүнең әһәмиятен мондый сүзләр белән тәкъбир итә: “Балалар якты дөньяга килгәндә, гадәтән, бер бәхетлелек диңгезе булып киләләр. Ләкин әнә шул балаларны туган минутыннан алып балигъ булганга кадәр **ата-ана үзләренә бәхет вә башка инсаннарга да шатлык булырлык итеп** тәрбия итүе бик читен, ...”. Алга таба ул татарларның бала тәрбия итә белмәүләренә басым ясый да, “Ир бала әйбәт кенә тәрбия ителсә, - ди Тукай, - ... ата-анасын сакларга күкрәк, нәгърә орып чыккан бер арыслан буладыр,” – дип яза. Кызларга аерым тукталып, тәрбияле кыз “үзе шикелле тагы әллә ничә фәрештә кызлар вә әллә ничә арыслан йөрәкле, гайрәтле егетләр тәрбия итә аладыр” дип күрсәтә. Тукай “тәрбия” сүзенә тирән мәгънә сала. Ул баланы тән, акыл, күңел ягыннан да тәрбияләргә, үстерергә, камилләштерергә, “юл күрсәтергә” кирәклегенә басым ясый. Тәрбиянең беренче шарты итеп аның шәхси, психологик үзенчәлекләренә, холык-фигылен исәпкә алу, белү, өйрәнүне куя. Тәрбиянең икенче шарты – “аның янында күбрәк булырга, аның берлән шөгыльләнергә, сәер кыйлырга, бигрәк тә аның берлән күбрәк сөйләшергә” киңәш бирә. Баланың ышанычын яулау һәм балада барча яшерен, яхшы, ялгыш серләрен сөйләргә теләк булдыру – өченче шарт буларак яңгырый. Язманың “Алтынчы мәктүб”ендә баланы мәктәпкә әзерләү мәсьәләсе күтәрелә. Тукаебыз баланы мәктәпкә кергәнче укырга-язарга өйрәтүгә кире мөнәсәбәтен белдерә. “Балага мәктәптә күңелсез булыр. Аның күңеле иске нәрсә белүдән ялкыр. Балалар бер дә ишетмәгән яңа нәрсәләрне генә бик ихлас берлән тыңлыйлар,” - ди ул. Шушы ук хатта баланы мәктәпкә рухи һәм физик яктан әзерләү өчен, үтә әһәмиятле киңәшләр җиткерелә. Бала тормышында гигиена режимының дөрес үтәлеше, баланың үз вакытында дөрес туклануы физик яктан бик тә зарур, ди ул. Баланың кирелегенә юл куеп, аның барлык теләген үтәргә ярамавын да кисәтеп үтә Тукай. Тәрбиячегә хас

булырга тиешле сыйфатларга басым ясый. Бу сыйфатлар - белемлелек, сабырлык, чыдамлык, гаделлек, бар нәрсәгә әзер тору, сөйкемлелек һәм үз-үзеңне тота белү.

Г. Тукайның тәрбия турындагы карашлары “Яңа кыйраәт” хрестоматиясендә үстерелә. 64 хикәя, проза белән язылган берничә мәсәл һәм 16 шигырь кертелгән бу дәреслек К.Д. Ушинскийның “Туган тел”, “Балалар дөньясы” , Л.Н. Толстойның “Яңа әлифба” дәреслекләре нигезендә төзелгәннәр. Анда әләге дәреслекләрдән тәрҗемәләр белән бер рәттән татар әдипләренең бик күп әсәрләре һәм Г. Тукайның үз иҗат җимешләре урын алга. “Яңа кыйраәт”нең сүз башында татар хрестоматияләре төзү өчен принциплар, бурычлар, хрестоматия белән эшләү өчен ысул, алымнар да тәкъдим ителгән. Тукай аңлап уку, укыганны сөйләтү, “гүзәл мәгънәләр уятырлык шигырьләрне” ятлату, бәйләнешле сөйләм төзерлек әңгәмәләр оештыру ысулларын тәкъдим итә. Әңгәмәне алга алып, “Картайган арыслан” кыйссасы мисалында үрнәк тә бирә.

Әдәбият укыту бурычларына килгәндә, ул әдәбиятның чын әһәмиятен аңлап, тәрбия бирүне беренче урынга куя һәм әсәрләр сайлап урнаштырганда да аңа игътибар итә. “Яңа кыйраәт”нең төп максаты – балаларның “әхлакларын тәрбия итеп, яхшы вә яманны, яхшы вә яманлыклары өчен сөйдерергә вә кире кагарга” өйрәтү дип язуы белән Г.Тукай методист буларак әдәбиятны традицион аңлату-укыту тарафдары икәнлегенә басым ясый.

Ул замандагы алдынгы карашлы укытучылар тирән эчтәлекле һәм методик күрсәтмәләргә бай булган бу дәреслеккә югары бәя бирәләр. Аның ел саен басылып чыгуы да күп нәрсә турында сөйли. 1913 елны Уфада уздырылган укытучылар киңәшмәсендә “Яңа кыйраәт” дәреслеге беренче премиягә лаеклы була һәм мәктәптә кулланырга тиешле тулы хокуклы дәреслек дип билгеләп үтелә.

1910 елда Г.Тукай “Мәктәптә әдәбият дәресләре” дип аталган китап төзи. Ул әдәби әсәрләрдән үрнәкләр җыелган беренче хрестоматия булып тора. Биредә бик күп танылган татар язучыларының әсәрләреннән өзекләр, шигъри әсәрләр урын

алган. Г.Тукай бу хезмәтендә “балаларның рухларына азык бирү вә аны тәрбия итү”не беренче максат итеп куя “Безгә балаларымызның кулындагы моңарчы кадерле булмаган әрекмән, кычыткан вә балтырганнарны алып, алар урынына шушы китап кеби чәчәк бәйләмнәре бирергә тиештер. Таки балаларымызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә ияләшсен.

Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә ләтыйф булып, анчак гүзәл вә мөкаддәс нәрсәләр генә сөючән буладыр.

Моның киресенчә, кечкенәдән тупас вә ямьсез нәрсәләр күреп үскән балаларның язгы күк кеби садә күңелләре томанланып, рухлары яхшыны вә начарны аермый, һәрнәрсәгә бертигез караучы буладыр, ” - дип язуы белән Тукай “Яңа кыйраәт”не төзегәндә сайлаган юнәлешенә тугры калуын күрсәтә. Дәреслекнең төзелешенә тукталмыйча гына, аңа урнаштырылган әсәрләрнең әдәп, әхлак, табигать һәм аның кеше күңеленә тәэсире, туган ил, туган тел, милләт язмышы, аның аерым шәхесләрен тасвир итү юнәлешендәге һәм тарихи вакыйгаларны күрсәткән текстлар булуын күрсәтеп китү кирәк. Билгеле, хрестоматиядә әхлак тәрбиясе бирү максатын алга чыгару уку китабын чикли, шулай булса да, бу дәреслекнең кыйммәте бик зур. Ул мәктәпләр һәм мәдрәсәләрдә татар әдәбияты укытыла башлау, югары сыйныфлар өчен әдәбият тарихы һәм теориясеннән дәреслекләр төзелү, әдәбият укыту методикасын эшләү өчен этәргеч, нигез булды.

“Мәктәптә милли әдәбият дәресләре” – әдәбият укытуда яңа баскыч. Г. Тукай хрестоматияне язганда берничә сорауга җавап бирә: татар әдәбиятын мәктәптә кайсы әсәрләр аша күрсәтергә, кайсы әдипләр иҗатын тәкъдим итәргә, әлеге әсәрләрне нәрсәгә нигезләнеп урнаштырырга, мондый уку китабында нинди мәсьәләләрне игътибар үзәгенә куярга? Әйтергә кирәк, бүгенге көнгә кадәр Тукай сайлап алган әсәрләрнең күбесе дәреслек-хрестоматияләребезнең түрен бизи, нәкъ ул сайлаган авторларны бүгенге көн методистлары да

яратып тәкъдим итәләр. Димәк, Тукайның педагогик-методик фикерләре искермәгән, бүген дә әһәмиятен киметмәгән.

Нәкъ менә шушы фикерләр безне әледән-әле Тукай хезмәтләренә алып килә. Алар безнең эш өстәлебезне бизиләр. Г. Тукай иҗатының, хезмәтләренең кадере дә нәкъ шунда.

**Әдәбият:**


1. Заһидуллина Д.Ф. Тукайның методик-педагогик карашлары / Д.Ф. Заһидуллина / Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары. – Казан: 1997.
2. Заһидуллина Д.Ф. Тукайның методик-педагогик карашлары / Д.Ф. Заһидуллина урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы – Казан: Мәгариф, 2000.
3. Исламов Ф.Ф. Тукайның педагогик эшчәнлеге һәм педагогик карашлары / Ф.Ф. Исламов / Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары. – Казан: 1997.
4. Исламов Ф. Тукай образы – әдәбиятта һәм сәнгатьтә // Мәгариф. -2006. -№4. - 61-62.
5. Лаисов Н. Габдулла Тукай / Н. Лаисов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1985.
6. Маликов Р.Ш. Тукайның балалар һәм яшүсмерләр өчен язган шигырьләрендә тәрбияви фикерләр / Р.Ш Маликов / Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары. – Казан: 1997.
7. Туишев Ю. Г.  Г. Тукайның кайбер педагогик карашлары. // Совет мәктәбе. – 1961. - №4.- 10.
8. Тукаев Габдулла Мәктәптә әдәбият дәресләре / Габдулла Тукаев – Казан: Тат. кит. нәшр., 2000.
9. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар . 2 томда, 2 нче том / Төз. Э Галимҗанов, - Казан: Тат. кит. нәшр., 2006.

10. Шарафетдинов З.Т. Традиции и преемственность просвещения. – Наб. Челны, 1997.

***Алексеев А.А. 8 нче мәктәп укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Галина В.М.***

## ТУКАЙ КҮҢЕЛЕН ЯКТЫРТКАН КАЗАН

Һәр халыкның, һәр милләтнең йөзек кашы булырдай гүзәл шәхесләре, олы талантлары, бөтен кешелек дөньясы тарихында тирән эз калдырган затлары була. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай, һичшиксез, әнә шундый олы шәхесләрнең берсе.

Олуг язучыбыз Әмирхан Еники моннан күп еллар элек: “Бер генә минутка фараз итик: безнең тарихыбызда Тукай юк, Тукай булмаган ди... Никадәр ярлыланып калыр идек без, күпме дан – дәрәҗәләребезне югалтыр идек!.. Әмма язмышка мең рәхмәт, безнең Тукаебыз бар!” – дип язган иде.

Тукай шигърияте җиһанга ямь, яктылык бөркеп торучы, туң катлауларын эретеп, җиргә, күңелләргә җылылык бирүче кояш үзенә бер илаһи көчкә ия. Чөнки аның иҗаты тар кысаларга сыймый, халкыбызның “хәсрәт кош көйләп”, авыр үткәне белән саубуллашып, киләчәк өчен көрәшергә өйрәтә, шуңа чакыра.

Әдәбият күгендә нибары 7-8 ел ялтырап, үз йолдызлыгын – шигъри мәктәбен тудырган сүз остасының мирасы күп тармаклы, киң кырлы. Аның үткен телле публиөистикасы, камчылы сатирасы, кинаяле, шаяртулы юморы, тәнкыйть эшчәнлеге – һәркайсы игътибар үзәгендә торырга тиеш.

Бөек Тукайның иҗаты татар әдәбиятына үсү, камилләшү өчен гаять көчле этәргеч булды һәм хәзер дә шулай булуын дәвам итә.

2011 ел Татарстан Республикасы президенты указы нигезендә Татарстанда Тукай елы дип игълан ителде.

Быел татар җәмгыятьчелеге милләтебезнең алтын баганаларының берсе булган – шагыйрь Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуны зурлап билгеләп үтә. Шул уңайдан сайланган “Тукай күңелен яктырткан Казан” темасы бүгенге көн өчен бик актуаль һәм кызыклы булып тора.

Тукай таланты беренче адымнарыннан ук, Казанга омтыла, анда гына торган матбугат аша иҗтимагый хәлләр, әдәбият һәм сәнгать хәбәрләре белән кызыксына, аны үзенең иҗат колачын киңәйтүнең алшарты итә.

Кемнәр генә аның Җаек (Уральск) шәһәреннән башкалага килүен тасвирлаган “Пар атын” яратып куымаган да, кемнәр генә аны яттан белми һәм җырламый икән.

Күпләр бу әсәрне Уральскидан Казанга кайткач язган дип уйлый. Ә ул баксаң, Уральскида чыгучы “Фикер” газетасының 1907 ел, 6 май санында һәм “Яңа гасыр” әдәби журналының шул ук елгы 25 май санында басылган булган.

Тукай үзе исә Казанга пар атта түгел, ә поезд белән 1907 елның 10 октяберендә, шигырь басылып чыкканнан соң 5 айдан соң, кайтып төшә. Әлбәттә, моның кайбер сәбәпләре дә була. Казанда “Әль – ислах” (“Реформа”) исемле газета чыгарырга алынгач, аның рәсми редакторы Вафа Бәхтияров Җаекка, танылып килүче шагыйрь Г. Тукаевка газета белән хезмәттәшлек итүен үтенеп хат җибәрә.

Икенчедән, Казанның Шәрәфләр нәшрияты “Шигырьләр китапхпнәсе” сериясендә “Габдулла Тукаев шигырьләре” дип аталган беренче китабын чыгарырга әзерли. Өченчедән, аңа солдатка каралырга вакыт җитә. Октябрь аенда, ниһаять, 12 ел гомер иткән шәһәрне калдырып китү көне җитә.

Бай тарихлы, сәнгать һәм сәүдә, фән һәм мәдәният үзәге булган Казанда яшәү һәм иҗат итү аңа иҗади үсеше өчен бик кирәк булган. Казан шаулап торган мәдәният-мәгърифәт дөньясына шагыйрьне бик тиз бөтереп алып кереп киткән.

Казанга кайту Г. Тукай иҗатына искиткеч шифалы тәэсир ясаган. Чөнки Җаек чоры иҗаты әле киң халык тарафыннан танылмаган була. Аның зур популярлык казанган “Туган тел”, “Китап”, “Шиһаб хәзрәт”, “Көзге җилләр”, “Олуг юбилей уңае

белән халык өметләре” шигырьләрен, “Су анасы”, “Кәҗә белән Сарык” әкияте кебек поэма әкиятләрен, “Печән базары, яхүд Яңа Кисекбаш”, “Ысулы кадимче” исемле поэмаларын, “Исемдә калганнар” повесте, балаларга багышланган шигырьләрен, “Мияубикә”, “Алтын әтәч” поэмаларын эченә алган 35 исемдә үзе исән чакта чыккак китаплары Казанда басыла.

Тукай Казанда 5 ел 8 ай гына яшәгән һәм әйтергә кирәк, аның таланты Казан белән бергә үскән, иҗаты шунда чәчәк аткан.

Казан шәһәрен татар мәдәниятенең үзәге, йөрәк тибеше итеп күтәрүдә бер генә шагыйрь яки язучы да аңа тиң хезмәт куймаган. Ә бит бу чорда Казанда татар халкының алга барышына, рухи тормышына озак вакытлар тәэсир итәчәк эшлеклеләр: Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Ибраһимов, М. Ваһитов, М. Солтангалиев, Ш. Камал, М. Фәйзи, К. Тинчурин һ. б. Яшәгән. Һәм шулар арасында 21-22 яшьлек Тукай, академик М. Хәсәнов бик дөрес билгеләнгәнчә, «ыргылып алга чыга, татар яңарышының әйдәүче шәхесләре рәтенә баса”.

Казан нәширләре Тукайны беренче көннәрдән үк үз иткән. 14 ноябрьдә шагыйрьгә “Казанны алырга” мөмкинлек биргән китабы – “Габдулла Тукаев шигырьләре” (3 нче дәфтәр). Шәрәфләр матбагасында басылып чыккан, күп тә үтми шунда ук 4 нче дәфтәр “Г. Тукаев шигырьләре”нең икенче китабы дөнья күргән. 1909 елның 6 нчы гыйнварында өченче китабы, кыска гына вакыт эчендә - биш ел ярым арасында 30 дан артык китабы басылган.

Казанда Тукай күпкырлы талантка ия шагыйрь буларак ачыла: ул нечкә лирик, шул УК вакытта үткен сатирик. Нәкъ менә Казанда шагыйрьнең иҗаты яңа темалар, образлар белән баетыла.

Шагыйрь Казанда узган бик кыска гомерен дә зур итеп, мәгънәле итеп яшәгән. Халыкның иҗтимагый һәм сәяси, әдәби һәм шигъри тормышында ул катнашмаган бер генә өлкә дә булмаган. Шул чорда Казанга багышланган, мөһим проблемалар күтәргән унөч әсәр язган. Алар арасында прозадан: күпсанлы

мәкаләләр һәм очерклар (“Казан хәбәрләре”, “Казан бәяләре”, “Казанда никах мәҗлесе”, “Казан мулласы һәм булачак депутат”, “Җәмгыяте хәйрия утырышы”, “Казанга кайтыш”), шигырьләр (“Казан вә Казан арты”, “Казан вә Кабан арты” (1912), “Казан” (1913) һ.б.

Шагыйрьнең башкалабыз Казанга бәясе-гыйбрәтле, бүген дә әһәмиятен җуймаган сөземтә. Һәр шигырьнең үз йөзе, рухи дөньясы, фикри байлыгы бар. Аларны гомуми сүзләр ташкынында адаштырмыйча, аерым-аерым укып карыйк әле.

а) “Печән базары, яхүд Яңа Кисекбаш” поэмасы – иҗтимагый тормышка зур йогынты ясаган әсәр.

“Печән базары, яхүд Яңа Кисекбаш” әсәрендә шул заманның шәһәр тормышын искиткеч оста итеп сатира утына тоткан. Әсәр казанлыларны битараф калдырмаган, ул аерым китап булып нәшер ителгәч, берничә көн эчендә үк сатылып беткән. Тарихта беренче тапкыр татар язучысының әсәре иҗтимагый тормышка зур йогынты ясаган. Казанның Печән базары әһелләре, поэманың тискәре каһарманнары, әдәбият көзгесендә үзләрен күрү “бәхетенә” ирешкәннәр.

б) “Казан вә Казан арты” (1912) шигыре.

Ул шигыре төрле мәгънәви төшенчәләрне капма-каршы куюга – антитеза алымына корылган. Тукай сүзен югары өслүб белән Казанына мәдһия яудырудан башлый. “И Какзан шәһәре, торасың тауда зур шәм кеби”. Сискәндерерлек дәрәҗәдәге романтик күпертеп мактау алдагы юлларга күчә:

“Син үзеңне чорнаган һәрбер өязгә нур чәчеп,
Бик мәһабәтле торасың торасың барчага юл күрсәтеп.

Шагыйрь үзен бу мактауда, төче теллелектә гаепләүдә курыккандай, Казан каласыннан нур, шөһрәт, мәгърифәт алып яшәүче төбәкләрне атап китүне кирәк таба. Казан нурлары җылысында рәхәтләнеп яшәгән яклар бик күп икән.

Хәзерге Татарстанга кергән Чистай, Спас, Тәтеш, Мамадыштан кала, Чабаксар, Чар (хәзерге Йошкар-Ола) кебек бүгенге чуаш, мари риспубликаларының башкалалары, Малмыж кебек шәһәрләр дә Казан ярдәмендә чәчәк аталар икән.

Һәр халыкның, һәр милләтнең үсешендә күтәрелеш чоры була. Без дә бүген шундый күтәрелеш чорын кичерәбез. Гасыр башында Тукайны борчыган сораулар бүген безне дә борчый, алар бүген дә актуаль. Менә ни өчен бүген күпләр Тукайга, аның үлемсез иҗатына мөрәҗәгать итә. Аның иҗатында бүгенге көннең күп кенә сорауларына җавап табып була. Шуңа күрә дә Тукай безгә һәрчак бик якын. Шагыйрьнең мирасы халкыбызның мәдәни, милли тормышының нигезен тәшкил итә.

Тукай телебезнең бик нечкә төсмерләренә кадәр сиземләгән. Аның үлемсез шигъриятен уку безнең сөйләмебезне баета. Шуңа күрә безгә Тукайны кат-кат, кайта-кайта укырга, үз-үзебезне тәрбияләргә кирәк.

**Әдәбият:**


1. Габдулла Тукай. Әсәрләр: 5 томда. – Т.1: Шигырьләр, поэмалар.- Казан, Татарстан китап нәшр., 1985. – 406б.
2. Габдулла Тукай / Составитель Н. Лаисов / на 2-х языках /. – К.: Таткнигоиздат., 1985. – 86с.
3. Галиуллин Т. Тукай күңелен яктырткан Казан: Г. Тукай иҗаты / Татарские новости. – 2004. - №4. – 10б.
4. Ганиев в. Күктән иңгән бәхете ул татарның! (Г. Тукай иҗаты) / Татарские новости. – 2004. – №4. – 10б.
5. Исәнбаев С. Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы // Мирас. – 2004. - №1. – 51-59б.
6. “Казан вә Казан арты” // Татарские новости . – 2004. - №4. – 10б.
7. Низамиев М.Г. Тукай һәм Казан // Мәдәни җомга. – 2004. – 23 апрель.
8. Низамиев М. Тукайсыз сиксән сигез ел: Шагыйрь иҗаты турында / Ватаным Татарстан. – 2001. – 14 апрель.
9. Низамиев М. Татар даһиенең урыны. – Казан: Г. Тукайның Казанга кайтуына 10 октябрьдә 95 ел тулды // Шәһри Казан. – 2002. – 8 октябрь.
10. Низамиев М. Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта милләтем // Мәдәни җомга. – 2002. – 26 апрель.

11. Нафыйгов Р. Тукай тормышында яңа фактлар // Ватаным Татарстан. – 2000. – 21 июль.
12. Хәсәнов А. Шүрәле илләр гизә: Тукайның 120 еллыгын каршылап // Мәгърифәт. – 2005. – 10 декабрь.
13. Шәймиев М. Халкыбызның йөзек кашы: Тукайның 110 еллыгына багышланган тантанада сөйләнгән чыгыш // Мирас. – 2004. – №12. – 7-8 б.
14. 2006 ел - әдәбият – сәнгать елы дип игълан ителде // Тәрбия. – 2006. - №1. – 1б.

***Ульданова Э. 20 нче мәктәп укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Константинова Д.М.***

## СӨЯМ ДИЕП ӘЙТӘ АЛМАДЫ

“Сөям кысмыйча нечкә биленңезне,
Ничек дисәм дә аз тәмсиленңезне.”
Г.Тукай.

"Сез балык баласы түгел, Сез халык баласы бит. Киләчәк көнгә Тукайны Сез алып барасы бит!”

- дип язган күренекле шагыйребез Хәсән Туфан үзенең "Кемнәр сез?" дигән шигырендә яшь буынга мөрәҗәгать итеп. Без, яшь буын, Тукайны үзебездән соң килә торган буынга ничек алып барабыз соң: телебезне, мәдәниятебезне югалтмыйбызмы? Тукайлар, Җәлилләр, Туфаннар йөзенә кызыллык китермибезме? Бу шигырь безне шундый уйларга этәрде һәм әдәбият дәресендә без озак фикер алыштык.

Бу елны Республикабызда Тукай елы дип игълан итү безне Тукайга тагын да якынайтты, рухландырды, иҗаты белән тирәнрәк танышырга мөмкинлек бирде.

Габдулла Тукай тормышы белән якыннан танышу, аңа тирән хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре мине шагыйрьнең ачы язмышы турында уйларга этәрде. Мине бөтен халык яраткан кеше нишләп ялгыз булды икән дигән уйлар борчыды.

Халкыбызның бөек шагыйре Г.Тукайның тормышы һәм кабантланмас иҗаты турында күп язылды, шулай да биографиясендәге ачыкланып җитмәгән кайбер фактлар һаман да кала килә әле. Белгечләребез арасында бүгенгә кадәр “Тукай хатын-кыздан качкан” дигән фикер яши. Бу чыннан да шулай микән соң? Тукай сөйгәнме? Сөйсә - кемне сөйгән? Габдуллада “гыйшык уты” беренче тапкыр Җаекта кабынган дип уйларга кирәк. Аның мәдрәсә каршында яшәүче бер апаның үзеннән 2-3 яшькә олырак кызына күз атып йөргәнлеге ихтимал, дип сөйлиләр. Бу мәхәббәт артык җитди булмаган күрәсең, сизелерлек эз калдырмаган.

Тукай яшьтән бәхетле гаилә тормышын белмәгән, хатын-кыз арасында булып, аларның матур якларын күп күрә алмаган. Габдулланы бердәнбер ышанычы - әнисе явыз карчыкка калдырып кияүгә киткән.(Дөрес, заманасы шундый булган, хатын-кыз ялгыз тормыш итә алмаган.) Шәрифә карчык сабыйга төзәтә алмаслык бәла китергән. Кышкы салкыннарда ишек ача алмый торган вакытларда ук башлангандыр инде бик иртә гомерен кискән чир. Үги әбисе күпме кыен ашаткан, кимсеткән. Киң күңелле хатын булса, иренең оныгын 6 “күгәрчен” янына сыйдырган булыр иде.”Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде”- дип каргамас иде. Кырлайда да Сәгъди абзыйның хатыны Зөһрә апа “үксез бала асрасаң”ны еш әйтеп бала күңелен кимсеткән. Саҗидә сабыйны үртәр өчен гел каккан, үз энем дип Садрины сөйгән. Болар Габдулланың йөрәген өзгәләгән бит, югыйсә исендә калмас иде. Хәтта әтисенең апасы Газизә дә, байлыгы була торып, энесен мәдрәсәдә көн иттергән, ачка интеккәнен белмәгәнмени. Габдуллага балачагында ачык йөз күрсәткән, аның турында кайгыркан Мөхәммәтвәли хатыны Газизә дә үз баласы булмагач сабый күңелен аңлап бетермәгән шул, Ташаяк базарында берәр уенчык алып бирер иде. Сабый базардан “кеше бәхетенә генә кызыгып” кайтмас иде. Габдулла үзенә балачакта ачык йөз күрсәткән ике кызны гына хәтерли.Үги әбинең кызы Саҗидә әнисеннән яшереп кенә иркәләгән аны һәм Сәгъди абзый кызы Сабира ятимне җәлләгән.Тукай тормышында билгеле эз

калдырган иң беренче хатын-кызлар, мөгаен ике Газизә булгандыр.Берсе әтисенең сеңлесе,икенчесе - әтисенең беренче хатыныннан туган кызы.Алар шагыйрьгә җылы мөнәсәбәттә булган.

Гомүмән алганда хатын- кыздан ачык йөз күрмәгән булачак шагыйрь. Ир-атлар саклап калган аны. Шуңа күрәдер белгечләр арасында, аларга ияреп халыкта "Тукай хатын-кызлар белән аралашырга яратмаган" дигән фикер яши.

Бу чыннан да шулай микән соң? Әлеге язмамда мин «гүзәл яртыбыз»ның шагыйрь тормышында күпмедер дәрәҗәдә роль уйнаганлыгын күрсәтүне максат итеп куйдым.

Г.Тукай Уральск басмаларында дөнья күргән әсәрләрендә хатын-кыз азатлыгы проблемасына шактый зур урын бирә. Хатын-кызның хөрлеген, ирләр белән тигезлеген кайнар яклый; аларның, ана буларак, балаларын Ватанга лаеклы ул-кызлар итеп үстерүдә төп көч булуларын ассызыклап күрсәтә.

Безгә Г. Тукайның матбугат чыгышлары тәэсирендә яисә аның турыдан-туры катнашы белән язылып, «Фикер» газетасында басылган кайбер язмалары билгеле.

Тукайның күп кенә мәкаләләре, очерклары, шигырьләре нәкъ менә алдынгы карашлы татар хатын-кызларының шул рәвешчә яктылыкка, азатлыкка омтылуын чагылдыра. Аның хатын-кызларга, аналарга дан җырлаган, күңел кылларын тибрәтә, кешеләрнең акылларын һәм хисләрен әсир итә алган әсәрләре кемгә генә мәгълүм түгел икән? Кем белә, мондый югарылыкка ирешүдә, бәлки, ул таныш булган хатын-кызларның да ярдәме тигәндер. Тукайның шактый яхшы танышы Фатыйма язмышы шагыйрьнең иҗатында чагылыш тапкан. Ул бәхетсез татар кызы турындагы күләмле шигырен аңа багышлаган.

Ятим кыз Бибиәсма Билюкованың язмышы исә бүгенге көнгә кадәр ачыкланмаган. Сөйләүләренә караганда, ул Тукайның беренче мәхәббәте булган.

Мөәзин кызы Я. Гафиятуллина белән аның дусты Г. Яруллина да шагыйрь белән яхшы таныш булган. Аның түбәндәге шигъри юллары шушы кызларга багышланган .

***Укыгыз, кызлар, укыгыз.***

***Күп хәлләрне белегез! Остабикәләрне ташлап. Мәктәпләргә керегез!***

Тукай белән таныш булган Мәрьям Галиева һәм Зиннәт Баткаеваны шагыйрьнең төннәр буе типографиядә кульязмалар өстендә утыруын күрәләр. Кызлар аңа кайчакларда ашарга алып керә торган булганнар.

Уралдагы социал-демократик оешманың иң актив эшлекләреннән Надежда Шилованы Тукай яхшы белгән, аның белән демонстрацияләрдә һәм митингларда булган, революцион йомышларын үтәгән. Шилова 1981 елга кадәр Мәскәүдә яшәгән. Тукайның аның дусларыннан А. Бокаушинаны, О. Донскованы белмәве дә мөмкин түгел. Ул аларның якшәмбе мәктәпләренә йөреп, лекцияләрен тыңлаган.

Мин бу язмамда Г. Тукайга Уральскида яшәү чорында таныш булган кайбер хатын- кызлар турындагы мәгълүматларга тукталырга тырыштым. Аларның шагыйрьнең шатлыгы һәм сыкрануы да, илһамчысы һәм сызлануы да булуларында шигем юк. Чордашларының тормышлары белән якыннанрак танышу шагыйрьнең эчке дөньясын, хиссият чыганагын тирәнрәк өйрәнергә ярдәм итә.

**Таныш хатын-кызларына багышланган шигырьләреннән өзекләр.**

**Кемне сөяргә кирәк?**

*Белү мөшкил — кирәк кемне сөяргә?*
*Үзең аусаң да, аудармый сөяргә?*
*Син үлсәң (бет!), сине кем кызгана соң?*
*Синең зәхмеңгә кемнәр сызлана соң?*
*Бу дөньяда сине кем иркәли соң?*
*Бәлаләрдән сине кем киртәли соң?*
*Тырышма, эзләмә юкны әрәмгә,*
*Табылмас — юк! Әрәм җәһдең, әрәм лә.*
*Сиңа, дустым, бу сүз ахыргы сүзем:*
*Үзеңне сөй! Ярат үзеңне үзең!*

**Татар кызларына.**

*Сөям сезнең сызылган кашыңызны,*
*Тузылган сачеңезне, башыңызны.*
*Яратам тәмле, татлы сүзеңезне,*
*Зөбәрҗәт төсле якты күзеңезне.*

**Кызык гыйшык.**

*Тирләп, эссе көндә койнырга теләп,*
*Бер кеше салкын су алды бер чиләк.*
*Өст-башын салган; вәләкин шикләнә*
*Су салырга тәнгә, чөнки чиркәнә.*
*Бер куя җиргә чиләкне, бер тота;*
*Нишләсен мискин — суык су куркыта.*
*Күп азаптан соңра гайрәткә килеп,*
*Суны җилкә аркылы читкә сибеп*
*Куйды да, — син нечкәләп бер баксана:*
*«Әл дә тәнгә тимәде», — дип шатлана!*

**Мәхәббәт шәрхе.**

*Мин: «Мәхәббәтсез»,— дидем, ләкин мәхәббәт төрлечә:*
*Йолдыз ул күктән атылган җиргә, Генрих Гейнечә.*

**Мәхәббәт.**

*Җир яшәрмәс, гөл ачылмас — төшми яңгыр тамчысы;*
*Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы.*
*Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну! —*
*Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?*
*Барча әхрары мәхәббәт миннән уңда, зан итәм, —*
*Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! — мин ал арның таңчысы!*

**Гашыйк.**

*Син күрерсең бу кешене: күп вакыт уйный, көлә, —*
*Ул шулайтеп халәте рухын яшермәкче була.*
*Белмичә, «уйный» диләр, эчтән ниләр уйлаганын;*
*Сизмиләр — чыкмый төтен тышка — мәхәббәт янганын!*

**Булмаса.**

*Кем белер кадреңне, җаным, дәртле күңел булмаса?*
*Наз итәр кемнәргә гөл — каршында былбыл булмаса?*

**Бер рәсемгә.**

*Бик матур бит, бакчы бу кызның күзенә, кашына,*
*Мең вә мильюн афәрин бу сурәтең нәкъкашына.*

**Син булмасаң!**

*И матур! мин янмас идем — яндыручы булмасаң;*
*Таммас иде җиргә яшьләр — тамдыручы булмасаң!*
*Бер минутта ташлар идем бу томанлы моңнарны, —*
*Син мине мескен кыйлып моңландыручы булмасаң!*

**Гыйшыкмы соң бу?..**

*Җанын фида иткән фәкыйрьмен, гыйшкың күбәләгемен;*
*Кил, гүзәл, күрсәт матурлыгың: янаем, кил, янаем.*
*И хода, бир акыл, торкыннар йортына эләкмим;*
*Бу кызга гыйшкым сәбәпле диванамын, диванамын.*
*И гүзәл, кил каршыма, кил, елмайчы рәхим итеп,*
*Мин дә синең әйләнәңдә әйләнием, әйләнием.*

**Ләззәт вә тәм нәрсәдә?**

*Нәрсәдә ләззәт икән? Чөнкем ялан дөньяда кәм;*
*Мин ләзиз шәйләр, вә ли кайсында ләззәт, кайда тәм?* —*
*Бер матур кызның нәзек билен кысып кочмактамы?*
*Яки пар юрга җигеп, фәйтун белән очмактамы?*
*Иә сихерле шишәдән әбелхәят эчмәктәме?*
*Мәет улып, аляме дөньядан тәмам кичмәктәме?*

**Исемдә.**

*Исемдә: курка-курка төрле уйлар уйлаган чаклар,*
*Гафифанә вә мәгъсуманә көлгән, уйнаган чаклар;*
*Исемдә һәм эчемнән көткәнем якты бәхетләрне,*
*Теләп яшерен генә – рәхәт, сәгадәтле вакытларны;*
*Исемдә: иң элекке саф мәхәббәт дәрте кузгалгач,*
*Илаһи бер тәләззездән беренче кәррә тамган яшь.*

Әгәр хатын-кыздан кача торган булган икән, Тукай иҗатында мәхәббәт хисләрен ничек шулай тирән бирә алган соң?

Күптән түгел Тукайның тууына 125 ел тулуга багышлап Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры Рабит Батулланың "Зәйтүнәкәй" исемле музыкаль драмасын сәхнәләштерде. Бу әсәрне карау безгә дә насип булды. Тукайнын Зәйтүнә исемле кызны яратып йөргәнлеге мәгълүм. Кем ул Зәйтүнә?

1907 елда Чистай пыялачысы Хәйдәр гаиләсе Казанга күчә. Кызлары Зәйтүнә, апасы Бәдриҗиһан белән бергә, рус-татар мәктәбендә укый. Зәйтүнәгә 14 яшь. Иртән укыйлар, укудан соң, өйдә чигү эшенә утыралар. Приказчик абыйлары алып кайткан төрле китап, газета-журналларның берсен дә калдырмый укып баралар.Зәйтүнәнең шагыйрьнең үзен күрәсе килә һәм ул Бәдриҗиһан белән бергә үзләренә туган тиешле Фатих Әмирхан янына “Әл-Ислах” редакциясенә килгәлиләр. Алар Фатих абыйларыннан Тукай белән таныштыруны үтенә. Сәхнәдә шул вакыйгалар. Сәхнәдән күзебезне ала алмыйча,Зәйтүнә белән Габдулла өчен кайгырып утырдык.Аңлашсыннар дип теләдек.

Тукайның мәхәббәтенә килсәк, Тукай шагыйрь булганга, кызларга мәхәббәт аны берничә шигырь язарга, шигырь тудырырга илһам биргән .

Ул туташ кем генә булса да булсын, ул туташның хәзер безнең гади тормышыбызда кыйммәте нинди генә булса да булсын, ул Тукайга шул шигырьләрне сөйләргә сәбәпче була алган. Тукайның күңелендә туган шул мәхәббәт янгынында ул туташның хәрәкәте ихтыярлы булса да, ихтыярсыз булса да, Тукай шул мәхәббәттән шатлык күрсә дә, кайгы күрсә дә, туташның шагыйрьнең шигыренә тәэсире өчен без баш иябез. Бәлки шагыйрь шул хисеннән һичбер төрле рәхәт алмагандыр, бәлки шагыйрьгә шул сөю көю-януга, кайгыдан хәсрәткә күчүгә генә сәбәп булгандыр. Ләкин шул көю-яну, ул — гади кешенең көю-януы гына түгел, ул — шагыйрь күңеленең асты өскә килүе, шагыйрьнең шигъриятенең нечкәләнүе, пакьләнүе, чарлануына сәбәп була торган көю-янудыр. Шагыйрьне нечкә шигырьләр сөйләргә мәҗбүр иткән яну-көюдер.

Габдулланың саф мәхәббәттән бер җимеш тә ала алмавы кызганыч. Габдулла шул мәхәббәт диңгезендә йөзсә, чын гыйшыкның биргән тәэсире белән язган шигырьләрен күргән булыр идек.

*Вәлиева Ч. 10 нчы мәктәп укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Лотфуллина Г.Г.,*
*I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕНЕҢ ТӘКЪБИРЕ

Коръән - мөселманнарның изге китабы һәм гарәп әдәбиятының классик ядкаре.

Коръәннең тууы Мөхәммәд пәйгамбәрнең эшчәнлеге белән бәйләнгән. 40 яшьләрдә вакытта, илһамланып, төрле ачышлар ясый башлый. Риваятьләр бу ачышларның аңа Аллаһ тарафыннан турыдан-туры яисә Җәбраил фәрештә аша иңдерелүен күрсәтәләр. Аларны халыкка җиткерү – Мөхәммәднең изге бурычы. Шуңа күрә ул үзен Аллаһ сүзен халыкка җиткерүче рәсүл, пәйгамбәр дип таный һәм бу изге эшкә ныклап керешә дә.

Коръән –изге китап. Ул кешегә әхлак тәрбиясе бирүдә зур роль уйнаган.

Коръәнне белгән кешеләр бик сирәк авырыйлар, чөнки ул чисталыкка, пакълеккә өйрәтә, рухны, җанны дәвалый.

Коръән поэтикасы өчен фәлсәфи һәм эмоциональ фикерләүнең табигый кушылуы, көчле образлылык хас булган эндәш, риторик сорау, мөрәҗәгать, кабатлау, инверсия алымнарына бай. Анда озын җөмләләр, фразалар аз. Күп кенә аятьләр ритмлы, рифмалы проза белән язылган.

Коръән аеруча мөселман халыкларының әдәбиятына нык тәэсир итте. Коръән төрки-татар әдәбиятына мең ел буена көч-куәт биргән, аңа идея һәм сәнгать ягыннан юнәлеш күрсәтүче маяк булган. Ул әдипләрнең дөньяга карашында, заманча әйткәндә, методологиясендә төп фактор хезмәтен үтәгән. Ислам диненә көчүне Г.Тукай уңай күргән:

*Гарәп халкы кабул итмәстән әүвәл дине исламны,*
*Илаһ урнында тотканнар агач, таш, төрле әснамны.*
*Бераздан соң килеп хак дин, тәмам батыйлҗ булып ялган,*
*Гарәпләрнең күзеннән дине ислам пәрдәне алган.*

*Алар бар үткән эшләргә пәйгамбәрдән оялганнар:*
*"Ничек соң без табындык потка?"- дип хәйранга калганнар.*

Гомумтөрки, ягъни борынгы төрки әдәбият - татар әдәбиятының нигезе, елга башы. Ә инде урта гасыр гарәп, фарсы әдәбиятлары, ягъни Шәрык классикасы, шул исәптән Коръән Тукайгача чор татар әдәбияты үсешендә мөһим чыганак кына түгел, ә осталыкка өйрәнү мәктәбе, олуг остаз да булган. Әдәбиятыбыз тарихын күздән кичерсәк, без моны ачык күрербез.

Тукайның балачагы ана назыннан мәхрүм, ачлыкта, ялангачлыкта, мохтаҗлыкта үтә. Нечкә күңелле, саф тойгылы, киң хыяллы күңел юатучысы, "туендыручы"сы "якын итүче"се тик Аллаһы Тәгалә була.

Г.Тукай кыска гына вакыт эчендә татар милләтеннең сөекле шагыйренә әверелә. Моның сәбәбе: шагыйрьнең күп гасырлык бай әдәби традицияләребезгә таянуында. Әдәбиятка яңалыклар алып килүче реалист буларак танылса да, ул иҗатының бөтен тамыры белән борынгы татар һәм көнчыгыш әдәбиятларына һәм тулаем Ислам мәдәниятенә барып тоташа. Кече яшьтән үк ул гади халыкның самими ышануларын мәдрәсәләрдә Ислам динен һәм һәм аның риваятьләрен күңеленә сеңдереп, борынгы Ислам әдәбиятын укып үсә, шулар җирлегендә тәрбияләнә, ә соңрак иҗат итә.

Г.Тукайга Коръәннең йогынтысы зур була. Күңеленә Коръән урнашкан шагыйрь иҗатында Коръәннән кергән сюжетлар, мотивлар зур урын ала.

Совет Тукайдан башта "демократ", аннан "социалист", соңрак бер имансыз "атеист" ясарга омтылып гәзит, журнал битләрен нинди генә мәкаләләр белән тутырмадылар. Моның дөреслектән ерак булуын түбәндәге мисаллардан ачык күрәбез. Әле 1906 елда ук Тукай үзенең бер шигырендә Коръәнгә мәдхия укып, болай дип яза:"Безләри иршад идән Коръән икәндер, белмәдем" (ягъни: "Безне туры юлга күндерүче Коръән икәндер, белмәдем"). Заман вә түрәләргә охшарга ашкынган "фәнниләрдән" кемнәр генә юка брошюралар, калын китаплар

язып, кемнәр генә зур дәрәҗәләр алып, кемнәр генә “атказанмады”?!

Бүген, ул хорафат идеология чүплеккә ташланганда, ниһаять, газиз Тукаебызның иҗаты турында дөреслекне әйтер заман килеп җитте.

Тукай ислам динен ”тамырыннан корытырга” түгел, “дин әһелләрен кырып ташларга” түгел, ә киресенчә, ислам динен, муллаларны якларга чакырды.

Тукай өчен дин – яшь буынны тәрбияләү чарасы, халыкны явызлыктан аралаучы көч, гыйлем һәм мәдәният чыганагы. Шуңа күрә дә ул динне пычратучы, диннән тик файда- керем эзләүче рухани түрәләр белән аяусыз көрәшә.

*“Синең дөньяда өлешең бетте һәм бурычың үтәлде.”*

Инде син Аллаһһудан разый булган хәлдә һәм Аллаһ синнән разый булган хәлдә һәм Раббыңа кайт!”- дигән Коръән кәлимәсен исебезгә төшереп, әдип:

*“Кайт, и нәфсе мотмәиннәм! бар, юнәл, кит тәңреңә:*
*Бирдең арканны моңарчы, инде бир бит әмренә,*
*Дустларым, кардәшләрем,сез муллаларга әйтегез:*
*Бу ике юлны, мине күмгәч, укырлар кабремә*
*Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем:*
*Күр нә рәсмә тулган иман берлә Коръән садремә!”*

- дип язган “Васыятем” шигырендә.

Шулай ук, Коръәндә кадер кичендә мөэмин-фәрештәләр сәлам укырлар дигәнне ул:

“Таң сызылганчы йөрерләр, әйтмичә һичбер каләм,

Тик диярләр: “Барча мөэмин, мөселманга сәлам!” дип, шигъри калыпка күчерә.

Габдулла Тукай ислам дcaseненең безнең җирдә үсеш алу сәбәбен 19нчы гасыр мәгърифәтчеләре – дин галимнәре Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләрнең фидакаръ хезмәтләре белән бәйли.

Шиһаб Мәрҗани хәзрәтләре милләтебезнең дини тарихын, әүвәл заманнардан алып мөселман мәгърифәтен безнең җирдә тасвир кылган галимебез. Бу мөхтәрәм имамыбыз, Шиһабетдин Мәрҗәнине Тукаебызның олуглавы тикмәгә генә

түгел. Бәлки бүгенге көнебездә дә ислам дөньясында Мәрҗәни фикере мөселманнарны гафиллектән уятуга, башка милләтләр, диннәр, дин әһелләре арасында Раббыбызның чын бәндәсе булып яшәр өчен олы хезмәт куйган, үрнәк булган хәзрәткә Тукаебыз үзенең бәһасен шулай итеп биргәндер.

Кайчандыр дини булып саналган мондый эчтәлектәге шигырьләрне тормышыбыгыздагы кимчелекләребезне төзәтергә тырышканлыктан туган әсәрләр дип аңларга кирәк. Тукайның аерым сүзләрен ялгыш аңлаучыларга карата әдипнең “Кыйтга” шигырен дә искә төшереп үтәсе килә. Шагыйрь:

*“Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,*
*Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.*
*Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,*
*Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.*
*Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч- шул булды эш:*
*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакъли алмадым”,-*

дисә дә, мәдрәсәдә алган гыйлемен Габдулла Тукай (шагыйрьнең әтисе Мөхәммәтгариф хәзрәт тә иман, мулла, галим иде) гомере буена милләтенә ирештерергә тырышты.

Шулай булса да, өметен өзмичә, “керләнеп беттем үзем, дөньяны пакъли алмадым”, дигән вакытында да, шигырьләре белән үзеннән соң булган буыннарга дөрес үгет- нәсыйхәт биреп, бу эшне дәвам иттерүне киңәш итә.

Коръән-Кәримне иркен тулы иттереп мәгънәви шигырьгә салган шагыйрьнең бу сүзләре һәр кешегә дәрес, үгет-нәсыйхәт булып торганына без ихлас күңелдән горурланабыз.

“Без мөэминнәрнең күңелләренә шифалы аятьләрне вә Коръәннән рәхмәтле хәкимнәрне иңдерәбез” , - дигән Хак Тәгалә сүзләрен “Тәәссер” (“Тәэсирләнү”) шигырендә газиз Тукай болай аңлатты:

*“Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында,*
*Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,*
*Укыйм тиз-тиз күңелдән гаҗаиб сүрә Коръәннән-*
*Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.*
*Оча дилдән бөтен шик-шөбһәләр, һәм мин җылый башлыйм:*
*Яңалыкларны мөкаддәс күз яшемлә энҗели башлыйм.*

*Бөтенләй сафлана күңлем; укыйм иман, булам мөэмин:*
*Килә рәхәт, җиңеллекләр: хәлас булам авыр йөкдин.*
*Ходай! Син тыйган эшләр тәмам әкътагъ вә әбтәр, дим;*
*Иям баш сәҗдәгә: "Аллаһһехак! Аллаһһеәкбәр!"- дим".*

Күңеленә Коръән урнашкан шагыйрь иҗатында Коръәннән кергән сюжетлар, мотивлар зур урын ала. Мәсәлән, "Кадер кич" шигыре турыдан-туры Коръәнгә барып тоташа.Ул "кадер" дип аталган 97нче сүрәне шагыйрәнә җырлап биргән.

Г.Тукай Коръәнне бик яхшы белгән. Хәтта ул аның кайбер сүрәләрен уңышлы гына тәрҗемә иткән.

*Һәр заман, кем насры берлән фәтхә килсә, Аллаһның-*
*Һич тә бер көч туктаталмый, манигы булмый аның.*
*Син күрерсең тугъры юлы тотканны күп төркем халык,*
*Хәмд-ү-тәсбих өннәре берлән гөрелдәр урталык.*
*("Ярдәм" сүрәсе -110 сүрә)*

Коръәндә телгә алынган пәйгамбәрләр, алар белән бәйле риваятьләр, ул вакыйгаларда катнашкан төрле персонажлар Тукай шигырләрендә урын алалар, шагыйрьнең фикерен җиткерәләр ("Печән базары...Кисекбаш", "Мөхәммәдия", "Тотса Мәскәүләр якаң һ.б.).

Тукайның Коръәнгә ихтирамы, мәхәббәте очсыз-кырыйсыз, ул аны укып әсәрләнә, аннан үзенә чиксез илһам ала.

Г.Тукайның дин белән сугарылган шигырьләре: "Дин вә гавам", "Рамазан гаетендә Иблиснең шайтаннарында китабы", "Тәәссер", "Васыятем", "Кадер кич", "Алтынга каршы", "Ана догасы", "Шиһаб хәзрәт", "Кыйтга", "Пәйгамбәр", "Таян Аллаһга", "Иһтида", "Коръән", "Аллаһ гыйшкына", "Ишан", "Нәсыйхәт", "Миграҗ", "Могҗиза", "Мөхәммәдия","Сабый чакта бәйрәм", "Туган тел" "Туган авыл". Дәрьяга тиңләргә мөмкин булган Тукай иҗатыннан дингә багышланган, аның асылын ачкан шигырьләр исемлеген әле тагын да дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Сабыйның йокларга ятар алдыннан теләк теләп, тәңрегә мөрәҗәгать итүен тасвирлаган "Йокы алдыннан"(1908),кайгы-хәсрәт килгәндә сабырлык,ярдәм сорарга өндәгән "Киңәш" шигыре һәм башкалар әнә шундыйлардан.

Һәр мәктәп баласы яттан белә торган “Туган авыл” шигыренең түбәндәге дүрт юлы совет чоры китапларыннан гел төшерелә килде. Чөнки анда Коръән һәм пәйгамбәр исеме телгә алынган.

*Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,*
*Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;*
*Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне,*
*Ничек михнәт-җәфа күргән, ничек торган.*

Дөньяда барлык татарларның гимны булып киткән “Туган тел”шигырен барыбыз да яхшы хәтерлибез. Ләкин совет чорында бу җырның соңгы строфасын дөньяга чыгармадылар.Чөнки бу вакытта безнең илдә дингә бик көчле каршылык хөкем сөрә иде. Шуның өчен шагыйрьләр дин турында әйтәсе килгән фикерләрен яза алмыйлар, җырчылар җырлый алмыйлар. Ләкин хәзерге вакытта безнең илдә сүз иреге һәм без Г.Тукайның шигырендәге бу соңгы строфаның матурлыгын күреп, аны күңелебез теләгән җирдә сөйли алабыз, җырлый алабыз:

“И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл,дип,үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!”

Кеше дөньяга килә һәм аңардан бик аз нәрсә сорала: кулыңнан килгән кадәр игелек кылу, Кеше булып калу. Кызганычка каршы, бүгенге болгавыр заманыбызда кешеләрдә әхлак сыйфатларының кимүе безне уйландыра. Ә бит халкыбыз нинди авыр елларны кичергән, ләкин иленнән куылса да, ачлыктан тилмерсә дә динен юк итәргә тырышсалар да бирешмәгән, мәрхәмәтле булып калган, олыны олы итеп, кечене кече итеп, милли сафлыгын югалтмыйча яшәгән. Ә моның сәбәпләренең берсе- мең елга якын халкыбызның рухи кояшы булган Корьәндәдер.

Г.Тукайның дин гыйлеме, энциклопедик дәрәҗәдә булу белән бергә, тирән мәгънәле дә.Үз иҗатында файдаланган дини әдәбият-китаплар, риваятьләр, шагыйрь фикерен куәтләргә ярдәмгә килгән Коръән аятьләре галимнәр тарафыннан киләчәктә өйрәнелер дип ышанасы килә. Тик моның өчен

галимнәрнең дин гыйлемен Габдулла Тукай дәрәҗәсендә белүе зарур.

Хак Тәгалене олугълап, ислам тәкълиматы вә шәригате таләп иткәнчә, балаларны сабый чактан ук изгелеккә өндәүдә, дуслыкка, миһербанлыкка үгетләүдә Габдулла Тукай әле үзе дә яшь булуына карамастан, үрнәк булып торды. “Таян Аллаһка” шигырендә без шуны укыйбыз:

*“Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!*
*Рәхмәте киң аның, һәрдаим таян син Аллаһга!*
*Йа, Ходай, күрсәт, диген, ошбу җиһанда якты юл;*
*Ул-рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!..*
*Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,*
*Пакъ телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.*

Без Тукай шигырьләреннән илһам алабыз, тормышыбызда булган хата һәм гөнаһларыбызны төзәтергә ашыгабыз.

Г.Тукайның хезмәтләрен күреп аны, әлбәттә, шикләнмичә изге кеше дип әйтеп була. Шулай итеп, изге кеше изге китап турында яза. Юкка түгелдер,аның иң танылган шигырь юлларында Коръән аһәңнәре ишетелә.Мәсәлән, “Аллаһ гыйшкына” шигыреннән өзек:

*Иске чир, түбәнлек юк булсын, Аллаһ яратсын өчен,*
*Шул юлга омтылыйк, и диндәшләр, Аллаһ яратсын өчен.*
*Мондый омтылыш, тырышлыклар керсен гадәткә,*
*Аллаһ яратсын өчен.*
*Болай итеп наданлык безне измәсен, Аллаһ яратсын өчен;*
*Чарасын яз яки телдән сөйлә, Аллаһ яратсын өчен.*
*Гыйлемгә кирелек пәрдә булмасын, Аллаһ яратсын өчен;*
*Җанланыйк, кузгалыйк һәр җирдә, Аллаһ яратсын өчен.*
*Дуслык булмау сәбәпле милләт шушы хәлгә килде,-*
*Гыйбрәт ал, и Мөхәммәт өммәте! Аллаһ яратсын өчен.*

**Әдәбият:**

1. Татар әдәбияты тарихы 1 том.
2. “Мирас” журналлары № 5-11, 2001; 2002; 1-1999;
3. “Казан утлары” №10-1996, №6-1991, №8-1995;
4. “Мәгариф” журналлары

5. Тукай Г. Шигырьләр. – 4 т.
6. Шәһри Шәриф “Әсхаб Кирам”. Чистай шәһәре – 2001.
7. Коръән Кәрим.
8. Коръән тәфсире. “Тәфсир Ногмани” – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.
9. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең тормышы / В.Ягъкуб “Иман” Казан, 1993.
10. Кыйссаи әнбия /Пәйгамбәрләр тарихы/ Казан, 2003.

## III НЧЕ ЮНӘЛЕШ.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР

*Галиева А.М. 14 нче лицей укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Фәсхетдинова З.М.*

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР

Татар әдәбияты үсешенә Габдулла Тукай кебек зур өлеш керткән башка каләм иясен табу кыен. Алай гына да түгел, ул тугандаш төрки һәм Идел-Урал буйларындагы мари, удмурт, чуваш сүз сәнгатьләренең чәчәк атуына да зур йогынты ясады. Дөресен әйткәндә, Габдулла Тукай элеккеге зур илдә барлык халыклар өчен дә ят булмады, киресенчә, аның әсәрләре тәрҗемә ителмәгән, чын мәгънәсендә югары сәнгатьчә шигырьләре яңгырамаган телләрне табу кыендыр. Тукай дигәндә - татар халкы күздә тотылса, татарлар дип әйтүгә - Г. Тукай дигән шигъри исем аңга килә. Ул чын мәгънәсендә халыкның үз улы. Инде бөек шагыйребезне бездән аерган XX йөз дә "узган гасыр" булып тарихка кереп калды. Әмма Габдулла Тукайның шәхесе һәм ул тудырган үлемсез әсәрләр һәрвакыт халык күңелендә, "безнең гасыр"да калалар. Бу – шагыйрьнең рухи үлемсезлеге дигән сүз.

Сөекле шагыйребезнең исемен телгә алуга, үзеннән-үзе аның "Исемдә калганнар" дигән язмаларында бәян ителгәннәр хәтергә килә. Шуларга менә бу мәгълүм юллар өстәлә:

Азмы каканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!

Азрак үстерде сыйпап тик маңгаемнан милләтем.

Билгеле булганча, Г. Тукай 1909 елда, үзе әйткәнчә, "берничә нәширләрнең язып бирергә үтенүләре" сәбәпле, тәрҗемәи хәлен "Исемдә калганнар" дигән истәлекләрендә бәян итә. Ләкин бу әсәр шагыйрьнең Җаекка килүен сүрәтләү белән генә тәмамлана. Димәк, 1895 елдан алып 1913 елга кадәр булган ел вакытта кичергәннәре кермәгән. Г. Тукай "Исемдә калганнар" ның дәвамын да язырга тиеш булган.

1907 нче еллардан соң, Казанга кайткач, Г. Тукай әдәбият мохитенә чума. Г. Камал белән бергә "Яшен", "Ялт-йолт" журналларын оештыра, Ф. Әмирхан нәширлегендә чыга торган

“Әл-ислах” гәзитендә еш язышa. Казанда аның иҗаты тагын да үремле, нәтиҗәле була, сәнгатьчә югары дәрәҗәдә язылган күпчелек әсәрләре шушында туа. Ул вакытта Казанда яшәп иҗат итүче әдәбият әһелләре белән бик тиз аралашып, дуслап китүе дә аның каләменең үткенләнүенә йогынты ясый.

Без Г. Тукай әсәрләрендә халык өчен актуаль мәсьәләләренең күтәрелүенә, аларның кыю фикерләргә, аңа кадәр очрамаган сурәтләү чараларына бай булуына игътибар итәбез. Билгеле булганча, каләм әһеленең иҗат өслүбе аның үз шәхесе белән тыгыз бәйләнгән. Әйдәгез, Казанга кайткан шагыйрьнең замандашлары күңелендә беренче очрашудан нинди тәэсир калдыруына игътибар итик әле:

*Г. Камал*: “Көннәрнең берендә кечкенә генә гәүдәле, өстенә “абыйсының бишмәтен кигән шикелле” кием кигән, өтек кенә бер малай редакөиягә керде дә (“Йолдыз” гәзите редакциясе – Ф.Г.), өстәл өстендәге газеталарны актара башлады.

Бераз укыгач:

- Безнең газета-журналлар сезгә килә торгандыр бит? – диде.

- Сезнең нинди газета?

- “Фикер”, “Әлгасрел-җәдит”, “Уклар”.

- Сез Уральскиданмыни?

- Әйе.

- Алай булгач, ...Габдулла Тукайны да бик яхшы белә торгансыздыр инде?

Малай елмайды да:

- Ул Апуш мин булам, - дип әйтмәсенме?!”

*С. Рәмиев:* “Номер ишегемне ачып:

- Сәгыйть әфәнде Рәмиев шушында торамы? – дип, бер малай килеп керде.

...Аның төсе коңгырт иде. Бәдәне зәгыйфь кенә булса да, әгъзалары бер-берсе илә бик мөнасип, бер күзенә ак төшкән булса да ямьсез түгел, бәлки уртача матур, биек маңгайлы; борыны килешле вә һәр даим тулы булып ачылып торган зур күзле иде. Казанга килгән чакларында 21-22, вафат елында

егерме җиде яшьлек булса да, һаман 14-15 яшьлек бала кебек кенә күренә иде".

*Фатих Әмирхан:* "Әүвәле күрешү миндә Тукаев хакында бер билгеле тойгы калдыра алмады. Тукайны мин үзем белгән татар яшьләре типларыннан берсенә дә нисбәт бирә алмадым. Аның әллә нәрсәсе минем күзләрдән, аңлаштан өртүле калган шикелле булды. Ул...дөрес сүзле, гакыл вә мантыйктан бигрәк, хискә бина итә торган, тормышында садәлекне һәр нәрсәдән алда күрә торган кеше иде". Ф. Әмирхан тагый болай дип өстәп куя: "Тукай хис белән генә тора торган кеше, без аның белән мәхрәм дуслар булып киттек".

Әйе, Тукай үз чорының иң талантлы, әдәбият һәм сәнгать мәйданында үзе кебек ат уйнаткан Г. Камал, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Г. Кәриев, К. Мойтыйгый һ.б. шәхесләр белән аралашып яши, алар белән фикердәш, сердәш, иҗатташ, хезмәттәш була. Аларның бөек шагыйрь турында һәр язганы безгә аның шәхесен аңлауда ачкыч булып хезмәт итә.

Еш кына ул истәлекләрдә шагыйрьнең бер үк вакытта балалар кебек беркатлыгы, самимилеге, инде сабыйлыктан күптән чыккан булса да, малайлар белән мавыгып кузна уйнавы, карусельгә утырып әйләнергә яратуы турында бәян итәләр. Моңа гаҗәпләнергә ярамый. Шагыйрь күңеле, шагыйрь йөрәге еш кына башкалар өчен үзенә күрә сер булып кала. Шагыйрьләрнең дә шагыйре булган Г. Тукай бигрәк тә.

Замандашларының истәлекләрендә Г. Тукайның хатын-кызга мөнәсәбәте турында да еш язалар. Матурлыкны күрә һәм нечкә итеп бәяли белүче, күңеле кешеләргә карата җылы хисләр белән тулы шагыйрь, әлбәттә, хатын-кыз нәфислеген дә күргән, аның турында гүзәл итеп язган. Аның хисләрен "Гыйшык бул, йа!", "Татар кызларына" һ.б. шигырьләрендә күреп була.

Ләкин шул вакытта, каләмдәшләренең язуына караганда, Г.Тукай хатын-кыз күзенә бик чалынырга яратмаган. Ни өчен? Чөнки үзен – ябык кына гәүдәле, бер күзенә ак төшкән егетне – бу гүзәл җан ияләре яратмаслар дип уйлаган. Хатын-кызның күзе иң элек ир-егетнең тышкы кыяфәтенә төшә, синең турында килеш-килбәт буенча хөкем йөртә дип ышануы да аңа шактый

күңел газаплары алып килгән. Кыскасы, табигате белән горур егет хатын-кыз каршында кызганыч хәлдә калырга теләмәгән. Аның бу омтылышын, әлбәттә, аңларга була.

Габдулла Тукай чирләү аркасында, 1913 елның 26 февралендә (иске стиль белән) Клячкин шифаханәсенә кереп ятарга мәҗбүр булла. Ләкин бер айдан аз гына артык вакыт үткәч, икенче апрельдә кичке тугызынчы унбиш минутта аның йөрәге тибүдән туктый.

Ул көннәрдә халык шагыйре Г.Тукай рухына багышланган бик күп шигырьләр, мәкаләләр, истәлекләр языла. Шаехзадә Бабич, аларда әйтелгән төп фикерләрне җыеп, болай диде:

Әй, хөрмәтле Габдулла, ярлыкасын сина Алла,
Шигырең белән рухландырып, салдың безне ак юлга.

Габдулла Тукайга иҗат итү өчен язмыш тарафыннан бары сигез ел гына вакыт бирелгән булып чыкты. Ләкин зур талантларның гомер озынлыгы еш кына аның ничә ел каләм тибрәтүе белән түгел, бәлки үзеннән нинди әдәби мирас калдыруы белән билгеләнә.

Г.Тукай татар шигърияте тарихында үзенә бер аерым урын тота. Ул мең еллык бу олы юлда бик тә әһәмиятле вазифа башкарырга өлгерде: урта гасырлар һәм XIX йөз әдәбиятлары казанышларына таянып, татар сүз сәнгате үсешенең яңа дәверенә нигез салды; шигъриятебезне сәнгатьлелек ягыннан гаятҗ югары дәрәҗәгә күтәреп, аның дөнья мәйданына чыгуын тәэмин итте.

Габдулла Тукай иҗаты – татар халкының йөз аклыгы ул. Мондый шагыйре булган милләт – зур, талантлы, үткәне һәм бигрәк тә киләчәге булган милләт.

**Әдәбият:**


1. Хәсәнов М. Габдулла Тукай. – Казан: Мәгариф, 2002. – 234б.
2. Мусин Ф. Без тарихта эзлебез // Ватаным Татарстан, 2004. – 28 июль.
3. Нуруллин И. Кайту // Казан утлары, 1990. - №2. – 12б.

***Фәсхетдинова З.М. 14 нче лицей укытучысы***

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНА МӨНӘСӘБӘТЕ

Читтәге татарларның туган кавеме белән бәйләнешен саклауда, милли рухны үстерүдә вакытлы матбугат мөһим роль уйный. Болар арасында аеруча Г.Исхакый мөхәррирлегендә Берлинда нәшер ителгән "Яңа милли юл" журналы күренекле урынны ала. Төрки-татарның, күренекле әһелләре - журналның даими игътибар үзәгендә. Болар арасында, әлбәттә, төп урыннарның берсен Г.Тукай алып тора.

Журналның мәсләге, рухы, әлбәттә, иң беренче чиратта, баш мөхәррирга, аның талантына, тәҗрибәсенә, эчке тоемына, доньяга карашына бәйле. Г.Исхакый бу җәһәттән - татар журналы өчен идеал мөхәррир. Ул – бөтен иҗади һәм иҗтимагый сәләтен, тормышын, яшәү максатын милләткә, "милли юл"га багышланган зат.

Тукай һәм Исхакый... Татарның бу бөек ике әһеле, аларның үзара мөнәсәбәте – һәм инсани, һәм милли ноктадан гаҗәеп кызыклы, гаҗәеп актуаль мәсьәлә. Бу хакта инде мөһим генә язмалар да бар. Мәсәлән, мөхтәрәм Ибраһим ага Нуруллин "Г.Тукай һәм Г.Исхакый" мәкаләсендә (Шәһри Казан.- 1993, 17 июль) бу ике затның бер-берсенә ихтирами карашлары турында кызыклы факт-мәгълүматлар китерә. Тукай Исхакый шәхесендә "дали" кешене, милли танны аттыручы затны, зыялыларның остазын күрә, хәтта аны билгеле бер дәрәҗәдә илаһилаштыра да. Г.Исхакый да, гәрчә алар көндәлек тормышта һич очрашмасалар да, Тукайны элек-электән хөрмәт иткән, аны олуг шагыйрь дип таныган, илдә вакытта да, мөһаҗәрәттә дә әдип хакында уңай фикерләр әйткән, бай эчтәлекле мәкаләләр язган. Мәсәлән, "Сүз" гәзитәсенең 1961 ел, 3 апрель санында басылган "Мәтхүм Тукай" язмасы - шуның бер гәүдәләнеше. Шагыйрәнә тел-стиль белән язылган, эмоциональ эчтәлекле бу мәкаләдә Исхакыйның Тукайга гаять җылы мөнәсәбәте, шагыйрь хакында уй-кичерешләре, аның татар тормышындагы бөек роле турында уйланулары үтә дә калку,

үтә дә оста итеп бирелгән. Язма авторы шагыйрьнең бик иртә үлүенә, милләтнең аны саклый алмавына тирән үкенеч белдерә. "Сигез ел фәүкыльгадә авырлыкта кичергән вакытында, шагыйрьлегенең сабыйлык дәверендә татарның гамәл дәфтәренә Тукай ниләр язган булыр иде! Нинди әсәрләр белән, нинди шигырьләр белән татар шигырь дөньясы бизәкләгән булыр иде!" – диелә ул мәрсияви мәкаләдә.

"Яңа милли юл" журналында Тукай мөнәсәбәтле материаллар арасында Г.Исхакыйның шагыйрь турында үзенең дә махсус мәкалә-язмалары бар. Шундыйларның берсе "Тукай истәлеге" дип аталган. Шагыйрьнең үлеменә 20 ел уңаеннан язылган бу материал журналның 1932 елның 11 нче санында дөнья күргән (1-466). Тукай юбилее, - ди мәкалә авторы,- "Тәрҗеман"ның чыга башлавына 50 ел тулу белән бергә туры килә. "Исмәгыйль Гаспринский бөтен төрек иленең уртак пәйгамбәре булганга, "Тәрҗеман"ның 50 еллыгын бәйрәм итү - аны искә төшерү бөтен төрек кабиләләренең уртак бурычы". Чөнки аларның бер өлеше – Төркия "үз эшенә үзе хуҗа". "Тик Тукайның 20 еллыгын кем искә төшерер?" Ул "безнең Идел буе төрек-татарының шагыйре булганга, ул безнең халкыбызның моңын җырлаучы, безнең дәртебезне күпләүче булганга, аны искә алу да турыдан-тугры безнең өстебезгә йөкләнә".

"Әмма,- ди Г.Исхакый,- илдә халкыбыз хокуксыз. Тукай татар халкы өчен аның кайгы-хәсрәтен әйтеп бирә торган бер халык шагыйре булса да, Совет каршында ул-мулла баласы, милләтче, динче; коммунизм каршында - урыслашу тәрбиясенә киртә салучы бер контрреволюционерчы; илебезне-йортыбызны урыс мөһаҗире белән тутырырга теләүче кызыл Мәскәү каршында ул - шовинист милләтче; бөтен большевик сәясәте каршында ул - үзенең халкы кебек, үз илендә бөтен нәрсәдән мәхрүм "хохуксыз- лишинтәс".

Г.Исхакый читтәге татарларны Тукайның үлеменә 20 еллыкны мөмкин кадәр хәзерлек белән тиешле югарылыкта үткәрергә чакыра. Моның өчен, мәкалә авторы, махсус комиссия төзү, шагыйрьнең әсәрләрен бастыру, Тукай турында җыентык

чыгаруны саный. Г.Исхакый фикеренчә, шагыйрьне зурлау, искә алу – милләтнең уртак бурычы.

Баш мөхәррирнең шагыйрь турындагы язмалары арасында аеруча "Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә" мәкаләсе игътибарга лаек (1938.- 4 сан. - 1 - 9 б.) Бу материал яшь галимә кыз Алсу Каримова тарафыннан әзерләнеп, кереш сүз белән "Казан утлары" журналында да басылып чыкты (1999.-4 сан.- 180-1866.)

Г.Исхакыйның гыйльми-теоретик һәм тәнкыйди эчтәлекле бу язмасы шактый кызыклы, полемик рухлы. Мәкалә авторы шагыйрьләрне, "шәхси кабилиятләренә" (сәләтләренә). - Х.М.), иҗади фикерләү үзенчәлекләренә, җәмгыять белән мөнәсәбәтләренә карап, икегә бүленә. Беренчесе - индивидуалист табигатьле, уйкичерешләрен генә үзәккә куючы, "бәйләнәлмиләл шигырьләр" тудыручы авторлар. Икенчеләре исә үзләрен "тирә - юньнең, мөхитнең бер өлеше итеп хис итеп, шуның бөтен күңел алышынуларына үзенең йөрәк тибүе берлә катышып, аның шатлыгына сөенеп, аның кайгысына янып, шатлык-кайгыдан дәрт алып кына шигырь яратучылардыр (язучылар). Болар "туган халкы, аның тирә - юне, яшәгән мөхитнең шул вакытта кичергән уйлары, хисләренең тәрҗеманы (тылмачы), "термометры".

Г.Исхакый беренче төркемнең вәкиле итеп С. Рәмиевне күрсәтә, икенчесенә Г. Тукайны кертә. Соңгысын тасвирлап, ул болай яза: "Үзенең мөхитенең шатлыгын, кайгысын, дәртен шигырь төсенә сугучы бер тел остасыдыр. Аның яшәгән, язган дәвере бездә милләтчелекнең иң кайнаган, милли теләкләрнең берсе өстенә берсе үсеп, тирә - якны тутырган вакыт булганга, ул шул теләкләргә, шул омтылышларга бер шигырь төс бирүче, чуалчык фикерләрдән туган агымнарга тугры юл күрсәтергә теләүче, милләт хезмәтчесе, милли шагыйрьдер... Бөтен кыска гомере буенча ул милли юлдан һичбер тайпылмаенча, кабергә кадәр милләт җырын җырлап, милләт кайгысын көйләп, милләт көлкесеннән көлеп, үзенең калыбына сугып киләдер."

Г.Исхакый Тукай тирәсендәге бәхәсләргә, аны "шагыйрьлек " тәхетеннән төшерергә "маташучы"ларның эшчәнлегенә дә туктала, "Мөнтәкыйдкә" һәм кайбер башка шигырьләрен анализлау аша

Тукай мәсләгенең "дөрес вә тугры" булуын янә бер мәртәбә раслый. "Бәрәкәт боерсын, - ди ул,- Тукайны бу ялгыш тәнкыйтьчеләр бу хата юлларга суга алмадылар. Тукай үз юлында баручы, милләт кайгысын кайгыртучы халык шагыйре булып калды".

Г.Исхакый Тукай шигырьләренең, шул исәптән әдәби тәрҗемәләренең дә тәрбияви әһәмиятенә югары бәя бирә. Шагыйрьнең "Туган тел" парчасы хакында ул, мәсәлән, болай ди: "Милли хис вә милли гакыл бергә кушылып эшләнгән бу шигырь... Тукайның тәрбияви шигырьләренең иң кыйммәтлеседер... Бу шигырь бөтен мәктәпләребездә милли һәймәнә (гимн) тесен ала алмыштыр һәм бу шигыре Тукайны мәңгегә безнең балаларның иң, сөйгән бер җырчысы итеп куймыштыр".

Г.Исхакый, Октябрь инкыйлабына кадәр язган мәкаләләрендәге кебек, биредә дә Тукайны саклап кала алмауга үкенечен белдерә. "...Бөтен төрек-татар дөньясы алдында, -ди ул, - Тукай җилдә яна торган шәм кеби көннән-көн аның актык сәгатьләре якынлаша. Ләкин аны саклау тәдбире (уй - нияте) иң, соңгы вакытка кадәр кичектерелә". Исхакыйның мәкаләсе шушындый юллар белән төгәлләнә: " Тукайның вафатына 25 еллыгы көнендә үксез иленең бүген руслык хөкеме сөрән үксез почмагында ятим яткан кабере алдында тезебезне чүгәмез. Исән вакытта кирәге кадер кадерен белмәгән, кыйммәтен танымаган милләтнең, бүгенге хөрмәтен, сөйгесен газиз рухына сонабыз (багышлыйбыз).

"Яңа милли юл" журналы һәм Тукай... Билгеле бер күзәтү ясау да бу ике төшенчә арасында тыгыз, табигый мөнәсәбәтләр яшәвен ачык күрсәтә. XX гасырдан башлап татар яшәеше шагыйрь рухы белән сугарылган. Тукайсыз милли юлның яңасы да, искесе дә юк.

Шушы хакыйкатьне тирәнтен аңлаган һәм чынбарлыкка тугры калган журнал нәкъ менә шуңа күрә дә Тукайга үзенең түрен бирә, аны милли үзлекнең мөһим бер символы итеп карый.

Безгә бөек шагыйребез хакындагы һәр төрле мәгълүматны, шул исәптән "Яңа милли юл" журналындагы материалларны да өйрәнергә, бүгенге югарылыктан торып анализларга кирәк. Бу-татар халкының әхлакый, инсани һәм милли бурычы.

**Әдәбият:**

1. Нуруллин И. Г.Тукай һәм Г.Исхакый// Шәһри Казан, 1993, 17 июль.
2. Миңнегулов Х. "Яңа милли юл" журналы// Казан утлары, 2002, №5,17 б.
3. Нуруллин И. Макталган һәм тапталган әдип// Казан утлары, 1994, №6, 1286.
4. Мусин ф. Гаяз Исхакыйның милләчелеге турында// Мирас, 1993. №1, 126.

***Нәбиуллина Э.Р. 13 нче лицей-интернат,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## ТУКАЙ ҺӘМ ӘМИРХАН ДУСЛЫГЫ

Татар галимнәренең вә чит илләрдәге фән эшлеклеләренең даими эзләнүләренә карамастан, Тукайның иҗаты һәм аның шәхси хәяты турында әле соңгы сүз әйтелмәгән һәм әйтелмәячәк тә, чөнки фән - ул чиксез дәвам. Язучы Р.Батулла Тукайга бәйле һәр нәрсә белән кызыксынуын болай аңлата: "Гади кызыксыну имеш-мимеш теләгемне канәгатьләндерер өчен генә түгел, ә бәлки иҗатым өчен, Тукай кебек даһиның рухын өйрәнер өчен кирәк." Тукайны үзе яшәгән заманасыннан башка күз алдына китереп булмый, аны бөек шәхес иткән нәрсәләр – яшәгән мөхите, аның якыннары, дуслары. Шагыйрьнең тормышында аеруча зур урын тоткан, күп булмаган дусларының берсе -Фатих Әмирхан.

Тукай белән беррәттән 2011 елда Фатих Әмирхан тууының да 125 еллыгы билгеләнеп үтте. Гаять үзенчәлекле, киң кырлы бу шәхесләрнең дуслыгы, Тукай Уральскийдан Казанга килгәннән соң башлана.

Г.Тукай Казанга 1907 нче елның октябрь башларында килә. Ул әле бары тик 21 яшьлек егет кенә, ләкин аңа карамастан Уральскида "Әлгасрелҗәдид", "Фикер", "Уклар" кебек гәзит-журналларда эшләп, аның исеме инде берникадәр танылган була. Тукай Фатих Әмирхан белән беренче күрешүе хакында болай сөй-

ли: "Мин Казанга килеп җиткәч, безне Борһан Шәрәф таныштырды. Ул мине Фатих Әмирхан янына алып барды. Фатих ул чагында Яңа бистәдә этисенең йортында торадыр иде. Ул безне ачык йөз, көлке сүзләр белән каршы алды."

Беренче очрашуда гади генә киенгән, кешегә алай ук ачылып китми торган, сөйләшкәндәә кыска җаваплар белән генә канәгатьләнүче яшь шагыйрь Фатих Әмирханда бернинди дә тәэсир калдырмый. Ләкин инде "Әлъислах" газетасы редакциясендә очрашып бергә эшли башлагач, Фатих Әмирхан белән Габдулла Тукай зур сердәш дуслар булып китәләр, һәм аларның бу дуслыгы гомерләре буе дәвам итә.

Г.Тукай Ф.Әмирханга фикере белән хисаплашырга лаеклы булган чын кеше итеп караган, аны ихлас куңелдән якын кургән, бөтен нәрсәсен аның белән уртаклашкан. Ул дусты хакында сүз чыкканда танышларына: "Мин аны беренче күрүемдә үк яраттым," - дип әйтә торган булган.

Тукай кешеләргә авыр якыная, аның белән чын дуслык мөнәсәбәтенә керү җиңел түгел. Шуңа күрә, шәхси ихтирам саклашып та, моның аерышмас дуслык дәрәҗәсенә күтәрелмәве дә мөмкин. Әмирхан белән Тукай арасында дуслык чагыштырмача тиз урнашкан. Телдән яисә язма рәвештә мөрәҗәгать иткәндә, "Фатих"ка ялганып килә торган "әфәнде" сүзе юкка чыга, "сез" "син"гә әверелә. Ярты ел да үтми, эчке дөньясына тыкшынучыларны җене сөймәгән кебек, үзе турында, уй-тойгылары, кайгы – хәсрәтләре турында сөйләргә яратмый торган Тукай күңел капчыгын Казанга килгәч беренче тапкыр Әмирхан алдында чишә. Ул үзенең килеп эләккән даирәсеннән риза булмавын, шуның өчен борчылуын белдерә: "Мин Казанга килгәннән бирле соң дәрәҗәдә эшлексезләндем. Минем булмәдә көне-төне буе вакытларын кайда куярга белмәгән кешеләр җыелып яталар," - дип әйтә.

Тукай Казанга ничек кенә атлыгып кайтмасын, биредә үткәргән беренче айларыннан никадәр генә кәнәгатьлек белдермәсен, килүенә бер ел да үтмәстән, Фатих Әмирханга зарын ишеттерә башлый. Менә аның Фатихка язган хатыннан өзек: "Ярабби! Ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, ачлыклар, авылдан-авылга

сатылып йөрүләр, рәхимсез татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәсендә черүләр арасында да саклап килдегем истигъдат (сәләт) очкыны шушы исереклекләр, исерек иптәшләр арасында бер дә кабынмаслык булып сүнәрмени инде?" Ни өчен соң Тукай менә шушындый "чиле-пешле" кешеләр арасына эләккән һәм үзләрен танып алгач, ник алар белән арасын өзмәгән? "*

Бу егетләр Габдуллага башта Казанның алдынгы яшьләре булып күренгән. Уен-көлке, тормышка җиңел караш. Габдулланың да күңелендә бәйрәм. Ләкин вакыт үткән саен "бәйрәм"нең җайсызлыклары аңа күберәк сизелә барган."Укыйсы, язасы, өйрәнәсе бар. Эшкә утырасың гына, шаулашып килеп керәләр, өстәлдәге кәгазьләрне, газета-китапларны читкә шудырып яисә бөтенләй идәнгә себереп төшереп, табын әзерлиләр. Шапылдатып шешә утыртып куялар, сыра шешәләре тезәләр. Китә кызып мәҗлес. Кечкенә бүлмә төтен белән тула. Аннары карта уйнау башлана. Тукай бүмәсендә башланып киткән мәҗлес еш кына ресторанда яисә берәр сыраханәдә дәвам итә, кайвакыт шикле урыннарда очлана. Тукайның шәкерт чагында ук хәмерне ара-тирә авыз иткәнлеге билгеле. Моны исә тыелган нәрсә булганга, тәртип һәм кагыйдәләргә каршы баш күтәрү рәвешендә эшләнгән дияргә була.

Ф.Әмирхан Тукай килеп эләккән урталыкның аңа килешә торган урын түгел икәнен аңлаган, шактый көч сарыф итеп аны яңа бер тирәлеккә кертү өстендә эшләгән, хәтта аның тормышын тәртипкә салу теләге белән өйләндерү ягын да караган. Ләкин соңгысының нәрсә белән бетүе безгә билгеле. Ә нинди тирәлеккә якынайтырга тели соң, ул аны? Үзе була торган тирәлеккә дип уйларга кирәк: Казанның милли аристократиясе дә, яңа карашлы байлары, университетта укыган интеллигенциясе дә бар. Әмма Тукай ул даирәләргә сыя алмый. Шул ук вакытта ялгыз яшәп тә булмый. Якын күргән берничә кеше кала: Фатих, Галиәсгар, Сәгыйть.

"Без Тукай белән тәмам танышып җиттек вә бик тиз арада бер-беремезгә ихтирам саклаша башладык,"...мәхрәм дуслар булып киттек", - дип яза Әмирхан.

Әмма гаять үзенчәлекле дуслык бу. Алар икесе дә көлергә оста. Идеаллары бер булса да, зәвыклары, гадәтләре шактый аерыла. Тукайның характер сыйфатларыннан, гадәт һәм яшәеш рәвешенә күз ташлыйк. Мәсәлән, Тукайны өс-баш, кием-салым ягыннан караганда, ул ни бар шуны киеп йөри, галстук, ак яка, манжетларны җене сөйми. Яисә Тукайның ара-тирә уянып куя торган "малай"лыгы. Ул урам малайлары белән кузна уйнарга ярата, кайвакыт исә яланаяк калып, ихлас күңелдән хәрәмләшә-хәрәмләшә уйный. Ташаяк ярминкәсенә барып, бала-чагалар белән бергә карусельда әйләнүе дә хак. Габдулланың мәчеләр, этләр белән уйнашуы, мәче балаларын һәм көчекләрне номерына алып кайтып, ипи-сөт белән сыйлавы турында сөйлиләр.

Күпләргә сәер булып тоелган тагы бер гадәте - хатын - кыздан качуы. "Әлъислах" идарәсенә Фатих Әмирханның танышларыннан берәр хатын-кыз килеп керсә Тукай, билгеле, шундук чыгып китү ягын карый.

Ниһаять, акчага һәм байлыкка карата мөнәсәбәте. Шагыйрь шундый фикердә була: "Тамак туярлык, бер дәрәрҗәдә мәгыйшәт итәрлек булгач, акчаның нигә кирәге бар?"

Ә бит Казанга килеп, бер-ике ел да үтми, Тукай язмалары өчен иң зур гонорар ала торганнардан була. Китабы артыннан китабы чыга, гаилә карыйсы юк, таләпләре дә зур түгел. Димәк, эшләп алганы артыгы белән җитәргә тиеш. Әмма Тукайның кесәсендә акча кергән тизлеге белән чыгып китә: аньң тирәсендә бурычка дип алып, кайтармаучылар да җитәрлек, кием-салым, азык-төлек алуда да сатулашып тору юк, китапны да ташып кына тора, алары да бик тиз кешеләр кулына кереп бетә.

Фатих Әмирханга карасак, кием-салымда модадан калышмыйча, европача зәвыкъ белән киенә. Кешеләр белән мөгәләмәсендә гади, уен-көлкеле булса да, дәрәҗәсен саклый белә. Хатын-кыз белән аралашырга ярата, җиңелчә флирттан да качмый. Акчага табынмаса да, иркен, мул, культуралы яшәргә мөмкинлек бирерлек микъдарда керем булдырырга тырыша.

Тукайның характер сыйфатлары һәм үзен тотышы Фатихка чиктән ашу булып күренгән кебек, Тукай да Әмирханның гадәт-холкын, яшәеш рәвешен кабул итеп бетерә алмыйм.

Ф.Әмирхан якын итеп Тукайга үзенең нечкә, нәфис энәләрен җибәргәләгән. Тукай да, җавап итеп, авыртгырып кадый торган энәләрен озаткалаган.

Әмма ни генә булса да, бу ике бөек шәхес бер үк идеал хакына кулга-кул тотынып барганнар, бер-берсенә олы хөрмәт саклаганнар, бер-берсен яратканнар.

"Әлъислах" эшеннән туктатылганнан соң яңа чыгып килә башлаган "Кояш" газетасы Фатих белән Габдулланы берләштерүче була. Газета идарәсе "Амур" кунакханәсенә урнашкан була. Фатих Әмирханны бу газетаны җитәкләргә билгелиләр, ул "Амур"дан номер алып тору фикеренә килгән. Әмирхан тәгъдим иткәнме, әллә инде Тукай үзе кабынып киткәнме: бервакыт алар "Амур"ның күрше номерларында тора башлыйлар.

Бу факт Тукай белән Әмирхан арасында соклангыч олы дуслык яшәгәнлекне тагын бер кат раслый.

Фатих Әмирханның 1914 елда язылган "Тукай үлеме алдыннан" исемле хатирәсе бар, Ул: "Тукайньң номеры белән минеке күрше иде. Аның төне буе горык-горык йөткергәне миңа аермачык ишетелеп тора иде," - дип яза. Шундый төннәрнең берсендә бик озак йөткерүләреннән соң Тукай: "Ялгызлыкта үлемнән качып синең янга кердем әле," - дип Әмирханның бүлмәсенә керә. Шул вакыт "...йөрәк сикеренде, җан куркынды, бугазга яшьләр килеп тыгылдылар. "Мә, Тукай, ал минем таза үпкәләремнең берсен, берәр үпкә белән дә дөньяда торырмыз әле," - дип кычкырасы килгән шикелле булды," -ди Фатих Әмирхан. Бу төннән соң инде озак вакыт үтми, аны Клячкин хастаханәсенә илтәләр. Китер алдыннан ул Фатих белән хушлашырга керә:

Моннан соң күрешмәсәк... хуш инде! - ди Тукай, сабыйларчарак шат йөз белән. Тиз терелеп чык, тиз күрешик!

- Юк, тиз күрешмик әле, син озаграк яшә! - дип Тукай чыгып китә.

Тукай вафатыннан соң да Фатих дустының үлемен бик авыр кичерә. Тукайның Фатихка дустанә мөнәсәбәте һәм ышанычы никадәр көчле булса, Фатихның Тукайны якын итүе дә шулай ук бик көчле була.

Йомгак сүзе урынына Салават Юзеевның Тукайга багышлап төшерелгән "121" фильмының азагында журналист белән Ф.Әмирхан арасындагы әңгәмәне китерәсе килә:

- Сез үзегезне ничек хис итәсез? - дип сорый журналист.
- Анысы сезгә нәрсәгә?
- Реаль булмаган затларның хәл-әхвәлләрен белү кызык ич.
- Кадерлем! Без сезгә караганда күпкә реаль затлар, - дип җавап бирә Әмирхан. Чыннан да, Тукай, Әмирханнар үлем белән тәгәлләнә торган ноктада тукталып калмыйча, тарихта, халык күңелендә мәңге яшиләр.

**Әдәбият:**


1. Әмирхан Ф. Әсәрләр. 4 томда. 4 том. / Ф. Әмирхан - Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. - 3906
2. Батулла Р. Урыннары җәннәттә булсын. / Р. Батулла - Казан: Рухият, 2007. - 992 бит.
3. Нуруллин И. Габдулла Тукай. /И. Нуруллин. - Казан: Татар, кит. нәшр., 1979. - 301 б.
4. Рәсүлева 3. Э. Тукай эзләреннән. / З.Э. Рәсүлева. - Казан: Тат. кит. нәшр.. 1985. - 141 бит
5. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. 2 томда. 2 т. / Г. Тукай - Казан: Татар, кит. нәшр., 2006. --383 б.
6. Фатих Әмирхан турында истәлекләр. - Казан: Татар, кит. нәшр., 2005. - 255 б.



***Хисамиев И. 10 нчы мәктәп укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Хәкимова Р.Р.,***
***татар теле һәм әдәбият укытучысы***


## Г. ТУКАЙНЫҢ ШАГЫЙРЬ БУЛЫП КИТҮЕНӘ СӘБӘПЧЕЛӘР

Габдулла Тукайның шагыйрь булып китүендә сәбәпчеләр.

Белгәнебезчә, Габдулла Тукайның тормышы, язмышы бик катлаулы булган. Кечкенәдән үк аны язмыш төрлечә сынаган, каккан, үзенчә яраткан....

Кечкенәдән үк ятим калган Апушка кемнәр җылы кулларын сузганнар да, кемнәр ярдәм итәргә тырышканнар? Бу сорауга без төрле китап-журналлардан мәгълүмат эзләдек, таптык.

Әтисе-Мөхәммәтгариф Мөхәммәтгалим улы 44 яшендә кату зәхмәтеннән үлә. Габдуллага 4 ай була. Әнисе-Бибимәмдүдә Сасна пучинкәсенә икенче мәртәбә тормышка чыга. Кечкенә Габдулланы Кушлавычка алып барып, Шәрифә исемле карчыкка калдыра. Беренче булып Шәрифә карчык ярдәм кулын сузган. Әнисе үлгәндә Тукайга 3,9 ай була, тома ятим кала. Өчилегә бабасы Зиннатулла янына кайтарыла. Базарда "Асрамага бала бирәм, кем ала?",-дип кычкырып йөргәндә Мөхәммәтвәли белән Газизә исемле кешеләр алып китәләр. Бабасы Зиннатулла Газизәләрдән соң Габдулланы Кырлайга Сәгъдигә асрамага биреп җибәрә. Үги әнисе Зөһрә абыстай укырга илтә. Габдулланың иң беренче мөгаллиме-Кырлай да Маһруйбикә абыстай була. Аннан соң аны Кырлайдагы хатиб һәм мөгаллим Фәтхерахман хәзрәт Гатаулла укыта. Уральскидагы җизнәсе Галиәсгар Госманов, хатыны Газизә үз янына чакыртып ала. Г.Тукай "Мотыйгыя" мәдрәсәсендә укыганда шагыйрь Мирхәйдәр Чулпаный белән таныша. Төрек егете Габделвәли Әмрулла белән таныша, дуслаша, аннан төрек телен өйрәнә. Тукай Уральскидан Өчиледә яшәүче Саҗидә апасына (Бибисаҗидә Зиннатулла кызы Хәбибуллина) хат яза. Хатында үзенең эч-серләре белән уртаклаша. Сабакташы Шәриф Каюмов үзенең истәлегендә Г.Тукайның "Кара урман", "Зиләйлүк", "Тәфтиләү" кебек татар халык көйләрен яратып җырлавы турында яза. Г.Тукай Уральскидан Гурьевтагы туганнары Абдуловлаларга хат яза (Әхмәди һәм Әүхәди). Хатында ул үзенә ярдәм иткәннәре өчен бу туганнарына рәхмәтен белдереп хат яза. Бер белдерүдә Г.Тукайның киләчәктә чыгачак басма "Әлгасрелҗәдит" журналының язышучыларыннан берсе булачагы турында

әйтелгән. Журнал эшенә катнашачак язучылар исемлегендә Тукай белән янәшә Г.Ибраһимов, Р.Фәхретдинов, Г.Исхакый, Ф.Кәрими фамилияләре кертелгән. Тукайның сабакташы шагыйрь Әхмәт Байтирәковка багышлап язган шигыре бар. Бу шигырьгә каршы Ә.Байтирәков Тукайны мактап хат язган. Тукайның дусты, сабакташы Ярулла Морадый истәлекләрендә шундый белешмә бар: “Беркөнне Тукай иптәш бөтенләй язу эшләренә бирелергә уйлады. Миннән ун тиен акча сорап алды да кәгазь вә карандаш сатып алды да Крыловның басняларын татарчага тәрҗемә итәргә тотынды”. Г.Тукай үз чорының мәдәни тормышында актив катнашкан журналист, укытучы Сәгыйть Кәримгә хатлар яза. Г.Тукай Ф.Кәримгә хатлар яза. Уральск эшчеләре үткәргән митингта матбага эшчесе А.Гладышев белән бергә, революцион прокламацияләр таратуда катнаша (аңа гел кул сузып, булышып кына да тормыйлар, каршы килүчеләр дә күп була. Уральскиның Хәлим Ахун, Тукай катнашындачыккан “Фикер” газетасын яптыруны таләп итеп, Уфага мөфтигә хат яза. Таләбе үтәлмәгәндә шул турыда Эчке эшләр министрлыгына шикаять җибәрәчәген белдерә). Тукай танышлары, дуслары белән карточкага төшәргә бик яраткан. Ул Уральскида Нәҗип Нигматуллин (Казан миһманханәсе буфетчысы), Рәхматулла Хәйруллин (М. Гобәйдуллинның приказчигы), Сиражи шәкерт белән карточкага төшә. Тукай Уральскида М.Мусин, К.Төхвәтуллин белән бергә, “Яңа тормыш” газетасын чыгару турында килешүгә кул куя. Тукайны журналист Борһан Шәрәф Ф.Әмирхан белән таныштыра. Бу ике зур әдип арасында эчкерсез дуслык гомерләре буенча дәвам итә. “Йолдыз” газетасы редакциясендә җаваплы секретарь булып эшләгән Г.Камал белән таныша. Бу ике зур әдип арасында дуслык гомерләре буенча дзвам итә. Г.Тукай “Әл-ислах”чылар белән фоторәсемгә төшкән: Г.Тукай, И.Әмирхан, Ф.Әмирхан, К.Бәкер, В.Бәхтияров. Казанга кайткач, Шәрәфләр матбагасында Гыйльметдин Шәрәф белән очраша. Спектакльгә баралар. Бу турыда Г.Шәрәф болай ди: “Менә шул минуттан без Габдулла әфәнде белән күреп таныш һәм соңгы көннәренә кадәр икебез дә Казанда булган вакытта бик еш-еш күрешә идек, Казан теле

белән әйтсәк, “кашыклы аштан калмый торган” дус, иптәш булып китәбез.” Габдрахман Дәүләтшин оештырган “Китаб” нәшриятында экспедитор булып урнаша. Мәхмүт Дулат-Алиевлар йортында Г.Тукай М.Дулат-Алиев һәм Х.Ямашев белән очраша. Шуннан соң алар арасында фикри дуслык урнаша. Үги әнисе Газизә апа белән күрешә. Г.Тукай: “Яңа бистәдә, җимерек кенә җир астындагы бер өйдә бер карчык бар икән. Көннәрдән бер көн мин, ничектер, шул өйгә чакырылдым. Анда мине әнкәем көтеп торачак иде. Кергәч тә.кара кашлы, кара күзле,яше кырыклардан узмаган диярлек, тулы гәүдәле бер хатын күренде. Моның әни икәнлеген танып: “Исәнме, әни”,- дип күрештем. Ул кулын бирде дә егълап җибәрде”. Г.Тукай авырып больницага яткач, аның янына Маһруй Мозаффия дус кызы Фатыйма Дәүләтгилдиева белән Клякин шифаханәсенә киләләр. Докторның киңәше буенча Ш.Әхмәров һәм Ә.Урманчиев саклап чыгалар. “Аң” журналы редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни килә. Бу вакытта Тукай янында Әмин Мостафин да була. Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның йөрәге тибүдән туктаган вакытта янында Әмин Мостафин була.

**Әдәбият:**

1.Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы.Казан: Татрстан китап нәшрияте,2003.271б.

2.Ибрагим Нуруллин Напевы мятежного саза. Габдулла Тукай Стихотворения, поэмы, сказки.

3.Габдулла Тукай Сайланма әсәрләр,шагыйрь турында истәлекләр. 7 том.2002.

***Габдуллина К.Т. 27 нче мәктәп,***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## ТУКАЙҺӘМ УФА

Бөек әдибебез Габдулла Тукайның татар халкының рухи тормышында гына түгел, бөтен төрки дөньясында тоткан бәяләп

бетергесез урыны турында бер гасыр буена бик күп язылды. Һәр халык, һәр милләт, һәр төбәк аның белән бәйләүче җепләрне юллый, тикшерә, шул бәйләнешләр турында горурлык хисе белән гыйльми хезмәтләр, шигырьләр, поэмалар, хәтта зур-зур чәчмә әсәрләр дә иҗат итте һәм итә.

Башкортостан җирендә яшәүче татарларны һәм башкортларны, татар халык шагыйре белән бәйләүче җепләр аеруча күп һәм үзенчәлекле.

Габдулла Тукай кече яшеннән үк, үз сүзләре белән әйткәндә, “җырларымызда шулкадәр күп җырланган” Агыйдел һәм Дим буйларын, фольклор әсәрләренә тарихи нигез биргән Ашкадар, сакмарларны үз итеп үсә. Әле Җаекта яшәгән үсмер елларында ук, ул куен дәфтәренә “Фатыйма”, “Стәрле”, “Агыйдел” кебек башкорт җырларын да терки.

1919 нчы елда Казандагы “Шәрык” клубында укыган “Халык әдәбияты” исемле лекциясендә ул, татар җырлары белән беррәттән, башкорт халкының “Ашкадар” җырының тарихына һәм үзенчәлекләренә дә туктала. Казанда Габдулла Тукай белән еш очрашкан әдип һәм библиограф  Исмәгыйль Рәмиев үзенең хатирәләрендә болай дип яза: “Башкорт баласы,  – ди торган иде ул миңа, гәрчә Уфа ягы Урал буе типтәре булсам да,  – “Ашкадар”ны җырла әле.” Шагыйрь үзе дә җырга кушыла...

Тукайны Башкортостан белән бәйләүче җепләр турында сөйләгәндә, танылган галим Суфиян Сафуанов  аның турындагы хезмәтләрдә бер тапкыр да диярлек телгә алынмаган тагын бер фактка тукталып үтә. Бу – галим, башкорт халкының азатлык хәрәкәте лидеры Зәки Вәлиди белән мөнәсәбәте.

“Хатирәләр” дигән китабында язуынча, Зәки Вәлиди, 1908 нче елда Казанга баргач, ислахчы (реформа тарафдарлары) яшьләр белән аралашып, аларның милли эшләрдә, мәгарифтә үзгәртеп кору планнары, максатлары белән таныша һәм “Бәянел-хак” гәзитендә, шуңа бәйле рәвештә, үз фикерләрен чагылдырган мәкалә белән чыгыш ясый. Аның фикерләре Г.Тукай белән Ф.Әмирханга ошамый. З.Вәлиди сүзләренә караганда, Ф.Әмирхан бу уңай белән бер-ике мәкалә дә бастыра.

Алар арасында кискен мөнәсәбәт соңрак та дәвам итә. Г.Тукай исә З.Вәлидинең “Бәянел-хак”тагы чыгышы турында “Улмы? – Ул...” дигән шигырь язып, “Әльислах” гәзитендә (1908, 23 нче сентябрь) бастыра. З.Вәлиди дә ят псевдоним белән аларга җавап эпиграмма бастырып чыгара.

“Язулары кимсетү рәвешендә иде, – дип яза соңыннан З.Вәлиди. – ...Бераз вакыт үткәч, шагыйрьнең үзе белән танышканнан соң, мәкаләнең авторы ...мин икәнлеген белде һәм эпиграмманың кайбер сүзләре урынсыз булуын аңлады... Габдулла Тукай отельдә берүзе яшәгән чакта аның янына еш кына бара идем”. З.Вәлиди шул аралашу-аңлашулар нәтиҗәсендә, Г.Тукайның аның чыгышында әйтелгән кайбер фикерләрен һәм максатларын ялгыш аңлаганын белдереп мәкалә язуын, әмма аның басылмый калуы турында әйтә...

Әнә шулай, Башкортостан, аның кешеләре, рухи тормышы Г.Тукай өчен һич тә чит һәм ят булмый.

Шуңа күрә, 1912 нче елның язында, авыру шагыйрьнең сәламәтлеген кайда ныгыту мәсьәләсе кузгалгач, иптәшләренең киңәше, Троицки мулласы Габдрахман Рахманкуловның чакыруы буенча, Тукай аның янында кымыз эчеп дәваланырга була. Әле кымыз ясау мәле җитмәсә дә, Самарада һәм Уфада бераз вакыт торырга исәпләп, ул пароход юлы ачылу белән юлга чыга.

Казандагы “Йолдыз” гәзитенең 1912нче елгы 17нче апрель санында: “Сәфәр”: “Г.Тукай 14нче апрель Самарага китте, аннан озак вакыт кымызга чыга” дигән кыска гына хәбәр урнаштырылган. Димәк, яңа стильгә күчерсәк, ул Казаннан 27нче апрельдә кузгала. Ә 16 (29) апрельдә Самарадан поезд белән Уфага юнәлә.

Ул вакытта вокзалдан шәһәргә menә торган бердәнбер юл хәзерге Вокзал, Кировоградская урамнары салынган җирдән үтә һәм Аксаков урамына килеп чыга. Үзенең шәһәргә менү юлыннан алган беренче тәэсирен Г.Тукай менә ничек бәян итә: “Уфага җиттем. Тау башына тәртипсез таралып утырган. Извозчикка утырдым... Арбасы шундый иске, шундый каты иде ки, эчәкләрем, такта арбага буш салган дилбегә кеби, үрле-

кырлы сикерә иде. Таудан акрынлап менәсең. Юлның әтрафында җәһәннәм кеби тирән чокырлар хисабы юк. Җәһәннәмнәрнең тирәсенә саклык өчен тезгән баганаларның арасы бик сирәк булып, арба янтайса, мөкиббән галә вәҗһиһи җәһәннәмгә төшү бик мөмкин иде.”

Шулай “кая соң моның шәһәрлеге?” дип сукранып барганда, ул Кәримовларның “Сабах” дигән китап кибетенең вывескасын күреп кала һәм, шәһәрдәге кунакханәләрне сорашу өчен шунда туктала (бу йорт хәзерге Свердлов һәм Карл Маркс урамнары чатында). Һәм ул шунда, сатарга китерелгән китаплар складында урнашып та кала. Аста кухня икән, һәрвакыт җылы бәреп тора. Авыру шагыйрь өчен “икенче ләүкә!” Китап төяп китерелгән әрҗәләрне тезеп, караватясыйлар, өстенә җәймә каплыйлар.

Уфада ул беренче мәртәбә татар әдәбиятының икенче классигы Мәҗит Гафури белән очраша. Җәмәгате Зөһрә Гафури истәлекләренә караганда, Мәҗит базарга барган җиреннән (ә базар нәкъ “Сабах” китапханәсенең каршында, хәзергә авиация-техник университеты урынында булган) Г.Тукайның Уфага килүе турында ишетеп кайта да, аны үзләренә чакырырга тәкъдим итә. Гафури, тиз генә киенеп, шәһәрдәге “Сибирская гостиница”, “Нур”, “Сарай” номерларын йөреп чыга, аларда шагыйрьне тапмагач, берәр нәрсә белмиләрме икән дип, “Сабах”ка барып керә.

Зөһрә ханым үзенең хатирәләрендә Гафуриның шундый сүзләрен китерә: “Мин керү белән приказчик малай әкрен генә: “Мәҗит агай, Тукай килде бит”, - диде. “Кайда төшкән соң ул, мин иртәдән бирле эзләп йөрим инде”, - дидем. Ул тагы, тавышын акрын гына чыгарып: “Бездә ул, әнә артта”, - диде. Мин ышанмыйча кибет артындагы запас китаплар торган бүлмәне ачып карадым. Аптырап киттем. Китап ящиклары өстенә юка гына бер келәм җәеп, ике кулын баш астына куеп, бәләкәй генә мендәрдә Тукай чалкан ятып тора иде. Мине күрүгә торып утырды да бик нык ютәлли башлады. Һәм ютәлләп бетәр-бетмәс, бик нык сагынышкан дусларча кочаклашып күрештек.”

Гафури аны өенә чакыра. Г.Тукай: “Мәҗит туган, мин гаиләле җиргә бара алмыйм. Уңайсызланам. Әгәр теләсәң, берәр җирдә кунак итәрсең”, - ди. Ләкин ничек кунак итәргә? М.Гафури, өенә кайтып, инде язга чыккач кирәге беткән кышкы пальтосын күрше бабайдан өч сумга саттырып, Тукайны кунак итәргә китә.

Очрашу күренешләрен Г.Тукай үзенең “Мәкаләи махсуса”сында, М.Гафури 1914нче елда “Ил” гәзитендә басылган истәлекләрендә теркәп калдырганнар. Ике шагыйрьнең күрешү куанычы артында шул чорның кара реакция сөреме тудырган вәзгыять чагылып тора. “Мәҗит әфәнде Гафури белән күрештек. Ул миңа караганда да җуашланган вә дөнья тарафыннан басылган кебек күренде. Аның белән безнең мосәхәбәмез күп вакыт күзләр аркылы гына кыйлына иде. Читтән безне караган кеше, икемезне әле генә хисаплы каты шаярып, соңра аналары кыйнап, бер минут элек кенә җылаудан туктаган балаларга охшатыр иде... Русиядә хәзер уйнаган җилләр вә Русия һавасы безнең бөтен коллегаларымызны шул халәте рухиягә китергән...”, - дип яза Тукай.

М.Гафури Г.Тукайны шәһәр күрсәтер, берәр ашханәгә алып керер өчен, берничә тапкыр урамга алып чыкса да, кунакның нык авыру булуы аңа иркенләп йөрергә мөмкинлек бирми. Беренче чыгуларында извозчикка утырып, Александров (хәзерге Карл Маркс) урамыннан Пушкин урамына борылып, бераз баруга, таш түшәлгән юлдан тимер шинлы арбада бөтен эчәкләре селкенүләре түзә алмыйча, аннан төшеп, түбәнгә таба җәяү генә китәләр. Бер ашханәгә кереп, аз гына утыруга, алар өстәленә каршы ике толчокчы килеп урнашкач, Казанда да шундый шикле кешеләрдән ялкып беткән Тукай Гафурины моннан тизрәк чыгып китәргә кыстый...

Гафуриның баерак кешеләрдән резин тәгәрмәчле арба-ат сорап йөрүе нәтиҗә бирми. Шуңа күрә Тукай үзе: “Уфада шактый вакыт торсам да, аның эчен вә әтрафын карап йөри алмадым. Мәҗит белән йөрергә чыксам да, ярты юлда хәл беткәч, өйгә борыла идем. Монда трамвай юк. Извозчикта эч

кенә авырта, эч авырттырмый торганына утырсаң, кесә авырта иде," – дип яза.

Шулай да шәһәр белән азмы-күпме танышкач, аның Уфага килеп кергәндәге беренче тәэссоратлары беркадәр йомшара. "Уфаның мәгъмурият ягы Казаннан күп начар булса да, табигать ягы күп шәһәрләрдән өстен. Әүвәл үк ул тау башында. Димәк, җәй көне дә, кыш көне дә һава яхшы. Җырларымызда шулкадәр күп җырланган Агыйдел буенда. Шәһәр эчендә йортларга караганда агачлар күп диярлек. Моның җәй көнегә әһәмияте! Өстән караштa Уфаның халкы да айнык вә саф күренә. Чөнки бу шәһәрдә чат саен халык саулыгын химая итә торган сөт кибетләре. Һәммәсендә халык. Пивнойлар сирәк."

Бу вакытта әле Уфада кымыз булмый, Троицкига да кымыз эчәр өчен барырга иртәрәк. Шуңа күрә Тукай, Петербургка чакырып берничә хат алуын исенә төшереп, шунда барып килергә карар кыла. Авыру шагыйрьгә Петербургның юеш, суык һавасы бик начар тәэсир итә. Майның 7-8ләрендә (яңача 20ләрендә) Уфага урап кайткач, күңеле күтәрелеп китә, хәзер аңа бөтенләй башка күз белән карый: "Уфага кайтсам, Уфа мине кияү көткән кыз кеби көтеп торган!" – ди ул куанып. Казанга Ә.Урманчиевка 11(24)нче майда җибәргән хатында ул: "...Бу шәһәрнең һавасы ләтыйф, саулык багышлар булганга, хәвефсезрәк күрәм. Агыйдел буендагы бакчага барып, берничә сәгать агач төпләрендә кырын ятам. Шунда ук кымыз да бар", - дип яза. Шул ук вакытта ул: "Уфада гына торган булсам, хат түгел, мәкаләләр дә язган булыр идем", - дип тә өсти.

М.Гафури да үзенең хатирәләрендә: "Кымыз эчеп, саф һавада яту Тукайның сәламәтлеген кайтарган кебек булды. Һаваны мактый, иркен сулу ала, ике сүзнең берсендә "Сәламәтлек һавасын эчәм", - дип сөйли иде. Шул ук вакытта М.Гафури: "Уфа Тукайның дәрәҗәсенә лаек һичбер хәрәкәт күрсәтә алмады. Тукайның Уфага килү хөрмәтенә һичбер мәҗлес-фәлән тәртип кылынмады, - дип хәтерләде соңыннан. – Бер гаиләдән башка, хосуси дәгъвәт итеп (чакырып), күңелен ачучы да булмады." (Телдән сөйләнеп йөргән хатирәләргә

караганда, бу гаилә – татар морзалары Дәүләткилдиевлар булса кирәк).

Аның каравы, Г.Тукайның үзе янына, “Сабах” кибет артындагы бүлмәгә шәһәрдәге зыялылар байтак килә. “Квартир, гомумән, күңелле. Кеше күп килә. Эч пошарлык түгел”, - дип яза Г.Тукай үзе. Әмма килүчеләр арасыннан, М.Гафуридан тыш, икесен генә – җырчы Әхмәтфәиз Даутов белән тарихчы һәм әдәбиятчы Габделбарый Батталны гына исемләп атый.

Г.Батталны исенә алып, шагыйрь: “Г.Баттал әфәнденең үткен вә искренний интикадларын (тәнкыйть материалларын) укыганым булса да, биззат (үзен) күргәнем юк иде. Бу юлы Уфада аны күрдем. Берничә көн Уфада хәл җыйгач, Баттал әфәнде белән вокзалга киттек”, - дип яза.

Г.Баттал халык шагыйрен озатуы турындагы истәлеген шундый сүзләр белән тәмамлый: “Шагыйрь вә сәнгатькәрләргә килешкән киң читле кара эшләпәсе, кайтармалы якалы, ләкин изүе ачык түгел саргылт пальтосы, кулындагы җуан таягы, пальто кесәсенә тыгызлап тыккан “Сатирикон”, “Будильник”лары белән Уфа вокзалының платформасында казакъча: “Карлыгач карлыгачка җим бирәде, карендәш карендәшкә дем бирәде”, - дип авыз эченнән көйләп торган сөйкемле кыяфәте әле дә минем күз алдымнан китмидер.”

Бу – 1912 нче елның 15(28) мае була.

**Әдәбият:**


1. Гафури Мәҗит. Габдулла Тукай Уфада. – “Өмет” газетасы (Уфа), №43, 26.04.1997, 3 бит.
2. Сафуанов Суфиян. “Уфа мине кияү көткән кыз кеби көтеп торган...” – “Тулпар” (Уфа) журналы,2006, №2, 4-7 битләр.
3. Юлмәтова Суфия. Г.Тукай һәм татар мәгърифәтчелеге. -– “Тулпар” (Уфа) журналы,2006, №2, 8-10 битләр.

**IV НЧЕ ЮНӘЛЕШ.**

**Г. ТУКАЙ ИҖАТЫН МӘҢГЕЛӘШТЕРҮ**

*Хәйриева Г.Р. 2 нче гимназия укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Зарипова Ә.Г.,*
*I квалификацион категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Б. УРМАНЧЕ ИҖАТЫНДА Г. ТУКАЙ ТЕМАСЫ

“Яңа татар поэзиясенә һәм татар музыкасына
нигез салучылар кемнәр дигәндә-беренчесе
Тукай, икенчесе Сәйдәш, дип җавап бирсәк,
татар сурәтчелек сәнгатенә нигез салучысы-
Бакый ага Урманче дип хаклы рәвештә әйтә алабыз”.
Нәкый Исәнбәт

Безнең гимназия Бакый Урманче исемен йөртә. Фойега керүгә аның бюсты. Гүзәллек тудыручы рәссам турында күргәзмә китапханә уку залында даими эшләүчеләрдән. Ә рәттән Габдулла Тукайга багышланганы. Һәм бу очраклы түгел. Әлеге ике шәхес арасында зур бәйләнеш бар. Аларны милләткә ихлас мәхәббәт, самими хезмәт берләштерә. Ана телебез, мәдәният, гореф-гадәтләребезне саклауда Габдулла Тукайның әһәмияте сөйләп бетергесез. Милли сынлы сәнгатебезнең чишмә башы да нәкъ менә Тукай мирасыннан ташып чыгадыр. 1907 елда Казанга килгәндә Баки Урманчега бары 10 яшь була. “Мөхәммәдия”гә укырга керә.Тукай иҗатының нәкъ чәчәк аткан чоры. Тукайның шул чорларда милли сәнгатебез турында: “Килер вакыт, халкыбыз арасыннан Шүрәлене тасвирлый алырдай талантлы рәссамнар чыгар әле”,-дигән өметен күңеленә нык беркетеп куя шәкерт. Габдулла Тукай 1886 нче елда туган, Бакый Урманче 1897 нче елгы. Яшь аермасы әллә ни зур түгел. Димәк, бу иҗат ияләре очрашкан да булырга мөмкин. Ачыклау өчен, ике шәхеснең XX гасыр башы тормыш чорына кагылышлы вакыйгаларга күз салу кирәк. Чыганаклар җитәрлек. Әлеге ике күргәзмәдә узган гасырда чыккан китаплардан алып бүгенге заман язмаларына кадәр тупланган. Гали Халитның 1939 нче елда басылган ”Халык шагыйре Тукай” китабы бар, хәтта.

Гаҗәп, Тукай әсәрләрен Бөек Ватан сугышы вакытында да нәшер иткәннәр. Безнең гимназия китапханәсендә 1943 нче елда чыккан академик тулы җыентыгының 1 томы бар. Анда шагыйрьнең үзе исән чакта басылган аерым әсәрләре, газета, журналлар һәм институтта булган кулъязмалар кергән. Шулай ук ,1955 нче елдагы 2 нче томы, 1956 нче елда чыккан 3 нче һәм 4 нче томнары бар. Гимназия оешкан чорда китапханә киштәләрендә дәреслекләр генә түгел, ә бүләк экземплярлар да урын алган икән. Әлеге басмалар шулай килеп эләкәннәр, күрәсең. Шагыйрьнең юбилеена багышланган күргәзмәдә, бу раритетлар әһәмиятле урын алдылар. Иллюстрацияләр дә китерелгән. 1943 нче ел басмасындагы, мәсәлән, рәссам Г.Мусинның "Авыл мәдрәсәсе" рәсемендә шәкертләрнең йөзләре куркулы, мөгаллим кулында озын чыбык. Бары ак-кара төсләр генә кулланылу да шом өсти.

Бүгенге басмалар исә, балалар игътибарын җәлеп итәрлек бизәлеше белән аерылып тора. "Шүрәле" китабының 2006 нче ел басмасы, мәсәлән, кулдан-кулга йөри. Аны үзе исән чакта Флора Әхмәтова-Урманче төзеп нәшер иткән. Бизәлеше (рәссам И.Шәмсетдинов) дөньякүләм күргәзмәләргә җибәрерлек югарылыкта. Хәер, бу китап чит ил укучыларына да таныш инде.Татарның Шүрәлесе турындагы әкият барлыгы 15 телгә тәрҗемә ителгән. Ул гарәп, кытай, казак, инглиз, француз, фарсы, үзбәк һәм башка милләт балаларына да барып җитте.Интернет заманасында китапның үз әһәмиятен югалтмавын исбатлаучы дәлил бу.

Габдулла Тукай тууга 125 ел тулуны билгеләп үтү чорында шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты белән кызыксыну тагын да артты. Башлангыч сыйныфлар кечкенә Апушның фаҗигале тормышы, әкиятләре белән кызыксынса, ә югары сыйныф укучылары шигырьләрен, сатира, публицистика, журналистика эшчәнлеген өйрәнә.

Юбилей уңаеннан татар матбугатында шагыйрьнең биографиясенә, иҗатына бүгенге күзлектән карап язылган эшләр басыла. Аларда яңа фикерләр. Шул ук вакытта, шагыйрь мирасын саклап калудагы авырлыклар турында аяну да. Әйтик,

Казандагы “Болгар” кунакханәсе бинасы тирәсендә шау-шу күп булды. Тарихи истәлек сакланырмы – мәсьәлә һаман чишелмәгән.

Ә менә Кырлайның Тукай белән бәйле урыннарын саклауда авыл халкы актив катнаша икән. Тарихтан белгәнебезчә, Сәгъди абый белән хатыны Бибизөхрәнең ир балалары булмаганлыктан, Габдулланы уллыкка алырга уйлыйлар. “Монда ул өч кенә ел яшәп кала. Авыл картлары әйтүенчә, Сәгъди абыйның җиде яшьлек Апуш белән утырткан нарат агачы бүгенгәчә сакланган. Ә менә Сәгъди абзыйның кабер урыны озак еллар билгесез була.” Яңа Кырлайдагы “Г. Тукай музей комплексы” директоры Тәлгать Гомәров газетада шул теманы күтәреп чыккан. Ул гына да түгел, өлкәннәрдән 1904 нче елда вафат булган Сәгъди абзыйның кабер урынын раслаттыра. Аннан авыл картлары белән берлектә чардуган корып куюга ирешәләр.

Әлеге хезмәтнең максаты – Бакый Урманче иҗатында Тукай ткмасын ачыклау. Рәссамның бу сәнгать әсәрләрендә шагыйрь экиятләренең чагылышын барлау. Чөнки Тукай биографиясе һаман ачылып торса, Урманче тормыш юлының иҗат чорында ак битләр күп.

## Б. Урманче сәнгатендә Тукай темасы, экият образлары

Бөек Тукай поэзиясе Урманченың гомер буена бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы булып тора. Иҗади тормыш дәвамында Тукай темасына гел әйләнеп кайта. 1923 елда үзенең беренче эскизларын Шүрәле образына багышлый. Үзбәкстанда да Тукай Б. Урманче темасыннан аерылмый, шагыйрьнең бюсты үрнәген гипстан ясап бетерә һәм мәрмәрдән эшли башлый. Аны үзе белән Казанга алып кайта.

Рүссам иҗат иткән портретлар галереясендә Тукай замандашларыннан Сәгыйть Сүнчәләй, Мәҗит Гафури, Шәйхзәдә Бабич, Нәкый Исәнбәт, Дәрдемәнд, Галимҗан Ибраһимов, Галиәсгәр Камал портретлары бар.

“Су анасы”, “Кәҗә белән сарык” экиятләрен тасвирлаганда фолҗклорны белүе, аңлап эш итүе күренә. Биредә

халкыбызның атаклы шәхесләрен, зыялыларын, шагыйрьләрен, язучыларын, коммерсантларны очратырга мөмкин булган. Рәссам әлеге хезмәтне әдәби әсәргә иллюстраөия итеп кенә түгел, ә бәлки Тукай күзләре белән Печән базарын тасвирларга тырышкан. Андагы персонажлар нәкъ чынбарлыкка туры килә.

Б. Урманче Шүрәлеләре исә, бөтенләй дә килбәтсез түгел. Тукай ул Шүрәлене Былтыр күзләре аша сүрәтләгән бит. Ә Былтырга караңгы урманда гап-гади кеше дә куркыныч булып күренгәндер. Үзе яклауга мохтаҗ, кешеләрне җәберләтерлек көчкә ия түгел кебек.

Архитектура һәм скульптураны кушу ысулын дәвам итеп, рәссам 1976 елда Кырлайда Тукайга багышланган мемориалькомплексны тәмамлый. Б. Урманче проекты бер бөтен: ишек алдында парк салынып, ул паркта Тукай персонажларының сыннары ясалган, өй алдындагы эскәмиядә бетоннан коелган Тукай фигурасы. Юка пальтосын салып эскәмиягә куйган, әйтерсең, бөек шагыйрь кайчандыр үзен җылыткан, ач үлемнән саклап калган Кырлаена яңадан кайткан да хәзер инде рәхәтләнеп, җан җылысы һәм кояш җылысы алып утыра.

Шагыйрь 100 еллыгына аның яңа копиясен эшләтәләр. Кырлайдан бер һәйкәл безнең Түбән Камага да килеп җитте. 1986 елда алып кайтылган ядкарь бүгенгәчә шәһәребезнең хастаханәсе бакчасын бизи. Шәһәребез милләтпәрвәрләре Г. Тукай исемен йөртүче үзәк китапханә каршында шагыйрьнең бюстын куйдыртуга иреште. Бәзгә Бакый Урманче тарафыннан иҗат ителгән 400 ләп нәкыш әсәре, 160 тан артык скульптура, меңнән артык рәсеме килеп иреште. Ә менә түбәнкамалылар шагыйрь һәм рәссам исемнәрен мәңгеләштерүе белән горурлана ала. Безнең шәһәрдә Г. Тукай һәм Б. Урманче урамнары бар.

1997 елда, олпат рәссамның 100 еллыгы уңаеннан, Түбән Каманың 2 нче татар гимназиясе Бакый Урманче исемен алды.

2007 елда Татарстан китап нәшриятында “Бакый Урманче иҗатынла Габдулла Тукай” дип исемләнгән альбом чыга. Флора Әхмәтова – Урманче тарафыннан төзелеп бастырылган 2000 данәлек бу тираж гына аз, әлбәттә. Берничә көнчыгыш телне

белгән, инглиз, француз, алман телләрендә укый алган, төрле халыкларның авыз иҗатын яхшы өйрәнгән, профессиональ дәрәҗәдә җырлаучы, скрипкада уйнаучы рәссам Коръән укуга да вакыт таба. Әйтергә кирәк, гомеренең соңгы елларында шәмаилләр белән күп шөгыльләнә ул. “...Бакый абзыйга килсәк, рәссам һәм скульптор буларак, Тукайның үзен, шулай ук әдәби образларын мәңгеләштерүдә күпме гомерен биреп, күпме онытылмаслык сүрәтләрен ясап калдырды.  Аның бу эшләре күпкырлы гаять бай иҗади мирасының Тукайга гына багышланган махсус өйрәнүгә лаек олы бер тармагын тәшкил итеп тора. Ләкин дә бит әле Бакый абзабыз, Тукай үлгәч, аның баш очында тәһлил әйтеп, Коръән укып тән чыккан яшь шәкерт тә, һәм шул ку вакытта бөек шагыйрьне озатуның милли матәмгә әйләнүен үз күзләре белән кәреп калучылардан…”- дип язды Бакый ага Урманче турында иң якын кешеләрнең берсе булган, бөтен Тукайны яттан белгән Әмирхан Еники. Язучы фикеренчә, нәкъ Тукайдан башлана саф татар җанлы шигъриятебез. Тукай, Сәйдәш, Урманче иҗаты – олы елганың чишмә башы шикелле мәңге тибеп торачак. Шулай гына яшәвен дәвам иттерә һәрбер әдәбият, милли сәнгать. Моны яшьләр бик нык исләрендә тотарга тиешләр. Әлбәттә, эзләнү кирәк, яңа табышлар кирәк, иҗат шунсыз була алмый.

Б. Урманче иҗатына җентекләп күзәтү ясаганнан соң, рәссамның сәнгати эзләнүләрендә, яңалыкка омтылышында, шәхес булып формалашуында бөек Тукай тәэсире гаять зур булуы тагын бер тапкыр ачыкланды. Бакый ага Урманче – милләтебезнең күпкырлы мәдәниятен үстерүгә, халкыбызның данын-дәрәҗәсен күтәрүгә зур өлеш керткән шәхесләребезнең берсе. Безнең бүгенге әдәбиятыбыз Тукайдан, музыкабыз Сәйдәштән, сынлы сәнгатебез Урманчедан башлана, дип әйтү дөреслеккә туры килә.

**Әдәбият:**

1. Вәлиева – Сөләйманова Г. Гап-гади хакыйкать: яңарышчы останың чишмә башы//Казан. – 1197. - №10-11.- 14б.

2. Галиуллина М. Бакыйлыкка баккан идек//Мәдәни җомга. – 2007. – 2 март. – 24б.
3. Гомәров Т. Шагыйрьнең икенче әтисе//Татарстан яшьләре. – 2011. – 17 март. – 3б.
4. Еники Ә. Шәхес// Мәдәни җомга. – 1997. – 31 гыйнвар. – 4б.
5. Зыятдинов А. Ил агасы белән очрашулар//Туган як.- 1997. – 13 февраль. – 5б.
6. Мәһдиев Р. “Иҗатымны шагыйрьгә багышладым//Татарстан яшьләре. – 2011. – 22 март. – 3б.
7. Миңлебаев К. Бакый Урманче: гасыр кешесе//Татарстан. – 2000. - №8. – 34б.
8. Нуруллин И. Моңлы саз чаңнары: Документаль роман. Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 272б.
9. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2002. – 511б.
10. Тукай Г. Шүрәле: әкият – поэма. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2006. – 6б.
11. Тукай Г. Академик басма, 1 том. – Казан: Татарстан дәүләт издательствосы. – 1943. – 428б.
12. Халит Г. Халык шагыйре Тукай. – Казан: Татгосиздат, 1939. – 20б.

***Төхвәтуллина Р. Түбән Кама педагогия көллияте студенткасы,***
***Фәнни җитәкче: Галәветдинова Л.Р.***

## ӘХСӘН ФӘТХЕТДИНОВ ИҖАТЫНДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МОТИВЛАРЫ

Даһилар гомере гасырлар белән генә исәпләнә. Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның да дөньяга килүенә 125 ел тулды. Бу чор эчендә аның туган халкы һәм Ватаны тормышында, тарихында искиткеч хәлләр, үзгәрешләр

булды. Тукай шәхесе үзе аларның һәммәсенә шаһит булмаса да, әмма аның иҗаты һәм шунда гәүдәләнгән якты сурәте, каты тарихи сынауларны кичеп, онытылмый-югалмый, безнең көннәргә килеп иреште. Бу инде – тарихның чын талантларга халык белән мәңге бергә яшәргә биргән хокукы да, мәрхәмәте дә, хөкеме дә.

Габдулла Тукай иҗаты һәм шәхесе татар мәдәниятен нурландырып тора. Тукай төрки-татар рухи дөньясында аерым бер урын тота. Аңлы рәвештәме, юкмы, шагыйрь безнең тормышыбызга балачактан килеп керә һәм гомер буена озата бара. Тукайның иҗат җимешләре бик күп рәссамнарга, музыкантларга, язучыларга сәнгать әсәрләре иҗат итәргә илһам бирде. Аның шигырьләре чын мәгънәсендә халык шигырьләренә әверелделәр, шигъри юллары канатлы сүзләр һәм афоризмнарның нигезе булдылар. Алар Коръән сүрәләре белән беррәттән шәмаилләрдә үз сүзен әйттеләр, халык күңеленең чагылышы буларак көйләргә әверелделәр.

Татар мәдәниятендә шагыйрьнең шәхесе һәм аның әсәрләре белән илһамланып иҗат итмәгән бер генә әдәбият яки сәнгать әһеле дә юктыр, мөгаен. Тукайга мөрәҗәгать иткән язучы, рәссам, музыкантның һәрбер иҗат җимеше ихлас хисләр белән сугарылган, аларның һәрберсе үз карашын һәм Тукайны үзенчә аңлавын чагылдыра. Алар барысы да милли сәнгатьне баеталар, аңа аеруча күркәм бер төсмер бирәләр, аның үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итәләр. Бөек шагыйребез образын, аның үлемсез геройларын гәүдәләндерергә рәссамнар да зур өлеш кертәләр. Алар иҗаты аша без Габдулла Тукайга тагы да якыная төшәбез, аны замандашыбыз итеп тоябыз. Шагыйрьнең җисми сурәте, аны төрле халәтләрдә гәүдәләндергән картиналар, әсәрләренә иллюстрацияләр киләчәк буыннар өчен тагы да кадерле һәм кирәгрәк була барыр.

Татарстанның халык рәссамы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Түбән Кама шәһәренең почетлы гражданины, сынчы, агач уймалар остасы Әхсән Фәтхетдиновның иҗатында да Габдулла Тукай мирасы

һичшиксез лаеклы урынын тапты. Бүгенге чыгышыбызда үз алдыбызга рәссам иҗатында Тукай образы һәм геройларының чагылышын тикшерү максатын куйдык. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны билгеләдек:

1) рәссамның Тукай шәхесе һәм үлемсез иҗатына багышланган эшләренә күзәтү ясау;

2) эшләрне тематик яктан - серияләп төркемләү.

Рәссам Әхсән Фәтхетдинов иҗаты үзенчәлекле. Ул мәҗүсилек образлары дөньясына мөрәҗәгать итә. Бичура, урман иясе, абзар, мунча, йорт ияләре образларын рәсем сәнгате, агач пластикасы һәм кисеп ясау синтезында гәүдәләндерә. Рәссам мифологиянең, халык фольклорының тулы бер катламын күтәреп ала һәм хикмәтле образлар панорамасын ачып сала. Әхсән Фәтхетдинов гаҗәеп фантазия, канатлы мифлар, фәлсәфи үгетләр, табигатьнең үзеннән чыккан технологияләр белән иҗат иткән әсәрләрен сайланган темага берьюлы серияләп эшләүне өстен күрә. Әсәрләренең бер сериясен Габдулла Тукайга багышланган 10 картина тәшкил итә: “Тукай шигырьләре”, “Халык шагыйре”, “Тукай кабере”... Аларда милли шигърият даһиена рәссамның тирән мәхәббәте һәм хөрмәте чагыла. Бу әсәрләрдә шагыйребез Габдулла Тукай образы, шигърияте, аның артында торган милли тоем, этнография, гүзәллек, эчтәлек, чор һәм язмыш, гомумән, Тукай Әхсән Фәтхетдиновның иманына, иҗат концепциясенә әверелә.

“Баганалар” сериясендә рәссам, халык телендәге “алтын баганалар” төшенчәсенә ияреп, чорны, вакытны, вакыйганы билгеләгән эзләр хакында сөйли. “Баганалар” – рәссам фикерләвендә - рухи төшенчәдә. Җир өстендә якты эз калдырганнарны, биек ноктага күтәрелгәннәрне, кешелекне явызлыктан, чарасызлыктан саклаганнарны да яратып, сокланып, “баганалар” дип атаганнар. Алар - вөҗдан һәм намус баганалары. Шундый идеал үлчәме булып, Әхсән Фәтхетдинов иҗатында бер якты зәңгәрсу фонга теркәлгән, саран-нечкә орнаментлы – “каурый каләм”, “ноталар”, “өч яфраклы орнамент” - өч аксыл-коңгырт каен “багана” – Габдулла Тукай, Салих Сәйдәшев, Бакый Урманче сурәтләнгән.

Журналистларга биргән бер интервьюсында Әхсән Фәтхетдинов Тукайга мөнәсәбәтен түбәндәгечә белдергән: “Безнең буын Тукайны укып үсте. “Су анасы”н, “Шүрәле”не... Мин балачакта Тукай шигырьләре чыккан газеталарны җыя бара идем. Берзаман өйдәгеләр, шул газетага май төреп, базаргә сатарга киткәннәр. Артларыннан куып җитеп алып кайттым... Тигезләп җыеп куйдым. Безнең авылда тимерче Мәхмүт абзый без – бала-чагага Тукай шигырьләрен яттан сөйли иде”... Мөгаен, шул Мәхмүт абзый сөйләгән һәм газеталарда чыккан шигырьләр рәссамның алдагы иҗатында Шүрәлеләргә мөрәҗәгать итүенә этәргеч булгандыр да. Шүрәле образы агач сынлы сәнгатендә гәүдәләндерү өчен бай материал булып тора. Әхсән Фәтхетдиновның “Шүрәлеләр” сериясендә 50 дән артык агач скульптура. Монда нинди генә Шүрәлеләр юк – ул көләч һәм моңсу, тыныч һәм ачулы, чәчәкләр, кошлар белән, курайда уйнаучы ... Шүрәлеләр... Алар – үзе бер дөнья. Чиста, пакь дөнья. Шүрәлеләрнең берсе, бәлки, автор үзедер әле! Ул да, безнең кылган гамәлләргә карап-карап тора да, хилафлыкларыбыз өчен бетереп үк ташламый, сынап-сынап карый да, аптырагач, шаяра, кытыклый, көлә... Әлбәттә, алар барысы да Тукай Шүрәлесе түгел, ләкин бу серияне иҗат итүдә, һичшиксез, Кырлай Шүрәлесе төп сәбәпче һәм илһам чыганагы булып тора.

**Әдәбият:**


1. Җамалетдинова Ф. Ияләр, Табигать, Вөҗдан һәм Моң турында. // “Ватаным Татарстан”, 2007, 4 август.
2. Фәйзуллин Р. Нарасый хәким.// “Казан утлары”, 1999, №6, 145-149 б.
3. Шаһиева Р. “Тау”га карап тау булмасак та... // “Шәһри Казан”, 2009, 19 июнь.

*Сабирова Л. Түбән Кама педагогия көллияте студенткасы,*
*Фәнни җитәкче: Ишмөхәммәтов И.Ш.,*
*югары категорияле укытучы*

## РӘСЕМ СӘНГАТЕНДӘ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ТЕМАСЫ

Г. Тукай – татар әдәбияты күгендә янган якты йолдызларның иң зурсы. Ул калдырган иҗат мирасы һәм андагы рухи яктылык – безнең мактанычыбыз һәм горурлыгыбыз. Аның исеме һәм язмышы мәдәният тарихының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән мәңгегә бәйләнгән. Аңардан башка татар мәдәниятенең һәм сәнгатенең XX йөздәге үсешен күз алдына китерү дә мөмкин түгел.

Г. Тукай – милли мәдәният тарихында якты сәхифәләр язып калдырган әдип. Ул танылган замандашлары Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал һ.б.лар белән сынлы сәнгатьне тудыруга зур көч куйды, милли “сәнгатьчелек“не яклап көрәште.

1907 нче елда, татар халык әкияте нигезендә язылган үзенең “Шүрәле” поэмасына карата Г.Тукай искәрмә урынына болай дип язган иде: “Өмет юк түгел әле: ихтимал, үз арабыздан маһир рәссамнар чыгып, шүрәленең кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кыйлынган урманнарны – һәммәсен тәрсим кылып чыгарырлар.” Аның бу изге теләкләрен, шагыйрь уйлаганча ук, Б. Альменов, Б. Урманче кебек рәссамнар күптән инде тормышка ашырдылар.

Г. Тукай үз чорында сынлы сәнгатьнең идея-эстетик бурычларын турыдан-туры милли үзаңны үстерүгә юнәлдерелгән көрәш белән бәйләде. Шуны истә тотып, без тикшеренү эшебезне **“Рәсем сәнгатендә Габдулла Тукай темасы”** дип атадык. Әлеге темага караган хезмәтләрне барлаганнан соң, аның фәнни яктан тулысынча өйрәнелмәве ачыкланды. Бу башкарган эшнең **актуальлеген** билгели. Үз алдыбызга рәссамнар иҗатында Тукай образының чагылышын тикшерү **максатын** куйдык. Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычларны** билгеләдек:

1) рәссамнарның Тукай шәхесе һәм иҗатына багышланган эшләренә күзәтү ясау;

2) эшләрне тематик яктан төркемләү;

3) Г. Тукайның балалар өчен чыгарылган җыентыклары һәм аларны бизәүче рәссамнарның иллюстрацияләре белән танышу.

Рәсем сәнгатендә Габдулла Тукай шәхесен һәм иҗатын чагылдыруны тикшереп, без аны ике чорга бүлеп карарга булдык:

1) XX гасыр башыннан 60нчы елларга кадәрге чор – Тукай темасы графикада гәүдәләндерелә;

2) XX гасырның 60нчы елларыннан хәзерге көнгә кадәрге чор – Тукай темасы сынлы сәнгатьнең барлык төрләрендә дә киң чагылыш таба.

Шулай ук, шагыйрь шәхесе һәм иҗатына багышланган эшләрне ике зур төркемгә бүлергә мөмкин:

I. Г. Тукайга һәм аның иҗатына багышланган портретлар, картиналар һәм иллюстрацияләр. Ул рәсемнәрнең үзләрен тематик яктан дүрт төркемгә бүлергә була:

1) Г. Тукайның балачагына багышланган: “Бәләкәй Апуш һәм Сәгъди абзый” (Л. Фәттахов, 1970) “Кечкенә Габдулла Кырлайда” (Ф. Әминев, 1972), “Бәләкәй Тукай” (Х. Казаков, 1958) “Тукайның Өчиледән китүе” (В. Федоров, 1975), “Кечкенә Габдулла бабасы Зиннәтулла карт белән Өчиле урамында” (В. Кудελькин, 1970), “Тукай балачагында” (М. Мавровская, 1946);

2) Әдипнең яшьлек елларын яктырткан картиналар: “Г. Тукай. Гасыр башында” (Ш. Әбдрәшитов, 1980), “Тукай листовкалар тарата” (Ю. Лысогорский, 1976), “Тукай Нева яры буенда” (Әминев, 1975);

3) Иҗатташлары белән булган бәйләнешне чагылдырган картиналар: “Тукай һәм “Сәйяр” труппасы” (В. Федоров, 1984), “Габдулла Тукай һәм Камил Мотыйгый Уральскида”(Х. Якупов, 1976), “Авыру Тукай янында крестьяннар” (И. Хәлиуллов, 1955), “Тукай крестьяннар арасында” (Х. Якупов, 1946);

4) Г. Тукай әсәрләренә ясалган иллюстрацияләр : Б. Урманче (“Пар ат”шигыренә, “Шүрәле”, “Печән базары, яхуд

Яңа кисекбаш” поэмаларына һ.б.), Б. Альменов (“Таз” шигыренә, “Кәҗә белән Сарык” әкиятенә), Т. Хаҗиәхмәтов (“Алтынчәч” әкиятенә, “Сабыйга” шигыренә һ.б.) , Г. Зяблицев (“Кызыклы шәкерт” “Ата илә бала”, “Имтияз алган бала”, “Эшкә өндәү” әсәрләренә һ.б.), В. Карамышев (“Су анасы” әкиятенә), Е. Сидоркин (“Көзге һәм Маймыл” мәсәленә), Р. Төхфәтуллин (“Безнең гаилә” шигыренә).

II. Тукай сыннары: М. Гасыймов, А. Галиев, И. Новоселов, Б. Урманче, З. Басыйров һ.б.

Шәһәребездә дә Тукай шәхесен, аның әсәрләрен мәңгеләштерүдә үзеннән зур өлеш керткән рәссам, нәкышчы, скульптор, Татарстанның халык рәссамы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әхсән Фәтхетдинов яши. XX йөзнең 70-80нче елларында ул Тукайга багышланган күп кенә эшләр иҗат итә. Мәсәлән, “Тукай – халык шагыйре”, “Тукай шигырьләре”, “Сагыш”, “Балачак хыяллары”, “Тиздән апрель”, “Көн ачыла”, “Шигырь тууы”, “Су анасы”, “Шүрәлеләрем”, “Мин китәмен” кебек эшләр шундыйлардан. Рәссамның җаны әле дә Тукайга битараф түгел. Ул шагыйрьне татар милләтен дөньяга танытучы шәхес буларак хөрмәтли, аның бөеклегенә мәдхия җырлый. Г. Тукайның юбилеена багышлап, рәссамның картиналары шәһәр музеена күрмәзгә куелды.

Еллар үткән саен, әйләнәбез дә һаман Тукай дибез. Чөнки ул – татар халкының йөрәк ярасы, тиңсез таланты, милли горурлыгы, йөз аклыгы һәм аның гасырлар дәвамында янар йолдызы. Шулай булгач, аның шәхесенә мөрәҗәгать итми мөмкин түгел. Без моның ачык мисалын үзебезнең фәнни эшебезне башкару барышында расладык.

**Әдәбият:**

1. Габдулла Тукай. Фотоальбом / Төз. С. Исәнбаев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 116б.
2. Габдулла Тукай. Фотоальбом / Төз. Р. Даутова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 175б.

3. Габдулла Тукай. Фотоальбом / Төз. З. Бәширов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 239б.
4. Исламов Ф. Тукай образы - әдәбиятта һәм сәнгатьтә / Мәгариф, №4, 2006, Б.61-62
5. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда, 1том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 361б.
6. Исламов Ф. Татар әдәбияты һәм рәсем сәнгате // Татар әдәбиятын укытканда сәнгатьнең башка төрләреннән комплекслы файдалану методикасы (V-XI сыйныфлар). Казан: Мастер Лайн нәшрияты, 1997. – Б. 30-36, 67, 101-103.
7. Габдулла Тукай. Бала белән Күбәләк: Шигырьләр, әкиятләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996 – 79б.
8. Габдулла Тукай. Шүрәле. Әкият-поэма. – Казан, 1997. – 35б.
9. Тукай Г. Мальчик с дудочкой. / Пер. с тат. Р. Бухарева. – М.: Малыш, 1986. Худ. Р. Халилов.
10. Тукай Г. Поэмы. / Пер. с тат. Р. Бухарева. М.: Современник, 1986. – 40с. Худ. В. Бухарев.
11. Г. Тукай. Шүрәле. Әкият-поэма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Худ. Б. Альменов.
12. Г. Тукай. Су анасы. Әкият. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. Худ. Карамышев.
13. Тукай Г. Шурале. / Пер. с тат. С. Липкина. Казань: Тат. кн. изд-во, 1997. Худ. В. Булатов.
14. Габдулла Тукай. Исемдә калганнар. Хикәя. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 30б. Худ. Т. Хаҗиәхмәтов.
15. Габдулла Тукай. Энҗе бөртекләре. Мәсәлләр. – Казан: Мәгариф, 1995. – 15б. Худ. В. Малякин.
16. Габдулла Тукай. Кәҗә белән Сарык әкияте. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Худ. Т. Хаҗиәхмәтов.

*Гайсина Г. 10 нчы мәктәп укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Тимофеева Т.М.*

# Г. ТУКАЙ ОБРАЗЫ – РӘССАМНАР ИҖАТЫНДА

Габдулла Тукай татар әдәбияты күгендә янган якты йолдызларның иң зурысы. Ул калдырган иҗат мирасы һәм андагы рухи яктылык – безнең мактанычыбыз һәм горурлыгыбыз. Аның исеме һәм язмышы мәдәниятебез тарихының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән мәңгегә бәйләнгән. Аңардан башка татар мәдәниятенең һәм сәнгатенең егерменче йөздәге үсешен күз алдына китерү дә мөмкин түгел.

Тукайның гомере бик кыска булды. Ул, егерме җиде яше дә тулар-тулмастан, үпкә авыруыннан вафат булды. Әмма шагыйрь, үз заманының һәм шәхси тормышының искиткеч авыр булуына да карамастан, хезмәт, иҗат утында янып яши алды. Аның иҗатын, һичшиксез, XX йөз башындагы татар җәмгыятенең энциклопедиясе дияргә була. Тукай татар тормышына бәйле темаларны гына түгел, гомумән Россиядә һәм дөньяда булган иҗтимагый вакыйгаларны һәм мәсьәләләрне халык таләпләре күзлегеннән аңларга, бәяләргә омтылды. Ул кеше йөрәгенең иң нечкә кылларын тибрәтә алучы лирик та, изүче җәмгыятьнең төрле золымлыкларын аяусыз фаш итүче сатирик та, заманындагы сәяси һәм социаль мәсьәләләрне яктырткан ялкынлы публицист та иде.

Тукай таланты, күпкырлы иҗаты XX гасрда татар профессиональ сынлы сәнгате туууда, милли рәссамнарның иҗат үсешендә дә җитди этәргеч булды.

Татарстан Республикасының әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге Дәүләт бүләкләренең Г.Тукай исемен йөртүе бер дә очраклы түгел.

Татар әдәбиятында зур урын тоткан шагыйрь заманнар узу белән узе дә сәнгать әсәрләренә килеп керде. Тукайның күркәм образын чагылдырган берсеннән-берсе гүзәл әсәрләр барлыкка килде.

Тукайның иҗаты, ул калдырган искиткеч темалар, образлар рәссамнарны да һәрвакыт дулкынландырып, үзләренә җәлеп итеп тора. Тормышчан итеп сурәтләү өчен алар шагыйрьнең биографиясен тирәнтен өйрәнә, әсәрләрен кат-кат укый, шул нигездә шагыйрь образын иҗат итә.

Милли әдәбиятларның сүз осталары арасында портретларга, рәсемнәргә иң бай булган зат – Г. Тукай. Татар һәм башка милләт рәссамнары тарафыннан аның биш дистәдән артык портреты эшләнгән. Аларны иҗат итүчеләр арасында Б.Урманче, С.Ахун, Х.Якупов, Б.Альменов, Л.Фәттахов, И.Хәлиуллов, Х.Казаков, Ш.Шәйдуллин, Г.Житков, Э.Лотфуллин, Е.Симбирин, В.Скобеев, В.Маликов һ.б.

Тукайга булган тирән мәхәббәт илледән артык рәссамны аның балачак, яшьлек елларын, иҗатташлары белән булган бәйләнешен, иҗади мирасын һ.б. темаларны яктырткан рәсемнәрен иҗат итәргә рухландырды. Б.Урманче, Т.Хаҗиәхмәтов, Х.Казаков, Л.Фәттахов, Ф.Әминов, В.Кудელькин, Х.Якупов һ.б. шушы темаларга картиналар иҗат иттеләр.

Рәсем сәнгатендә Тукай образын гәүдәләндерүдә иң күп көч куйган өлкән буын рәссамнарының берсе – Бакый Урманче. Ул – Татарстанның һәм Россиянең халык рәссамы, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Тукай чордашы. Ул – татар сынлы сәнгатенә нигез салучы.

Булачак рәссам хәзерге Буа районы Күл Черкене авылында туган. “Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә белем алган. 1929 елда, милләтчелектә нигезсез гаепләнеп, кулга алына, Соловки лагерена сөрелә. Кайткач, Мәскәүдә, Алма-Атада, Урта Азиядә яши. 1958 елда Казанга кайта һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яши. Үзен олы рәссам, сынчы итеп таныта: китаплар бизи, татар костюмнары эскизлары, шәмаилләр, бик күп күренекле кешеләрнең портретларын ясый.

Бөек Тукай поэзиясе Урманченың гомер буена бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы булып килә. Ул “Шүрәле” поэмасына гына да 100 бит рәсем багышлаган. Архитектура һәм

скульптураны кушу ысулын дәвам итеп, рәссам 1976 елда Тукай мемориаль комплексын тәмамлады. Б.Урманче проекты белән салынган Тукай музей-йорты халык иҗатының төзелеш-корылыш традицияләренә таянып эшләнгән. Останың идеясе бер бөтен тәшкил итә: ишек алдында парк салынып, ул паркта Г.Тукай персонажларының сыннары ясала, бу комплекста бетоннан коелган, өй алдында эскәмиягә утырып торучы Тукай фигурасы аеруча рухланган,эчке нур балкытып торган төсле. Юка пальтосын салып эскәмиягә куйган, әйтерсең бөек шагыйрь кайчандыр үзен җылыткан, ач үлемнән саклап калган Кырлаена яңадан кайткан да хәзер инде рәхәтләнеп , җан җылысы һәм кояш җылысы алып утыра. Бу һәйкәлдә татар халкының сөекле улына карата иң җылы хисләре чагыла.

Х.Якупов Тукай образына еш мөрәҗәгать иткән рәссамнарның берсе. Аның “Тукай апасы Газизә белән Кырлайда”, “Габдулла Тукай һәм Камил Мотыйгый Җаекта”, “Габдулла Тукай”, “Габдулла Тукай крестьяннар арасында” һ.б. рәсемнәре билгеле.

Г.Тукай Петербургта да булган. Шуңа бәйле рәвештә М.Рәхимовның “Тукай Петербургта” исемле картинасы барлыкка килә.

Х.Казаков шулай ук Тукайның портретын һәм аның иҗатына багышланган рәсемнәр ясаган рәссамнарның берсе булып тора. Аның “Тукай Печән базарында”, “Бәләкәй Тукай” һ.б. картиналарын атарга мөмкин. “Бәләкәй Тукай” картинасында Габдулла Кырлайда Сәгъди абзый йортында сурәтләнгән. Чиста, матур өй эче. Тәрәзә төбендә яран гөле үсеп утыра. Тәрәзәдән сирпелеп кергән кояш нуры, әйтерсең лә, назга сусаган ятим баланың башыннан сыйпый. Сәкедә бәләкәй Апуш ашап утыра. Аның алдында әле яңа гына пешеп чыккан, парлары чыгып торган бәрәңге һәм тирән савытка салынган катык. Бу минутта Габдулланы алырга килгән Сәгъди абзыйның аңа: “Менә хәзер... алла боерса, бездә катык, сөт, ипи күп, теләгәнчә ашарсың,” – дигән сүзләре искә төшә дә йөрәккә рәхәт булып китә. Чөнки нәни Апуш бу өйдә, ниһаять, күптән онытылган гаилә җылысын татый. Әмма Габдулланың моңсу,

сагышлы күзләре үзәкне өзә. Бу рәсемне карагач, күңелдә кызгану хисе белән бергә, аның шушы кыска вакытка булса да рәхәт көннәре өчен куаныч хисләре туа.

Татар рәссамнары гына түгел, башка милләт рәссамнары да Тукай темасына еш мөрәҗәгать итәләр. Шуларның берсе – Е.Симбирин. Аның “Шагыйрь Габдулла Тукай” рәсеме шуның ачык дәлиле.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Виктор Федоров республикада танылган оста. Ул монументаль сәнгатьтә дә, сынлы сәнгатьтә дә, графикада да бер үк дәрәҗәдә көчле. В.Федоров иҗат иткән картиналардан без күңелләрдә тирән эз калдырган бөек шәхесләр белән танышабыз. Г.Тукайга багышланган рәсеме “Өчиле авылыннан Кырлайга китү” дип атала. Бу рәсемдә кечкенә Габдулланы алырга килгән Сәгъди абзый кулларын аның иңнәренә салган. Әбисе, бабасы, аларның балалары озата чыкканнар. Бу картинада рәссам аерылу сагышын, алдагы тормышка өмет чаткыларын күрсәтә алган.

Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Лотфулла Фәттахов - тематик картина жанрында аеруча зур уңышларга ирешкән рәссам. Аның әсәрләрендә халык тормышы киң яктыртыла. “Бәләкәй Апуш һәм Сәгъди абзый”, “Тукай” картиналары бөек шагыйрьнең образын ачуга, Кырлай авылының гүзәл табигатен күрсәтүгә зур өлеш кертә.

Г.Тукай исемендәге Дәүләт буләге лауреаты Тавил Хаҗиәхмәтов – йөздән артык китапны бизәгән, аларның бик күбесенә, бигрәк тә балалар өчен чыгарылганнарына төсле рәсемнәр ясаган рәссам.Бигрәк тә аның Г.Тукай шигырьләренә, әкиятләренә ясаган рәсемнәре үзенчәлекле. Аның “Су анасы”, “Кызыклы шәкерт” һ.б. иллюстрацияләреннән балалар дөньясын яхшы белүе, аларны кызыксындыра белүе күренеп тора.

Байназар Альменовның төп иҗат юнәлеше – китапларга рәсемнәр төшерү, бизәү. Г.Тукайның “Шүрәле”, “Су анасы” әкиятләренә төрле вариантларда эшләнгән рәсемнәре, шулай ук “Исемдә калганнар” әсәренә ясалган иллюстрацияләре аеруча билгеле. Б.Әлменов татар халкының күренекле кешеләре

портретларын ясауда да актив эшләде. Аның тарафыннан Г.Тукай портреты ясалган.

Тукайга һәйкәлләр дә күп куелды. Аның мәһабәт һәйкәлләре Казанда икәү. Берсен скульптор С.Ахунов Мәскәү сынчылары Л.Кербель, Л.Писаревский белән берлектә иҗат итә, икечесенең авторы – Е.Шулик. Туган авылы Кушлавычта скульптор И.Новоселов , Кырлай авылында Б.Урманче тарафыннан эшләнгән һәйкәлләр куелган. Шулай ук Әлмәт, Уральск шәһәрләрендә сынчы М.Гасыймов эшләгән һәйкәлләр, А.Абдрашитов тарафыннан эшләнгән һәйкәлләрне дә әйтеп үтәргә мөмкин. Г.Зябликов эшләгән “Былтыр һәм Шүрәле” сыны да халык күңеленә хуш килде.

Еллар үткән саен Тукай иҗатының мәгънәсе тирәнрәк ачыла бара.

“Килер заман: һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле”, - дип язган илим, рәссам, композитор үзеннән өлеш кертә.

Габдулла Тукай – XX гасырда татар яңарышы тудырган бөек шәхес. Ул безнең халыкның иң мәшһүр, иң газиз, иң популяр милли шагыйре. Бер социаль катлауның, сыйныфның гына түгел, барлык татарларның да уртак казанышы. Чын мәгънәсендә бөтен халык шагыйре.

Татар яшәгәндә, аның теле һәм милли җаны исән булганда, милли шигърияте, милли моңнары яңгыраганда Г.Тукай яшәячәк. Ул туган халкы белән киләчәккә бара. Тукай шәхесе, Тукай иҗаты үзе яңадан-яңа талантлы әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең нигезенә алына, Тукай чишмәсе бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы буларак шаулап агуын дәвам итә.

**Әдәбият:**

1. Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияте (ТаРИХ), 2002. – 511б.
2. Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – 271 бит

3. Җиһаншина З. Тукай образы – рәссамнар иҗатында / Мәгариф. – 2008. - Апрель. – 57-59 бит
4. Галиуллин Т. Без – Тукайлы шигърият / Мәгариф. – 2006. – Апрель. – 7-11 бит
5. Исламов Ф. Тукай образы – әдәбиятта һәм сәнгатьтә / Мәгариф. – 2006. – Апрель. – 61-62 бит
6. Исхакова М. Син яшәрсең, мең яшәрсең, син – шагыйрьләр солтаны / Мәгариф. – 2006. – Апрель. – 7-11 бит
7. Миннибаев К.С., Ахметова Ф.В. Баки Урманче. Альбом. – Казань: Тат.книжное издательство, 1982
8. Рәшитова Н. "Син бер гөлме? Милләт бакчасының гөлләренә баскан былбылмы?" / Мәгариф. – 2006. – Март. – 19-21 бит

***Яруллин И. Түбән Кама кадетлар мәктәп-интернаты укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Ишмөхәммәтов И.Ш., югары категорияле укытучы***

## Г. ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР МУЗЫКА СӘНГАТЕ

Чиктәш сәнгать төрләре арасында әдәбиятка иң якыны – музыка. Әдәбият – музыканың сюжетын коруда катнашучы төп чараларның берсе. Әдәбият һәм музыка бер-берсе белән иҗади якынлыкта, үзара үрелеп яңадан-яңа сәнгать жанрлары тудыралар. Боларга, гадәттә, романс, опера,оперетта, баллада, симфония, соната, балет һ.б.ны кертергә була.

Шуны истә тотып, без тикшеренү эшебезне **"Г. Тукай һәм татар музыка сәнгате"** дип атадык. Әлеге темага караган хезмәтләрне барлап чыкканнан соң, аның фәнни яктан тулы өйрәнелмәве ачыкланды. Бу башкарган эшнең **актуальлеген** күрсәтә.

**Тикшеренүнең максаты** булып татар музыка сәгатендә Г. Тукайның ролен билгеләү тора. Әлеге максатка ирешү өчен үз алдыбызга түбәндәге **бурычлар**ны куйдык:

- композиторларның Тукай шәхесе һәм иҗатына багышланган әсәрләренә күзәтү ясау;
- татар музыка сәнгате үсешендә Тукайның урының билгеләү;
- шагыйрь сүзләренә язылган җырлар һәм аның әсәрләренә нигезләнеп иҗат ителгән музыкаль әсәрләр белән танышу.

Тикшеренү барышында без Тукайның халык җырларын җыю һәм өйрәнүен ачыкладык. Моңа дәлил булып аның 1946 елда дөнья күргән “Халык әдәбияты” җыентыгының “Җырлар дәфтәре” дигән өченче бүлеге тора.

Музыка белән поэзиянең дуслыгы бик борынгы заманнардан ук килә. Сүз белән көйдән торган халык җырлары моңа ачык мисал булып тора. Кеше җырны көе һәм сүзләре белән бергә ота.

Габдулланың 48 биттән торган кульъязма дәфтәрендә көйгә җырлана торган 28 төрле җыр теркәлгән. Бу җырлар татар фольклорын һәм этнографиясен өйрәнүдә гаять зур әһәмияткә ия. Алар арасында хәзерге вакытта бөтенләй очрамаган яисә бик сирәк очрый торган җырлар да бар. Дәфтәрдә сюжетлы җырларның да булуы аның кыйммәтен тагын да арттыра.

Г. Тукайның бу дәфтәрендә “Кәримәкәй”, “Ак бүрек”, “Сәлим бабай”, “Фатыйма”, “Аргамак”, “Сәгать чылбыры”, “Бөгелмә” кебек татар җырлары һәм берничә башкорт җыры – “Эстәрле”, “Сәрмәсән буе” һәм “Агыйдел” урын алган була.

Халык җырларын шагыйрь үзенең иҗаты өчен иң югары дәрәҗәдәге үрнәк итеп карый. Әдәби телнең тууында, беренче чиратта, халык җырларына, иҗатына һәм теленә нигезләнү кирәклеген әйтә.

Халык җырларын җыйган, аларның чыгышларын өйрәнгән Г. Тукай җыр-моңның кешеләргә зур йогынты ясавы һәм аның зур тәрбияви көчкә ия булуы турында үзе: “җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле”, “халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгесе”, - ди. Шуның аша

халык җырларының иҗтимагый тормыштагы ролен, урынын билгели.

Кечкенәдән халык моңнарына, халык җырларына булган тирән мәхәббәт Г. Тукайның шагыйрь булып формалашуына булышлык иткән. Ул музыканың әһәмиятен тагын да күтәрә торган: “Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем... Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телемезне сөю тугъды”, - дигән тирән фикерне әйтә.

Г. Тукай үз вакытында: “Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр”, дигән фикерләрне әйткән иде. Бу сәнгатьнең халык иҗатына нигезләнгән вакытта гына чын реалистик югарылыкка күтәреләчәген төшендерүче кыйммәтле идея буларак әһәмияткә ия. Шагыйрь үзе яшәгән чорда “Шәрык” клубы каршында алдынгы яшьләр тарафыннан оештырылган скрипка, рояль, гармун һәм мандолиналардан торган кыллы оркестр чыгышларында татар халык көйләрен яңа тавышларда яңгыравын ишетеп шатлана, аларны башкаручыларны тәбрик итә.

Г. Тукай халык көйләре, халык җырларына зур бәя бирү белән бергә үзенең халыкка якын поэзиясе белән аның музыка иҗаты өчен классик җырлар тудыруга зур хезмәт күрсәтте.

Әдипнең күп кенә шигырьләренә халык үзе һәм композиторларыбыз көйләр язды. Бу тикшерүебезнең аерым юнәлеше буларак каралды.

Халык Г. Тукайның шигырьләрен үзе иҗат иткән көйләргә беркетеп җырлады һәм һаман җырлый, аның аерым әсәрләренә көйләр чыгара. Мәсәлән, “Пар ат”, “Анам кабере янында” (“Өзелгән өмет”), “Ишек бавы”, “И туган тел”, “Бала белән күбәләк”, “Бәйрәм бүген” шигырьләренең үз көйләре бар.

Шагыйрь үзе исән чакта ук, аның күп кенә шигырьләрен халык үзенеке иткән, мәгълүм көйләргә салып җырлаган. Мондыйларга аның “Зиләйлүк”, “Әллүки”, “Тәфтиләү”, “Пар ат” һәм “Туган тел” җырлары керә.

Г. Тукайның талантлы, эчтәлеккә бай иҗаты татар музыка сәнгате үсешенә зур булышлык итте. Композиторларыбыз аның шигырь, поэма, әкиятләренә музыка яздылар. Аларның саны бүгенге көндә 60 тан артык.

Г. Тукай поэзиясе милли музыканың аеруча вокаль сәнгатен үстерүдә зур роль уйный. Шагыйрьнең үз сүзләренә дә Мансур Мозаффаров (“Тукай поэмасы”), Александр Ключарев (“Шүрәле”), Заһит Хәбибуллин кебек композиторлар байтак кына көйләр, романслар иҗат итәләр.

Г. Тукай иҗатына бәйләнештә туган җыр-романслар белән беррәттән, татар музыка сәнгатендә шагыйрьгә багышланып яки аның әкиятенең эчтәлеге буенча язылган инструменталь музыка һәм зур форма поэма-балетларның тууы да куанычлы факт. Бу эшебезнең өченче юнәлеше буларак карала.

Г. Тукай – татар композиторларына тема һәм илһам бирүче мул сулы чишмә ул. Алмаз Монасыйпов “Тукай аһәңнәре” дигән зур күләмле әсәр – симфоник поэма иҗат итте. Әсәрнең “Туган җиремә” дип аталган беренче өлеше Г. Тукай иҗатында төп урынны тоткан туган җир, Ватан темасын чагылдыра һәм поэманың бөтен рухына юнәлеш бирә.

Татар композиторлары симфония иҗат итүдә Г. Тукай поэзиясеннән кыю файдаланганнар. Н.Җиһанов, мәсәлән, үзенең “Кырлай” дигән симфоник поэмасында “Шүрәле” әкияте мотивларын нигез итеп ала һәм туган табигатьнең матур күренешләрен, халык фантазиясендәге сихри образларны гәүдәләндерә.

Халык җырлары традицияләре нигезендә Н.Җиһанов “Симфоник җырлар” дигән әсәр дә иҗат итә. Бу әсәр дә Г. Тукай поэмасы белән турыдан-туры бәйләнгән. Аның төп өлешен шагыйрьнең “Туган тел” әсәре алып тора.

Нәтиҗә итеп шуны әйтергә була: Г. Тукай музыкант та булмаган, көйләр дә язмаган. Шулай да аның һәр шигыреннән музыкаль аһәң, моң бөркелә. Бөек шәхес турында күбрәк укыган, күбрәк белгән саен, ул, ничектер, күңелгә һаман да якыная, аның иҗаты яңа яктан ачыла бара.

Без үз эшебездә Г. Тукай шәхесен һәм иҗатын татар музыка сәнгате белән бәйләнештә ачтык һәм бу өлкәнең бик бай күпкырлы булуына инандык.

**Әдәбият:**

1.Газиев И. "Ишеттем мин кичә берәү җырлый..." //Татарстан, 2006, №4.- Б. 48-51.
2.Исламов Ф.Ф. Татар әдәбияты һәм музыка//Татар әдәбиятын укытканда сәнгатьнең башка төрләреннән комплекслы файдалану методикасы. – Казан: Мастер Лайн, 1997.-Б.19-30.
3.Исламов Ф.Ф. Тукай образы – әдәбиятта һәм сәнгатьтә//Мәгариф, №4, 2006.-Б.61-62.
4.Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда, 4 том.-Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.-Б. 173-174.

***Идиятуллина М. 8 нче мәктәп укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Хәйруллина Ф.Х.***

## ТУКАЙ ҺӘМ МУЗЫКА

"Тукай һәм музыка" махсус монографик тикшеренү өчен бай һәм күпкырлы тема булып тора. Шулай итеп, бу хезмәтнең максаты – Тукайның музыкага мөнәсәбәтен монографик күзәтү. Бу максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге бурычлар хәл ителде:

- Тукайның милли музыкага мөнәсәбәтен өйрәнү;
- Тукай әсәрләренең халык музыкасында чагылышын күзәтү;
- профессиональ татар музыкасында Тукай тоткан урын-ны билгеләү;
- бәетләрдә Тукай образын барлау.

Тукай яшәгән һәм иҗат иткән чор бездән еракլаша барган саен, шагыйрь мирасының бөеклеген һәм күпкырлылыгын тагын да ныграк тоябыз. Ул татар халкы милли сәнгатенең барлык өлкәсенә йогынты ясады һәм ясый.

“Чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җыруларыннан гына табып була...” Г. Тукай.

Халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукайның тормыш юлына күз салсак, аның бик кечкенәдән үк җырга, моңга тартылуын һәм алардан кәңеленә юаныч алуын күрәбез. Әйе, Тукайны музыкасыз, көй-җырсыз күз алдына китерүе бик кыен. Аның бу турыда әйткән сүзләре бар: “Халык җырлары бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале мирастыр... Халык җырлары халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер”. Ул истәлекләрендә алты яшеннән үк Яңа Кырлай авылында халык җырларын башкаруын әйтә, дини китаплар “Бәдәвам”, “Кисекбаш”, “Мөхәммәдия”ләрне яратып укуы турында язып калдыра. Ә тугыз-ун яшьләрендә апасы Газизә Забировага: “Апа, минем белмәгән җырым юк,” – ди.

Г. Тукай кечкенәдән үк үзе ишеткән тыңлаган халык җырларын, бәетләрен язу дәфтәренә теркәп барган. Вафатына күп еллар узгач, Г. Тукайның кулъязмаларын табалар.

“Тетрадь для списывания ученика 1 класса А.М. Тукаева” дип исемләнгән кулъязма-дәфтәрендә 28 халык җыры теркәлгән. Алар арасында халкыбызның бик сирәк очрый торган җырлары булуы зур әһәмияткә ия. Чагыштырмача күптән түгел генә табылган бу халык җырлары, бәетләре һәм Тукайның үзенә багышланган бәетләре турында Татар Дәүләт фольклор Үзәге директоры Котдус Хөснуллин “Мәдәни җомга” газетасының 1997 елгы 9 нчы май санында язып чыкты. Бу мәкаләдән Тукайның халык җырларын җыеп, өйрәнеп кенә калмыйча, оста башкаручы да булганын беләбез.

1910 елның 15 апрелендә Казанның Шәрыкъ клубында укыган “Халык әдәбияты” дигән лекциясендә Тукай үзенең балалык еллары турында болай сөйли: “Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атна кичләрдә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде. Мин, самавыр артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул

жырлавым бәрабәренә хәлфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия кыйлына иде. Мин, кулымдагы симәнкәне беткәнче яргач, тагын жырлый идем. Мәдрәсәдә үк мине жырчы диләр иде.”

Г. Тукай халык жырларын күңеле тулган, кайгылы мизгелләрдә жырлаган, ә андый мизгелләр ятим баланың тормышында күп булган шул:

“Җилбер-җилбер йөргән чакта,
Җил ачадыр куенымны;
Күңелсез чакта жырласаң,
Җыр ачадыр күңелне”.

Язучы Мәгъсүм Латыйфуллин “Сәйдәшнең балачагы” исемле повестенда Г. Тукайның бер төркем иҗат әһелләре (Г. Коләхмәтов, Ф. Әмирхан, С. Рахманкулов, З. Яруллин, Г. Кариев) каршында, аларның соравы буенча “Тәфтиләү”не башкаруы турында яза: “Салих “Зиләйлүк”не уйнап чыккач, Тукай тирән сулап куйды һәм: “Әйдә, “Тәфтиләү”не, - диде. Салих салмак хәрәкәт белән сузынкы, сыгылмалы “Тәфтиләү” көен яңгыратканда, Тукай да жырлый башлады. Аның тавышы җәйге иртәдә искән жылы җил шикелле йомшак, ягымлы бәрхет тенор иде. Ул үзенчә жырлый, ахырда көйне тагын да киңәйтә, озынайтып суза һәм сандугач терелдәвенә охшатып, җиңелчә калтыратып бетерә”.

Җырларның барлыкка килү һәм яшәү тарихын башка берәү түгел, нәкъ менә Тукай яза башлаган. "Халык әдәбияты" хезмәтендә ул жырларның килеп чыгышы тарихын, образлары ничек башкарылуы турында мәгълүматлар бирә. Г.Тукайның халык иҗатын жыю һәм өйрәнү буенча гыйльми хезмәтләре 1910, 1912 елларда язылa.

Ул "Халык моңнары" һәм "Халык әдәбияты" исемнәре белән ике әсәрен аерым китап итеп бастырып чыгара. Аның жырларны жыю, өйрәнү кирәклеге, чын халыкчан. Г.Тукай башка халыкларның музыкасы белән дә кызыксына.

Г.Тукай Уральскида да, Казанда да яшәгәндә әдәби-музыкаль кичәләр оештыру белән бик актив шөгыльләнә. Бу кичәләрдә ул "безнең этиләребез йөрәгеннән" чыккан мирасыбызны, ягъни татар халык жырларын пропагандалый.

Г.Тукай еш кына төрле авторларның шигъри әсәрләрен, кайчагында "Коръән"нән сүрәләр дә көйләгән. Ул музыка белән тәэсирләнеп яши, ул аның йогынтысы белән теге яки бу әсәрен иҗат итә. Шагыйрь үз иҗатында татар халкының уй-теләкләрен, өмет-хыялларын чагылдырган демократ шагыйрь. Тукайның шигъри иҗаты - әдәби эшләнеше белән югары, үзенең теле белән татар халкына ачык аңлаешлы. Шагыйрьнең төрле яклы мирасы татар халкы куңеленә киң һәм тирән үтеп керде. Тукай чын-чынлап халык шагыйренә әверелде. Моны татар тәнкыйтьчеләре шагыйрь үзе исән вакытта ук аңлыйлар. Әмма бу хакта Тукайның үлеменнән соң аеруча кискен әйтелә. Әле революциягә кадәр үк Тукай шигырьләренең, халык җырлары булып, фольклор көйләренә җырлануы билгеле.

Бу җырлар, композиторлар М.Мозаффаров, А.Ключарев, З.Хәбибуллин тарафыннан хор өчен эшкәртелеп, туып килүче милли хор стиленең үзенчәлекле эталонына әверелде һәм Татарстан Республикасы җыр һәм бию ансамбленең алтын фондына керде.

Г.Тукай сюжетларына һәм шигырьләренә җыр һәм романслар язылды, балетлар, симфоник поэмалар иҗат ителде.

Тукайның иҗаты – хәзерге һәм киләчәк буын музыкантлары, башкаручылары, композиторлары өчен тирән фикерләрнең, нечкә юмор, үткен сатира һәм югары гражданлык хисләренең саекмас чишмәсе ул. Шагыйрьнең тормышы үзе үк музыкаль гәүдәләнеш булып тора. Һичшиксез, әле күп әдипләр бөек Тукай мирасының яңадан-яңа кырларын ачарлар.

Композиторларга, аеруча шагыйрь мирасына мөрәҗәгать иткәндә, аның музыкаль-эстетик карашларын белү бик мөһим. Композиторлар арасында Тукай шигърияте белән кызыксыну һаман үсә бара бит.

**Әдәбият:**

1. Әмирхан Ф. Әсәрләр. Дүрт томда. – Казан, 1986, 4 том, 115б.
2. Исхакова-Вамба Р.А. Тукай и татарская музыка. – Казань, 1997.

3. Исхакова-Вамба Р.А. Татарские народные песни. – №79.
4. Лаисов Н. Лирика Тукая. – Казань: 1976. – 106с.
5. Лаисов Н. Г. Тукай. – Казань: Тат. кн. издат., 1985.
6. Нигъмәтҗәнов М. Татар халык җырлары. – Казан, 1976.
7. Рәсүлева З.Ә. Тукай эзләреннән. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1985.
8. Рәхим Г. Тукаев – халык шагыйре. – Китапта: Тукай турында замандашлары. – Казан, 1960. – 232б.
9. Тукай турында истәлекләр. - Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. – 33, 64, 66, 67б.
10. Тукай Г. Әсәрләр. Дүрт томда. - Казан: Тат. кит. нәшр., 4 том.

***Ямалетдинова А. Түбән Кама химия-технология институты студенткасы,***
***Фәнни җитәкче: Мирдиянова Б.М., татар теле укытучысы***

## ӘДӘБИЯТТӘҺӘМ СӘНГАТЬТӘ ТУКАЙ ОБРАЗЫ

Исемнәре һәм иҗатлары үз халкының тарихыннан аерылгысыз кешеләр бар. Алар иҗат иткән җәүһәрләр балачактан ук кешенең күңеленә керә һәм бөтен гомере буена аның юлдашы була. Аларның мирасы бер милләт байлыгы булып кына калмый, бик күп халыкларнын, уртак хәзинәсенә әверелә. Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай—әнә шундый классикларның берсе. Ул халкыбызның иҗат даһилыгын мәңгеләштереп калдырды, үз заманының иң зур һәм җитди мәсьәләләренә җавап бирде. Шагыйрь — кешеләр күңелендәге изге хисләрне уята торган нечкә күңелле лирик та, үзе яшәгән заманның иҗтимагый строен, андагы гаделсезлекләрне фаш итүче ачы телле сатирик та, мөһим политик һәм социаль күренешләргә карата әһәмиятле фикерләр әйтүче ялкынлы публицист та була. Ул әдәбиятка азатлык өчен көрәш җырчысы һәм халыкның бәхетле киләчәккә өметен

чагылдыручы буларак керә, гомеренең соңгы минутына кадәр үз идеалларына турылыклы булып кала.

Татар әдәбияты тарихында гаять зур урын тоткан бөек Тукай, заманнар узу белән, үзе дә әдәбият һәм сәнгать әсәрләренә килеп керде. Аның күркәм образы халык авыз иҗатында да чагылыш тапты. Тукай күп еллардан бирле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләрен яңа әсәрләр иҗат итүгә рухландыручы илһам чыганагы булып килә. Әдипләребез һәм шагыйрьләребез, художникларыбыз, композиторларыбызның бөек Тукайның күркәм образын чагылдырган берсеннэн-берсе гузэлрэк эсэрлэре денья курде. Тукай образы язучыларны драма эсэрлэре иҗат итүгә дз рухландырган. Бу юнәлештә эшләүчеләрдән беренче буларак, Ә. Фэйзи 1938 нче елда Тукайны драма жанрында чагылдырды. Бу эштә драматург зур уңыш казана. Шул ук елда әлеге әсәр сәхнәдә дә уйнала. Аның театрларда куелуы халык өчен зур бәйрәм төсен ала. Сәхнәдә Тукай ролен башкаручыларның берсе — СССРның халык артисты Габдулла Шамуков булды. Ул, яшьтән үк Тукай образы белән хыялланып йөргәнгә күрә, чын образ тудыруга иреште. Шулай ук РСФСРның халык артисты Камал III һәм ТССРның атказанган артисты И. Гафуров та Тукай ролен гаять оста башкарды. Яшь буын вәкилләреннән ТССРның атказанган артисты, М. Җәлил исемендәге премия лауреаты Наил Дунаев һәм артист Илдус Әхмәтҗанов бу традицияне уңышлы дәвам иттерделәр. Драматургия өлкәсенә караган әсәрләрнең исемлеген тагында дәвам итеп булыр иде әле Р. Ишморатның "И мокатдәс моңлы сазым", Т.Миңнуллинның "Без китәбез, сез каласыз", И.Юзеевнең "Очты дөнья читлегеннән", Ә.Гаффарның "Соңгы сәгать", И.Нуруллин "Тукай Петербургта" драмалары һәм трагедияләрендә шагыйрь образын яңача сүрәтләргә омтылыш көчле. Болар арасында Р.Батулланың "Сират күперендә", Тукайның соңгы айлары һәм көннәре сүрәтләнә. Ул инде бу вакытка шәхес буларак та, шагыйрь буларак та формалашып җиткән, киң танылган. Талантлы һәм горур, туры сүзле, хәтта бәгырьсез дәрәҗәдә туры сүзле, үзенең җирдәге урынын яхшы аңлаган, дусларын яраткан, хатын-кызга

кырысрак һәм беркадәр кыюсыз мөнәсәбәтле, киң карашлы, тирән белемле - әсәрдә Тукай шундый шәхес булып күз алдына баса. Сөекле шагыйребез әсәрләренә композиторларыбыз да еш мөрәҗәгать итә. Музыкада бу теманы үзенең «Тукай маршы» белән композитор Заһидулла Яруллин башлап ж,ибәрде.

Татарстанның халык артисты, композитор Н. Җиһанов «Кырлай», ә ТССРның халык артисты һәм атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор М. Мозаффаров «Тукай» дигән симфоник әсәрләр иҗат иттеләр. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Алмаз Монасыйпов «Тукай моңнары» циклын иҗат итте. Шагыйрьнең үз иҗатын музыкага салуда да композиторларыбыз зур уңыш казанды, Тукайның дистәләгән шигырьләренә көй язылды.

Тукай халык өчен яшәде, аның бәхете, азатлыгы өчен көрәште, аның максаты туган илне хөр, азат, бәйсез итеп күрү иде. Ләкин шагыйрь андый көннәрнең килүен күрә алмады. Азатлык, бәхет килде.

Халык үзенең җырчысына мәңге онытылмаслык истәлек итеп һәйкәлләр куйды. Сөекле шагыйрьгә Казанда гына түгел, аның туган авылы Кушлавычта, Тукай - Кырлайда, Әлмәттә дә һәйкәлләр куелган. Аларны Новоселов, Бакый Урманче, Садрый Ахун, Лев Кербель, Лев Писаревский кебек мәшһүр скульптор-лар эшләгән. Садрый Ахун тарафыннан иҗат ителеп, 1958 нче елда Казанда Тукай мәйданына куелган һәйкәлен күз алдына китерегез әле. Шагыйрнең киеренке йөз чалымнары безгә күп нәрсә турында сөйли. Кара материалдан эшләнгән постамент композициягә катгыйлык һәм шул ук вакытта бөеклек биреп тора. Һәйкәлнең классик стильдәге торышына тирәлек, аерым алганда, Тукай иҗатында бик еш телгә алынган Кабан күле дә җанлылык өсти. Бу һәйкәл янында ел саен сөекле шагыйребез Г.Тукайның туган көне билгеләп үтелә. Мәдәниятне үстерүгә зур өлеш керткән язучыларыбызга, сәнгать әһелләренә иң зур бүләк Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге премиясе бирелә.

Һәр чор бөек язучыларны яңадан ача, аларның иҗатында яңадан-яңа бизәкләр таба. Бүгенге гүзәл эшләребез, казанышларыбыз яктылыгында караганда, Тукай безнең күз алдыбызга тагын да бөегрәк, тагын да мәһабәтрәк булып килеп баса.

Шул кыска гына гомерендә дә ул кайберәүләр 100 елда үтәп чыга алмаслык эш башкарырга өлгерә. Күрәсез, кеше аз гына вакыт эчендә дә гаять зур эш эшләргә, шул хезмәтләре белән халык куңеленә кереп калырга мөмкин. Тукай — әнә шундыйларның берсе. Шагыйрь бер дә шикләнмичә: «Халкым өчен яшәдем, аның белән бергә кайгырдым, яндым, аның бәхете өчен көрәштем»,— дияргә хаклы иде. Шуның өчен бөек Тукай безгә якын, сөекле, кадерле һәм һәрчак безнең күңел түребездә яши. Аның мөкатдәс образы сәнгатьнең төрле өлкәләрендә гәүдәләнеш тапты һәм халык мәхәббәтен яулады.

***Ульданова Э. 20 нче мәктәп укучысы,***
***Фәнни җитәкче: Константинова Д.М.***

## КЫРЛАЙДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МУЗЕЕ

Без инде күптәннән Тукайның Кырлайдагы музеен барып карау теләге белән яна идек. Әгәр бик теләсәң, хыял тормышка аша икән бит ул! 14 нче май көнне без - 20 нче мәктәпнең Тукайны хөрмәт итүче татар һәм рус балалары, укытучылар һәм эти - әниләр (барлыгы 42 кеше) - иртә таңнан Кырлайга юл тоттык. Юлда сыйныф җитәкчебез Фәния Гатуф кызы Габдулла Тукайның иҗаты буенча викторина уздырды, шагыйребезнең тормыш юлыннан кызыклы мәгълүматлар сөйләде, аның шигырьләренә язылган җырлар юлда бигрәк матур яңгырады.

Кырлай мемориаль комплексы безне үзенең матурлыгы белән җәлеп итте. Ия инешенә шәүләләре төшеп чиксез озын булып күренгән каеннары, сырлы - сырлы күперләре, инешкә кереп торган әкияттәгедәй беседкалары, Бакый Урманче проекты буенча челтәрләп ясалган ике катлы музей йорты, аның

эчендәге әйләнмәле баскычлары безне әллә нинди сихри, серле дөньяга алып кереп китteләр.

Габдулла Тукайны бәләкәй вакытында үзенә сыендырган Яңа Кырлай авылы (Татарстанның Арча муниципаль районында) үзе үк мемориаль һәйкәл булып тора. Кырлай авылында Сәгди абзыйлар гаиләсендә Тукай 5 елга якын яши. Тукайның гади крестьян тормышының көндәлеге, ихтыяҗын сиземләве шушы Кырлайдан башлана. Монда ул мәдрәсәгә йөреп белем ала, халык иҗаты гәүһәрләре белән таныша. "Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным"-, дип язды шагыйрь.

Шагыйрь эзләре калган сукмаклар авылда әле дә саклана. Аларның берсе Тукай мемориаль коплексына алып килә. Габдулла Тукай Яңа Кырлайда багышланган музей экспозициясе 1960 елларның икенче яртысында авыл китапханәсендә оештырыла.1971 елның 30 мартында Г. Тукай музее Казанда М. Горький музее статусы ала.1976 елдан ТАССР Дәүләт музее филиалы. ТАССР ның Министрлар Советының 1978 елның 7 декабрьдәге" Яңа Кырлай авылын һәм Г. Тукай мемориаль үзәген төзекләндерү, архитектура - сынлы бизәү буенча чаралар карары буенча Б. Урманче проекты белән яңа музей комплексы төзелә, яңа экспозиция ачу тантанасы 1979 елның 25 апрелендә үткәрелә. Музей комплексы үз эченә ике экспозицияне ала: мемориаль көнкүреш (Сәгъди абзый йорты) һәм әдәби - нәфис (махсус төзелгән бина). "Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты" дигән экспозиция Б. Урманче проекты белән төзелгән ике катлы бинада урын алган.

2006 елда музей реконструкция эшләреннән соң яңадан ачыла. Музей Тукай үзенең бик күп шигырьләрен багышлаган елга буена урнашкан, ул еpактан ук күренеп тора. Музейга берничә юл илтә. Туры сукмактан, бөдрә каеннар утыртылган юлдан да барып була. Музейга кунакка килүче һәркем бирedә агач утыртып калдыра, хәзер биредә барысы бергә 171 чыршы үсә. Аларны мәктәп балалары карап, су сибеп тора. Исем - фамилиясе язылган кәгазь һәр агачка беркетелгән. Хуҗасын табуның бер кыенлыгы да юк дигән сүз. Музей каршынында

безне Тукай һәйкәле каршы ала. Әйтерсең, шушы йортка керер алдыннан Тукай ял итәргә уйлаган.

Бөек Тукаебызның тормыш юлы бик тә кыска һәм авыр булган Кырлай музее экспозициясе шагыйрьнең бөтен тормыш юлын гәүдәләндерә: экспонатлар арасында Тукайның үзе исән чакта басылган китаплары, аның туганнары һәм дусларының шәхси әйберләрен, Казанның "Болгар" кунакханәсендәге җиһазларны күрергә мөмкин.

Тиздән музей янында туристлар өчен иске татар авылы барлыкка киләчәк. Кырлай авылындагы күл тирәсендә бүрәнәдән 13 йорт калкып чыгачак, аларның 3 сен быел кар эрегәч, җир ачылгач, күтәрәчәкләр. Тукай заманындагы татар авылы музейның бер өлеше булачак,- дип аңлата музей директоры Тәлгат Гомәров. – Ул йортларның ишегалдында мунча, кош йортлары һәм мал-туар алачыклары корылачак, яшелчә бакчалары үсәчәк, су һәм җил тегермәннәре, чәйханә эшләп торачак. Кырлайга килгән туристлар бу йортларда вакытлыча тукталып . үзләрен элеке замандагы татар авылында яшәгән кебек хис итәчәк. Шунда ук аларны яңа сауган сөт, яңа пешкән икмәк белән сыйлаячаклар.

Кырлай музее. Тукай йөргән эзләр. Күңелгә тынычлык, рәхәтлек өстәлә торган урын. Кырлайны тикмәгә генә татарның мәккәсе димиләр, күрәсең.

Тукай күпкырлы талант. Ул - шагыйрь, туган як табигатенә гашыйк, җир йөзендә яшәүче һәркемнең ирекле һәм азат булуын тели. Шул вакытта - ул үткен телле сатирик та, ялганчыларның, идарә итүчеләрнең, руханиларның ике йөзлеген фаш итә. Тукай иҗатының ике югары ноктасы булып "Печән базары яхут яңа Кисекбаш" поэмасы тора. Шагыйрь анда искелек калдыкларын, дорфалык, наданлыкны тәнкыйтьли. Г.Тукай - публицист та, тормышның иң мөһим проблемаларын мәкаләләрендә күтәреп чыга.

Тукай биографиясе - дөнья әдәбияты тарихында иң драматик биографияләрнең берсе. Болай караганда, шагыйрьнең узган юлы озын түгел. Аның төп урыннары Кушлавыч-Кырлай-Өчиле - Казан - Уральск ... Ләкин шул авыллар, шул шәһәрләр

арасында күпме фаҗига!

**Әдәбият:**

1.”Татарстан яшьләре” газетасы , 2010 ел, апрель.
2.Г. Тукай “Сайланма әсәрләр .
3.Г. Тукай “ Исемдә калганнар”. Кырлайдагы тормышы.

## ЭЧТӘЛЕК

**I НЧЕ ЮНӘЛЕШ. ШАГЫЙРЬ ТОРМЫШЫННАН ЭПИЗОДЛАР**
***Шарифуллина А.И.*** ШАГЫЙРЬ ТОРМЫШЫННАН ЭПИЗОДЛАР........................................................................ 5
***Тимербаева Л.*** ТУКАЙНЫҢ ҖАЕКТАГЫ ТОРМЫШЫ 9
***Якупова М.Р.*** ТУКАЙ ЯНӘШӘСЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗЛАР........................................................................ 13
***Никитина А.Е.*** Г.ТУКАЙНЫҢ НӘСЕЛ ШӘҖӘРӘСЕ...... 17
**II НЧЕ ЮНӘЛЕШ. Г. ТУКАЙНЫҢ КҮПКЫРЛЫ ИҖАТЫ**
***Гыйбадуллина Г.Ш.*** ТУКАЙ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮДӘ КОЛ ГАЛИ ИСЕМЕНДӘГЕ МИЛЛИ КИТАПХАНӘНЕҢ ЭШ АЛЫМНАРЫ.................................................................. 26
***Кунаев А.Ю. МНОГОГРАННОСТЬ ТВОРЧЕСТВА Г. ТУКАЯ.........................................................................*** 33
***Сәйфуллина Л.З.*** ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ КҮПКЫРЛЫ ИҖАТЫ........................................................................ 37
***Портнова Э.В.*** Г. ТУКАЙ ИҖАТЫНДА МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ........................................................................ 43
***Магданурова Л.И.*** ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ТАТАР МУЗЫКАСЫ........................................................................ 47
***Кыяметдинова Д.Ф.*** ТУКАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР..................................................... 52
***Галиева М.Р. ӨСТӘЛЕМДӘ ТУКАЙ КИТАБЫ.................*** 61
***Алексеев А.А.*** ТУКАЙ КҮҢЕЛЕН ЯКТЫРТКАН КАЗАН........................................................................ 66
***Ульданова Э.*** СӨЯМ ДИЕП ӘЙТӘ АЛМАДЫ.................... 71
***Вәлиева Ч.*** ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕНЕҢ ТӘКЪБИРЕ................................ 78
**III ЮНӘЛЕШ. ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР**
***Галиева А.М.*** ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР........................................................ 87
***Фәсхетдинова З.М.*** ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ГАБДУЛЛА

ТУКАЙ ИҖАТЫНА МӨНӘСӘБӘТЕ................................... 91
***Нәбиуллина Э.Р.*** ТУКАЙҺӘМ ӘМИРХАН ДУСЛЫГЫ................................................................... 95
***Хисамиев И.*** Г. ТУКАЙНЫҢ ШАГЫЙРЬ БУЛЫП КИТҮЕНӘ СӘБӘПЧЕЛӘР...................................................... 100
***Габдуллина К.Т.*** ТУКАЙ ҺӘМ УФА..................................... 103
**IV НЧЕ ЮНӘЛЕШ. Г. ТУКАЙ ИҖАТЫН МӘҢГЕЛӘШТЕРҮ**
***Хәйриева Г.Р.*** Б. УРМАНЧЕ ИҖАТЫНДА Г. ТУКАЙ ТЕМАСЫ........................................................................... 111
***Төхвәтуллина Р.*** ӘХСӘН ФӘТХЕТДИНОВ ИҖАТЫНДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МОТВЛАРЫ........................................ 116
***Сабирова Л.*** РӘСЕМ СӘНГАТЕНДӘ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ТЕМАСЫ........................................................................... 120
***Гайсина Г.*** Г. ТУКАЙ ОБРАЗЫ - РӘССАМНАР ИҖАТЫНДА................................................................... 124
***Яруллин И.*** Г. ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР МУЗЫКА СӘНГАТЕ 129
***Идиятуллина М.*** ТУКАЙ ҺӘМ МУЗЫКА............................ 133
***Ямалетдинова А.*** ӘДӘБИЯТТӘ ҺӘМ СӘНГАТЬТӘ ТУКАЙ ОБРАЗЫ…................................................................ 137
***Ульданова Э.*** КЫРЛАЙДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МУЗЕЕ.. 140

Научное издание

# ТУКАЙ ИҖАТЫНЫҢ КАДЕРЕ

**Г. Тукайның 125-еллыгына багышланган шәһәркүләм түгәрәк өстәл материаллары**

Сдано в набор 25.05.2012.
Подписано в печать 29.05.2012.
Бумага писчая. Гарнитура Таймс.
Усл. печ. л. 9. Тираж 100.
Заказ №30.

НХТИ (филиал) ФБГОУ ВПО «КНИТУ»,
г. Нижнекамск, 423570,
ул. 30 лет Победы, д. 5а.